Министерство образования и науки РФ

ФГАОУ ВПО «Казанский (Приволжский) федеральный университет»
Институт филологии и межкультурной коммуникации

Кафедра общей лингвистики, лингвокультурологии и переводоведения

Г.А. НАБИУЛЛИНА

ПЕРЕВОД ХУДОЖЕСТВЕННОГО ТЕКСТА

Конспект лекций

Казань-2014

Направление подготовки: 032700.62 Прикладная филология: Межкультурная коммуникация и переводоведение.
Учебный план: «Прикладная филология (переводоведение)» (очное, 2011)
Дисциплина: «Перевод художественного текста» (бакалавриат, 3 курс, очное обучение)
Количество часов: 108 ч. (в том числе: лекции – 30, лабораторные занятия – 42, самостоятельная работа – 36), форма контроля: экзамен (5-й семестр).
Темы:
1. Теоретические основы художественного перевода.
2. История татарского художественного перевода.
3. Проблемы национально-культурной и хронологической адаптации художественного текста при переводе.
4. Принципы художественного перевода.
5. Особенности перевода художественных текстов различных видов и жанров.
6. Лексические особенности художественного перевода.
7. Синтаксические особенности художественного перевода.

Аннотация:
В предлагаемых лекциях изучаются теоретические и практические вопросы художественного перевода. Рассматриваются проблемы становления и истории теории художественного перевода, переводимости и адекватности текста, классификации видов и форм художественного перевода, лексикологических, грамматических, стилистических аспектов художественного перевода, освоение компетенции переводчика. Ограниченное число лекций по теории перевода с русского языка на татарский художественного текста имеет своей целью передать студентам минимум знаний, основных положений, необходимых им для дальнейшего выполнения практических задач, а именно выполнение тренировочных упражнений по переводу с русского языка на татарский литературных текстов, анализа готовых переводов, сделанных профессиональными переводчиками относительно достигнутой адекватности вариантов. В процессе изучения дисциплины студенты учатся, опираясь на современный уровень развития теорий перевода, различать специфику художественного перевода; развивают способность выделять языковые особенности и образную систему художественного текста, приобретают навыки исследовательской работы.

Ключевые слова: әдәби тәрҗемә, проза тәрҗемәсе, поэзия тәрҗемәсе, әдәби тәрҗемәнең лесик үзенчәлекләре, әдәби тәрҗемәнең синтаксик үзенчәлекләре, әдәби тәрҗемә тарихы, милли-мәдәни колорит, әдәби тәрҗемәгә анализ.

Дата начала использования: 1 сентября 2014 года

Автор - составитель: Набиуллина Гузель Амировна, доцент кафедры общей лингвистики, лингвокультурологии и переводоведения, кандидат филологических наук , тел.: (843) 2-21-34-78, email: GuzelNab2@yandex.ru.

Электронная версия курса в MOODLE: http://bars.kpfu.ru/course/view.php?id=1791

Содержание

Тема 1.ӘДӘБИ ТӘРҖЕМӘНЕҢ ГОМУМТЕОРЕТИК НИГЕЗЛӘРЕ........ 7
Лекция 1. Әдәби тәрҗемә теориясе: максаты, бурычлар, объекты 7
1.1 Әдәби тәрҗемә теориясе 7
1.2 Әдәби тәрҗемәнең максат, бурычлары, объекты 8
Список литератур 10
Рекомендуемые информационные ресурсы 10
Лекция 2. Әдәби тәрҗемә ысуллары, чаралары һәм методлары 10
2.1 Әдәби тәрҗемә чаралары һәм методлары... 10
2.2 Әдәби тәрҗемәчегә куелган таләпләр, тәрҗемәченең вазифасы 11
Список литератур 13
Рекомендуемые информационные ресурсы 14
Задания для практики по теме 1 14
Тема 2.ӘДӘБИ ТӘРҖЕМӘ ТАРИХЫ... 16
Лекция 3. Татар әдәбиятын башка халыкларга таныту. Рус (чит) телдән татар теленә, татар теленнән рус (чит) телгә әдәби тәрҗемәләр. 16
3.1 Татар теленә беренче әдәби тәрҗемәләр 16
3.2 Рус теленнән татар теленә тәрҗемә итү тарихы 17
3.3 Татар теленнән рус теленә тәрҗемә тарихы.. 18
3.4 Чит телләрдән рус теленә тәрҗемә тарихы 19
Список литератур 22
Рекомендуемые информационные ресурсы 22
Задания для практики по теме 2 22
Тема 3. ӘДӘБИ ТӘРҖЕМӘНЕ МИЛЛИ-МӘДӘНИ ҺӘМ ХРОНОЛОГИК ЯКТАН ТӘҢГӘЛЛӘШТЕРҮ ПРОБЛЕМАЛАРЫ................ 23
Лекция 4. Әдәби тәрҗемәдә милли колоритны чагылдыру........................ 23
4.1 Әсәрнең милли колориты. Реалияләр 24
4.2 Тәрҗемә ителә алу-алмау мәсьәләсе.. 27
Список литератур 29
Рекомендуемые информационные ресурсы 30
Лекция 5. Әдәби тәрҗемәне хронолик тәңгәлләштерү мәсьәләсе.............. 30
Список литератур 34

Рекомендуемые информационные ресурсы 34
Задания для практики по теме 3 34
Тема 4. ӘДӘБИ ТӘРҖЕМӘ ПРИНЦИПЛАРЫ 38
Лекция 6. Әдәби тәрҗемә принциплары. 39
6.1 Әдәби тәрҗемә концепциясенең башлангычы 39
6.2 Әдәби тәрҗемәнең төп юнәлешләре 41
6.3 Әдәби тәрҗемәнең дүрт принцибы 42
Список литератур 43
Рекомендуемые информационные ресурсы 43
Задания для практики по теме 4 44
Тема 5. ТӨРЛЕ ЖАНРДАГЫ ҺӘМ ТӨРДӘГЕ ӘСӘРЛӘРНЕ ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ 45
Лекция 7. Проза тәрҗемәсе 45
Список литератур 49
Рекомендуемые информационные ресурсы 49
Лекция 8. Поэзия тәрҗемәсе 50
Список литератур 56
Рекомендуемые информационные ресурсы 56
Лекция 9. Драматургия әсәрләрен тәрҗемә итүнең төп алымнары 56
Список литератур 59
Рекомендуемые информационные ресурсы 59
Задания для практики по теме 5 60
Тема 6. ӘДӘБИ ТӘРҖЕМӘНЕҢ ЛЕКСИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ 62
Лекция 10. Әдәби тәрҗемәнең лексик үзенчәлекләре 62
10.1 Әдәби тәрҗемәдә сүзнең мәгънәсен бирү 62
10.2 Сүз тәңгәллекләре 63
10.3 Диалектизмнарны, гади сөйләм сүзләрен тәрҗемә итү 66
Список литератур 67
Рекомендуемые информационные ресурсы 68
Лекция 11. Лексик сурәтләү чараларын тәрҗемә итү ысуллары 68
Список литератур 71
Рекомендуемые информационные ресурсы 71
Лекция 12. Фразеологик әйтелмәләрне тәрҗемә итү 71
Список литератур 76

Рекомендуемые информационные ресурсы 76
Лекция 13. Паремийларны тәрҗемә итү 76
Список литератур 80
Рекомендуемые информационные ресурсы 81
Задания для практики по теме 6 81
Тема 7. ӘДӘБИ ТӘРҖЕМӘНЕҢ СИНТАКСИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ........ 84
Лекция 14. Синтаксик фигураларны тәрҗемә итү үзенчәлекләре 84
14.1Синтаксик фигураларны тәрҗемә итү үзенчәлекләре 84
14.2Кабатлауларның бирелеше 87
Список литератур 90
Рекомендуемые информационные ресурсы 91
Лекция 15. Сүз тәртибе белән бәйле мәсьәләләр 91
Список литератур 93
Рекомендуемые информационные ресурсы 94
Задания для практики по теме 7 94
Глоссарий 96
Литература 97

Тема 1. ӘДӘБИ ТӘРҖЕМӘНЕҢ ГОМУМТЕОРЕТИК НИГЕЗЛӘРЕ

Лекция 1

Әдәби тәрҗемә теориясе: максаты, бурычлар, объекты

Аннотация. Данная тема раскрывает основные понятия литературного перевода.

Ключевые слова. Әдәби тәрҗемә, әдәби тәрҗемәнең максаты, әдәби тәрҗемәнең бурычлары, матур әдәбият, минималь берәмлекләр, әдәби текстны тәрҗемә итүче, әдәби тәрҗемәченең вазифасы.

Методические рекомендации по изучению темы.

- Вначале необходимо изучить теоретическую часть с определениями основных понятий.
- В качестве самостоятельной работы предлагается написать эссе по актуальным проблемам художественного перевода.
- Для проверки усвоения темы имеются вопросы для изучения, также необходимо выполнить задание и отправить на проверку.

Вопросы для изучения

Теория художественного перевода как научная дисциплина.

Предмет, объект художественного перевода.

Цели и задачи художественного перевода.

Әдәби тәрҗемә теориясе

Тәрҗемәләрне төркемләүдә төрле классификацияләр яшәп килә. Л.Н. Соболев 3 төркемне аерып карый: 1) техник, фәнни, һәм эш кәгазьләре тәрҗемәсе; 2) матур әдәбият тәрҗемәсе; 3) иҗтимагый-сәяси һәм публицистик тәрҗемә

А.В. Федоров тәрҗемәләрне түбәндәгечә төркемли: 1) газета-информация текстлары, документаль һәм махсус фәнни текстлар; 2) публицистик әсәрләр; 3) матур әдәбият әсәрләре [5].

Р.А. Юсупов тәрҗемәләрне 5 төркемгә бүлеп карарга тәкъдим итә: 1) шигъри тәрҗемә; 2) проза тәрҗемәсе; 3) публицистик тәрҗемә; 4) фәнни, информацион, документаль тәрҗемә; 5) кино тәрҗемәсе. Проза тәрҗемәсе дигәндә, матур әдәбият тәрҗемәсе күздә тотыла [6].

Һәртөрле классификация күпмедер дәрәҗәдә шартлы: аерым төркемнәргә кергән тәрҗемә төрләре үзара якынча берләштерелгән. Техник, фәнни һәм эш кәгазьләре тәрҗемәсе бер үк төркемгә караса да, фәнни хезмәтне тәрҗемә итү белән эш кәгазьләрен тәрҗемә итү бер үк түгел, хәтта фәнни тәрҗемә исеме астына берләштерелгән махсус фәнни хезмәтне тәрҗемә итү белән мәктәп дәреслеген тәрҗемә итү бер үк түгел. Шулай ук матур әдәбият тәрҗемәсенә караган проза һәм поэзияне тәрҗемә итүнең дә аермалы яклары бар. Күренгәнчә, матур әдәбият тәрҗемәсе, тәртибе буенча төрле

классификацияләрдә урыны төрле булса да, аерым бер төркем итеп карала. Нигездә, күп кенә төркемнәрдә проза һәм поэзия тәрҗемәсе матур әдәбият тәрҗемәсе исеме белән бирелә. Р.А.Юсупов исә методологик максатлардан чыгып, поэзия тәрҗемәсен проза тәрҗемәсеннән аерып карау ягында тора.

Күренгәнчә, тәрҗемә эше, объектка нисбәтле рәвештә, үз эченә әдәби, фәнни, публицистик, фольклор үрнәкләрен тәрҗемә итү һӘМ башка юнәлешләрне берләштерә. Тәрҗемәнең һәр төренең үзенә генә хас таләпләре, кагыйдәләре бар. Аларны тәрҗемә итүнең үзенчәлекле яклары, үз ысуллары бар. Тәрҗемә материалының һәр төренә аерым таләпләр куела. Тәрҗемә материалының төре андагы сүзлек составы, лексик чаралар, синтаксик төзелеш үзенчәлегеннән чыгып билгеләнә.

Шулар арасында иң катлаулы һәм авыр төрләрнең берсе булып матур әдәбият әсәрләрен тәрҗемә итү санала. Утыз ел дәвамында француз әдәбиятыннан төрек теленә роман-хикәяләр тәрҗемә иткән төрек әдибе Җәмил Мәрич әдәби тәрҗемә турында шулай дип аңлата: «Тәрҗемә ул — яралту, минемчә, шигырь кебек, нәсер кебек, хәтта алардан да кыенрак. Әйе, тәрҗемә әдәби жанрлар арасында иң авыры — башка җирлектә һәм башка чорда туган уй-фикерне үз җирендә терелтү. Тәрҗемә — яулау, яулау гына түгел, уй һәм хисләрнең катлаулы дөньясын баетучы казаныш ул». Әнә шулай әдәби тәрҗемәгә иң хак, иң гадел бәя биргән галим. Матур әдәбиятны тәрҗемә итүче бер үк вакытта көзге ролен дә башкара. Аның төп эше — әдип әсәрен чын мәгънәсендә түкми-чәчми башка халыкларга житкезү. Шуңа күрә үзе алда күренми, ул арткы планда, аның аша әдипләр башка илләрдә танылa. Аларның мәшһүр булуы тәржемәчегә дә сөенеч китерә [http://www.sptatar.ru/index.php/2012-08-06-14-40-58/313-t-r-em-chelek-zaman-tal-be].

Матур әдәбиятны тәрҗемә итүнең теоретик һәм практик мәсьәләләре фәнни әдәбиятта шактый җентекләп өйрәнелгән. Бу турыда рус тел белемендә А.А.Смирнов (1930), В.Н. Комиссаров, А. Федоров (1940-1970), Е.Г. Эткинд (1960-1980), П.И. Копанев (1970), Г.Р. Гачечиладзе (1960-1980), В.В. Виноградов (1970), Д. Шариков (1960), Ю.П.Солодуб (2000), А. Попович (1980) хезмәтләре бар. Татар тел белемендә тәрҗемә, лингвистик проблема буларак, XX гасырның беренче яртысында өйрәнелә башлый. Әдәби тәрҗемәнең теоретик һӘМ практик мәсьәләләре хакында телче һӘМ әдәбиятчы галимнәребез Г.Х.Алпаров, М.Максуд, Г.Ибраһимов, Х.Курбатов, Р.Башкуров, И.Ахунҗанов, Х.Алмаева, Ф.Әхмәдуллина, Г.Ахунов, В.Ганиев, Р. Сибәгатов, Ф. Сафиуллина, К.Миңлебаев, Л.Газизова һ.б. хезмәтләре билгеле.

Әдәби тәрҗемәнең максат, бурычлары, объекты

Матур әдәбият әсәре - теге яки бу милләтнең рухи казанышы, хәзинәсе, мәдәни йөзе ул.

- ✓ *Әдәби тәрҗемәнең **максаты** - шул казанышны башка халыкларга җиткерү, әдәби багланышларны ныгыту.*

✓ ***Бурычы** белем, мәгълүмат бирү генә түгел, матур әдәбият теле күңелгә хуш килүе белән дә матурлык хисе тәрбияләргә һәм укучы тарафыннан яратып укылырга тиеш. Теләсә нинди матур әдәбият әсәре тәрҗемә ителә алмый.*

✓ *Төп **предметы** – әдәби әсәр.*

Тәрҗемә әсәргә яңа форма кидертелә (рус телендә сөйләшкән китап татар телендә сөйләшә башлый). Әгәр бу форма үзенең эшләнеше, дөреслеге, төгәллеге, матурлыгы белән элекке формасыннан түбән торса, икенче төрле итеп әйткәндә, тәрҗемәсенең теле оригиналының теленнән начаррак, зәгыйфьрәк булса, әсәрнең эчтәлегенә, идеясенә, һичшиксез, зыян килә. Димәк, әдәби әсәрне мәгънәсе ягыннан гына түгел, ә эмоциональ яктан, интонация ягыннан, колорит ягыннан да дөрес тәрҗемә итү кирәк.

Тәрҗемә әсәрнең теленә бу телдә сөйләтүчеләрнең рухи йола-традицияләре, менталитеты, фикер йөртү үзенчәлекләре кебек экстралингвистик факторлар да йогынты ясый. Бу фактор - тәрҗемә вариантының вариантының теленә сүз сайлауда зур роль уйнаган күренешләрнең берсе. Мәсәлән, оригинал телдәге ниндидер фикерне, идеяны укучыга җиткерү өчен, оптималь булган лексик, морфологик яисә семантик чаралар җыелмасы икенче телдә сөйләшүчеләр өчен, гомумән, тирән эчтәлеккә, матур яңгырашка ия булмаска да мөмкин. Телнең лексик составында икенче бер телгә тәрҗемә ителмәүче, ягъни аналогы булмаган берәмлекләр дә урын ала. Бу фактор да тәрҗемә процессына тәэсир итүче күренешләрнең берсе булып тора. Югарыда әйтелгәннәрне истә тоткан хәлдә, Һичшиксез, бу процесста тәрҗемәче шәхесенең (яше, белеме, эрудициясе, профессиональ сыйфатлары) роле зур булуны да ассызыклап үтү мөһим.

Тәрҗемә теориясе, шул исәптән әдәби тәрҗемә өчен сүзнең тел берәмлеге буларак түгел, ә бәлки мөмкин булган (хәтта мөмкин булмаган) лексик, стилистик, экспрессив мәгънәләре, грамматик формалары белән контекстта конкрет кулланылышы әһәмиятле. Сүз сөйләмдә, кагыйдә буларак, үзенә хас булган билгеле бер мәгънәдә, һәм грамматик формада урын ала. Үзенчәлекле буларак, матур әдәбиятта исә мәсьәлә тагын да катлаулырак. Сүз сурәт ясау, образ тудыру, эстетик тәэсир итү чарасына әверелә. Матур әдәбиятта сүзнең эстетик мөмкинлекләре сүз-сурәт, сүз-образ белән бәйле була, сүзнең берничә мәгънәсе – туры яисә күчерелмә мәгънәләре берьюлы семантик актуальлеккә ия була.

Тәрҗемәче әдәби текстны тәрҗемә иткәндә, җөмләләр аша аерым сүзләр белән эш итә. Ул контексттан чыгып аерым сүзнең лексик, экспрессив, стилистик мәгънәләрен билгели, һәм тәрҗемә телендә шул мәгънәне белдерерлек сүз эзли. Биредә хәлиткеч рольне оригинал сүзнең контексттан аңлашылган мәгънәсе уйный. Кайвакыт сүз, язучының стиленә, хикәяләү осталыгына бәйле рәвештә яңа мәгънәви төсмерләр ала, сүзлекләрдә теркәлмәгән, көтелмәгән мәгънәләр ала. Әдәби тәрҗемә процессында бер телдәге сүз икенче телдә бик күп төрле сүзләр белән бирелергә мөмкин. Тәрҗемәче исә контексттагы сүзнең мәгънәсен мөмкин кадәр төгәл бирергә тиеш, сүзлекләрдә теркәлмәгән мөмкинлекләрне, чараларны да файдаланырга туры килә. Р.А. Юсупов

сүзләре белән әйткәндә, функциональ-экспрессив тәңгәллеккә туры килгән лексик берәмлекне дөрес сайлап ала белергә тиеш. Оригиналдагы сүз тәрҗемәгә сәнгатьлелеге, укучыга эстетик тәэсир итү көче буенча тиң, тәңгәл булырга тиеш.

Список литературы

1. Казакова Т. А.. Художественный перевод. Теория и практика. - Инъязиздат, 2006.
2. Нәбиуллина Г.Ә., Мөгътәсимова Г.Р. Тәрҗемә практикасы: әдәби һәм фольклор тәрҗемәләре. Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы. - Казань: Ихлас, 2012. – 91 б.
3. Попович А. Проблемы художественного перевода. - М., 2000. - 198 с.
4. Солодуб Ю.П. Теория и практика художественного перевода / Ю.П. Солодуб, Ф.Б. Альбрехт, А.Ю. Кузнецов. – Москва: Изд. центр.“Академия”, 2005. – 304 с.
5. Сибәгатов Р.Г. Рус теленнән татар теленә тәрҗемә методикасының нигезләре. – Уфа, 1979. - 72 б.
6. Федоров А.В. Основы общей теории перевода (лингвистические проблемы) / А.В.Федоров. – СПб.: Филологический факультет СПбГУ; М.: ООО «Издательский Дом «ФИЛОЛОГИЯ ТРИ», 2002. – 416 с.
7. Юсупов Р.А. Соотношение разноструктурных языков и вопросы перевода. – Казань: 2005. - 225 с.

Рекомендуемые информационные ресурсы

1. Р. Юсупов: Тәрҗемәдән кәлҗемә ясамыйк // http://www.madanizhomga.ru/tt/hbrl/item/1068-r%D2%AFz%D3%99l-yusupov-t%D3%99r%D2%97em%D3%99d%D3%99n-k%D3%99l%D2%97em%D3%99-yasamyiyk.html
2. Тәрҗемәчелек – заман таләбе // http://www.sptatar.ru/index.php/2012-08-06-14-40-58/313-t-r-em-chelek-zaman-tal-be

Лекция 2

Әдәби тәрҗемә ысуллары, чаралары һәм методлары

Аннотация. Данная тема раскрывает способы и методы литературного перевода.

Ключевые слова. Тәрҗемә методы, машина (интернет) тәрҗемәсе, кулдан тәрҗемә итү, компромисс метод, иҗадилык принцибы, әдәби тәрҗемәченең вазифасы.

Методические рекомендации по изучению темы.

- Вначале необходимо изучить теоретическую часть с определениями основных понятий.
- Для проверки усвоения темы имеются вопросы для изучения, также необходимо выполнить задание и отправить на проверку.

Вопросы для изучения

Методы художественного перевода.

Требования к переводчику художественного текста.

Функции переводчика.

Хәзерге көндә тәрҗемә методлары ике төргә бүленә: машина тәрҗемәсе (интернет) һәм кулдан тәрҗемә итү. Бүген күп төрле тәрҗемә программалары эшләнгән, төрле сайтлар бар, тәрҗемә хезмәтен тәкъдим иткән күп онлай-сайтлар эшли. Ләкин рус теленнән татар теленә, татар теленнән рус теленә тәрҗемә итә торган интернет тәрҗемәләр бүгенге көндә бөтенләй юк. Билгеле бер сүзләрне, аерым фразеологизмнарны тәрҗемә итү өчен, ойнлайн-сүзлекләргә генә мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Интернет сүзнең күчерелмә мәгънәләрен билгеләп, контекстка туры килгән уңышлы тәрҗемәне сайлап ала алмый. Нәтиҗәдә, хаталар, уңышсыз тәрҗемәләр барлыкка килә. Тагын бер метод – компромисс метод та кулланыла. Башта интернет (машина) тәрҗемә итә, аннары тәрҗемәче кулдан төзәтеп, чистартып чыга. Ләкин белгечләр алай эшләргә тәкъдим итмиләр. Интернет текстны боза һәм стилистик яктан тәрҗемәне оригиналга яраклаштырып, тәңгәлләштереп бетереп булмый дип аңлаталар. Иң камил ысул буларак кулдан тәрҗемә санала. Чөнки тере кеше генә тәрҗмене тоеп эшли ала, оргианалның мәгънәсен тулысынча җиткереп, дөрес һәм төгәл грамоталы тәрҗемә итүгә сәләтле.

Әдәби тәрҗемәчегә куелган таләпләр, тәрҗемәченең вазифасы

Тәрҗемә ул – чыганак телдән тәрҗемә теленә җиткерү өчен алынган билгеле бер мәгълүматны үз эченә алган интеллектуаль эшчәнлек. Тәрҗемә эшен ике телне дә яхшы белгән тәрҗемәче башкара. Тәрҗемәчедән, иң беренче чиратта, интеллект, зәвык сорала. Тәрҗемәченең әсәрнең асылын, эчтәлеген, идеясен аңлавы, тәрҗемә берәмлекләренә (сүз, сүзтезмә, җөмлә) структур-семантик эквивалентлар таба белүе әһәмиятле.

Тәрҗемәче эшчәнлегенең иҗади характеры нәрсәдә чагыла соң? Мәсәлән, (А. Купринның «Ак пудель» әсәреннән бер өзек): *Тропинка шла вдоль высокого прибрежного обрыва, извиваясь в тени столетних маслин. Море иногда мелькало между деревьями, и тогда казалось, что, уходя вдаль, оно в то же время подымается вверх спокойной могучей стеной, и цвет его был еще синее, еще гуще в узорчатых прорезах, среди серебристо-зеленой листвы. В траве, в кустах кизиля и дикого шиповника, в виноградниках и на деревьях - повсюду заливались цикады; воздух дрожал от их звенящего, однообразного, неумолчного крика. День выдался знойный, безветренный, и накалившаяся земля жгла подошвы ног.* - *Диңгезнең текә ярлары буйлап, йөзәр ел яшәгән зәйтүн агачларының күләгәләре эчендә борылмалы сукмак күренгәләп кала. Ул ерак-еракларга сузыла да, тыныч, көчле стенадай югары күтәрелә кебек, һәм аның төсе көмеш-яшел яфраклар арасыннан тагын да зәңгәррәк, тагын да куерак булып күренә*

иде. Үләннәр арасында, кызыл агач һәм гөлҗимеш куакларында, виноград бакчаларында, агачларда – бөтен җирдә чикерткә тавышлары яңгырый; чикерткәләрнең өзлексез чыңлаган тавышыннан һава калтырый. Көн эссе, җилсез, уттай кызган җир аяк табаннарын пешерә иде.(И. Туктаров тәрҗемәсе). Бу текстны төрлечә тәрҗемә итәргә мөмкин, һәркем үзенең иҗади сәләтен күрсәтә ала: сүзләр өсти, яисә киресенчә кыскарта, стилистик төзәтмәләр кертә ала. Текст катлаулана барган саен, тәрҗемә итү дә авырлаша бара. Матур әдәбиятны тәрҗемә иткәндә исә, тәрҗемәче язучының автордашына әверелә. Бу очракта тәрҗемәче чын мәгънәсендә барлык иҗади мөмкинлекләрен чагылдырырга тиеш.

Димәк, тәрҗемәченең эшчәнлеге – иҗади һәм интеллектуаль, шулай да иң әһәмиятлесе – ул оригинал һәм тәрҗемә телен бертигез дәрәҗәдә камил белергә тиеш.

Тәрҗемәче өчен тел өлкәсендәге иҗади мөмкинлекләр чикләнмәгән. Зур булмаган берәр җөмләне икенче телдә, ул белдергән мәгънәне саклап, уннарча вариантларда бирергә мөмкин. Берсе аның җыйнаграк, икенчесе җәенкерәк, берсе шомарак, икенчесе катлаулырак булырга мөмкин.

Матур әдәбият тәрҗемәчесенең иҗадилыгы башкаларыннан нәрсә белән аерыла соң? Тәрҗемәчегә тел-сурәтләү чаралары, ягъни Р.А. Юсупов сүзләре белән әйткәндә, «тел элементларының катлаулырак һәм күп төрлерәк категорияләре" белән белән эш итәргә туры килә. Тәрҗемәнең башка төрләрендә күбрәк эквивалентлы тәңгәллекләр кулланылса, матур әдәбият тәрҗемәсендә адекват тәңгәллекләр, компенсацияләүләр зуррак урын алып тора.

Матур әдәбият тәрҗемәсенә куелган таләпләр В.Г. Белинский, Ф. Батюшков (Матур әдәбият тәрҗемәсе принциплары. 1920), А.Агатов, татар тәрҗемә гыйлемендә Г. Ибраһимов җитәкчелегендәге комиссиянең "Милләт мәсьәләсе", Г.Хәбиб, И. Гази, Г. Кутуй, С. Фәйзуллин, Р. А. Юсупов, Г. Хантимерова һ.б. хезмәтләрендә өйрәнелә.

1) Тәрҗемәнең төп таләпләреннән берсе һәм иң әһәмиятлесе – оригиналның мәгънәсен, эчтәлеген тулы бирү. Мәгънәне, эчәлекне тулы бирү принцибы тәрҗемә төгәл булырга тиеш дигән таләп белән аерылгысыз бәйләнгән. Тәрҗемә төгәл булмаса, тәрҗемә ителә торган әсәрнең мәгънәсе тулы бирелә алмый. Бу турыда В.Г. Белинский болай дип яза: "Матур әдәбият тәрҗемәсендә бернинди төшереп калдырулар да, өстәүләр дә булырга тиеш түгел". Мәгънә ялгышлыклары әсәрнең милли колоритына, сәнгать дәрәҗәсенә зыян китерергә мөмкин.

2) Тәрҗемәдә төп нөсхәнең форма үзенчәлекләре, автор стиле, сәнгать-милли үзенчәлеге мөмкин булганча тулы гәүдәләнергә тиеш. Күренекле тәрҗемәчеләр, тәрҗемә белгечләре бу принципка элек-электән зур игътибар итеп килгәннәр һәм тулы кыйммәтле тәрҗемәгә ирешү өчен, форма элементларын да мөмкин кадәр тулы сакларга кирәк дип исәпләгәннәр. Форма төгәллегенә ирешү автор стилен саклауга кайтып кала. Төп нөсхәнең үзенчәлекләре: сурәтләү чаралары, образлылык элементлары, интонациясе һ.б. автор стиленә яраклаштырып бирелсә, бу – тәрҗемә оригиналга стиле буенча тиң дигән сүз дип аңлата Р. А. Юсупов. Бу очракта авторга хас язу алымнарына, аерым алганда, тропларга, фразеологизмнарга, гади сөйләм сүзләренә, диалекталь сүзләргә,

билгеле бер төрле җөмлә төзелешләренә туры килерлек чаралар таба алу әһәмиятле. Ләкин һәр очракта да даими эквивалентлар табарга мөмкин булмый. Бу очракта тәрҗемәче күп төрле вариантларның берсен, эчтәлеге һәм формасы белән оригиналга мөмкин кадәр туры килгән тел чараларын сайлап ала.

3) Сайлап алу, эзләү тагын бер әһәмиятле принципка килеп тоташа. Иҗадилык принцибы – матур әдәбият тәрҗемәсендә, бигрәк тә поэтик тәрҗемәдә әһәмиятле принцип. Үз вакытында рус шагыйре-тәрҗемәче В.А. Жуковскийның иҗат иреге турында әйткән сүзләре бүген дә үзенең әһәмиятен югалтмый: «Проза тәрҗемәчесе – кол, шигырь тәрҗемәчесе – көндәш». Бу принцип поэтик чаралар сайлап алганда, сүз белән сурәт тудыруда чагыла. Шулай да тәрҗемәче иҗат ирегеннән дөрес файдалана белергә тиеш, чама хисен аңларга, сак килергә тиеш. Тәрҗемәче, үзе теләгәнчә, текстны үзгәртеп, үзирекле тәрҗемә белән мавыгып, авторга хыянәт итә алмый. Дөрес, тәрҗемә тарихында авторны төзәтү, әсәрне шомарту күренешләре дә күзәтелә. 19 гасырда шундый тәрҗемә нәтиҗәсендә көнбатыш язучылары руслаштырылган, әсәрдәге вакыйгалар Россия җирлегенә күчерелгән, Париж Мәскәүгә, Пьер Иванга әверелдерелгән – ягъни, әсәргә җан кертелгән. “Үзгәртеп” тәрҗемә итүнең нигезендә берничә сәбәп яткан. Беренчесе – укучы чит язучы әсәрен җиңелрәк үзләштерсенннәр, тулырак аңласыннар дигән теләк белән тәрҗемә әсәрен укучыга якынайту. Икенчесе – тәрҗемәченең оригиналны ошатмыйча, үзе теләгәнчә төзәтеп, кыскартып, яисә бөтенләй төшереп калдырып тәрҗемә итүендә. Өченче сәбәп тәрҗемә эшенең кыен эш булуында. Кайвакыт тәрҗемә итүгә караганда яңача әйтү, арттырыбрак эшләү җиңелрәк була башлый. Гомерның “Илиада”сын тәрҗемә иткән Н.И. Гнедич болай дип язган: “Бизәү, Гомер шигырен безнең төскә буяп җибәрү бер дә авыр эш түгел, ул купшырак, зиннәтлерәк булып күренәчәк, һәм безгз ныграк ошаячак, ләкин аны нәкъ Гомердагыча итеп саклау шактый кыен эш”.

Аңлашылганча, тәрҗемәче иҗаты бары тик тел өлкәсенә генә карый. Оригиналның эчтәлегенә, мәгънәсенә, сәнгатьлелегенә, стиль үзенчәлекләренә килгәндә, тәрҗемәченең иҗаты турында бернинди сүз дә булырга мөмкин түгел. В. Г. Белинский сүзләре белән әйткәндә, тәрҗемәче таланты ул – форма таланты, чит әсәрләрнең рухына төшенү, аларның матурлыгын тою сәләтендә күренә.

- ✓ *Матур әдәбият әсәренең эчтәлек һәм форма бердәмлеге укучыда билгеле бер эмоцияләр, кичерешләр тудыра, ягъни билгеле бер эстетик әһәмияткә ия була. Тәрҗемә ителгән әсәр дә шундый эстетик әһәмиятен югалтмаска тиеш.*
- ✓ *Тәрҗемәче һәр ике телне дә яхшы белергә тиеш. Тәрҗемәче өчен оригинал һәм тәрҗемә телләренең әдәби формаларын гына белү җитми, халык сөйләм телен, диалектларын да, ягъни бөтен нечкәлекләрен белергә тиеш.*
- ✓ *Тәрҗемә теле дөрес булырга, әдәби нормаларга туры килергә, оригиналдагыча җанлы, бай, эмоциональ булырга тиеш.*

Список литературы

1. Казакова Т. А.. Художественный перевод. Теория и практика. - Инъязиздат,

2006.
2. Нәбиуллина Г.Ә., Мөгътәсимова Г.Р. Тәрҗемә практикасы: әдәби һәм фольклор тәрҗемәләре. Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы. - Казань: Ихлас, 2012. – 91 б.
3. Попович А.Проблемы художественного перевода. - М., 2000. - 198 с.
4. Солодуб Ю.П. Теория и практика художественного перевода / Ю.П. Солодуб, Ф.Б. Альбрехт, А.Ю. Кузнецов. – Москва: Изд. центр.“Академия”, 2005. – 304 с.
5. Сибәгатов Р.Г. Рус теленнән татар теленә тәрҗемә методикасының нигезләре. – Уфа, 1979. - 72 б.
6. Федоров А.В. Основы общей теории перевода (лингвистические проблемы) / А.В.Федоров. – СПб.: Филологический факультет СПбГУ; М.: ООО «Издательский Дом «ФИЛОЛОГИЯ ТРИ», 2002. – 416 с.
7. Юсупов Р.А. Соотношение разноструктурных языков и вопросы перевода. – Казань: 2005. - 225 с.

Рекомендуемые информационные ресурсы

1. Р. Юсупов: Тәрҗемәдән кәлҗемә ясамыйк // http://www.madanizhomga.ru/tt/hbrl/item/1068-r%D2%AFz%D3%99l-yusupov-t%D3%99r%D2%97em%D3%99d%D3%99n-k%D3%99l%D2%97em%D3%99-yasamyiyk.html
2. Тәрҗемәчелек – заман таләбе // http://www.sptatar.ru/index.php/2012-08-06-14-40-58/313-t-r-em-chelek-zaman-tal-be

Задания для практики по теме 1

Задание 1.1 Р. Юсуповның “Тәрҗемәдән кәлҗемә ясамыйк” язмасын укып фикер алышу.

Задание 1.2 Оригинал белән тәрҗемә текстын чагыштырып укыгыз. минимал берәмлекләрне табып, тәрҗемәсен аңлатыгыз.

Вронский вошел в вагон. Мать его, сухая старушка с черными глазами и букольками, щурилась, вглядываясь в сына, и слегка улыбалась тонкими губами. Подкявшись с диванчика и передав горничной мешочек, она подала маленькую сухую руку сыну и, подняв его голову от руки, поцеловала его в лицо.

— Получил телеграмму? Здоров? Слава богу.

— Хорошо доехали? — сказал сын, садясь подле нее и невольно прислушиваясь к женскому голосу из-за двери. Он знал, что это был голос той дамы, которая встретилась ему при входе.

— Я все-таки с вами не согласна, — говорил голос дамы.

— Петербургский взгляд, сударыня.

— Не петербургский, а просто женский,— отвечала она.

— Ну-с, позвольте поцеловать вашу ручку.

— До свиданья, Иван Петрович. Да посмотрите, не тут ли брат, и пошлите его ко мне, — сказала дама у самой двери и снова вошла в отделение.

— Что ж, нашли брата? — сказала Вронская, обращаясь, к даме.

Вронский вспомнил теперь, что это была Каренина.

— Ваш брат здесь, — сказал он, вставая. — Извините меня, я не узнал вас, да и наше знакомство было так коротко, сказал Вронский, кланяясь,— что вы, верно, не помните меня.

— О нет, — сказала она, — я бы узнала вас, потому что мы с вашею матушкой, кажется, всю дорогу говорили только о вас,— сказала она, позволяя, наконец, просившемуся наружу оживлению выразиться в улыбке.— А брата моего все-таки нет. (Л.Н. Толстой “Анна Каренина”)

Тәрҗемәсе:

Вронский вагонга керде. Аның әнисеӊ кара күзле, бөдрәләткән чәчле, кечкенә гәүдәле кипшенгән бер карчык, кечкенә гәүдәле текәлеп улына карап тора һәм юка иреннәре белән чак кына елмая иде. Ул, кечкенә диваннан торып, янчыгын хезмәтчесенә бирде дә кипшенгән кечкенә кулын улына сузды, аның башын күтәреп, битен үпте.

— Телеграмманы алдыңмы? Исәнлек-саулыкмы? Ярый, аллага шөкер!

Улы аның янына утырып һәм ишек артыннан ишетелгән хатын-кыз тавышына ирексездән колак салып:

— Әйбәт кенә килеп җиттегезме, —диде. Ишек артыннан ишетелгән тавыш кергәндә, очраган дама тавышы икәнен Вронский белеп тора иде.

— Ә мин шулай да сезнен фикерегезгә кушыла алмыйм,— диде дама.

— Петербург карашы бу, ханым.

— Петербург карашы түгел, тик хатын-кыз карашы гына, — дип җавап кайтарды дама.

— Ярый, кулыгызны үбәргә рөхсәт итегез.

— Хушыгыз, Иван Петрович. Анда күз салыгыз, абый килмәгәнме икән, күренсә, минем янга җибәрегез,— диде дама ишекнең янында ук, аннары үзе яңадан бүлмәгә керде.

— Я, ничек соң, абыегызны таптыгызмы? — диде.

—Вронская, дамага мөрәҗәгать итеп.

Хәзер инде Вронский бу даманың Каренина икәнлеген аңлады

— Сезнең абыегыз биредә, — диде ул, урыныннан торып. — Гафу итегез, мин сезне танымадым, хәер, безнең танышлык та бик кыска вакытлы гына булган иде бит, — диде Вронский, баш иеп, — сез инде, мөгаен, мине хәтерләми дә торгансыздыр.

— Һич тә алай түгел, — диде дама, мин сезне таныган булыр идем, чөнки әнкәгез белән без юл буе диярлек тик сезнен турыда гына сөйләшеп килдек, — диде ул ирекккә ашкынган елмаюына чагылырга рөхсәт итеп. — Ә шулай да абый һаман юк бит әле (М. Максуд тәрҗемәсе).

Тема 2. ӘДӘБИ ТӘРҖЕМӘ ТАРИХЫ

Лекция № 3

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫН БАШКА ХАЛЫКЛАРГА ТАНЫТУ. РУС (ЧИТ)ТЕЛДӘН ТАТАР ТЕЛЕНӘ, ТАТАР ТЕЛЕННӘН РУС (ЧИТ) ТЕЛГӘ ӘДӘБИ ТӘРҖЕМӘЛӘР

Аннотация. Данная тема раскрывает краткий обзор истории художественного перевода в с русского (иностранного) языка на татарский и с татарского языка на русский (иностранный) язык.

Ключевые слова. Әдәби тәрҗемә, татар теленә беренче әдәби тәрҗемәләр, ирекле тәрҗемә, татар теленнән рус теленә әдәби тәрҗемәләр, рус теленнән татар теленә әдәби тәрҗемәләр, чит ил әдәбияты татар телендә.

Методические рекомендации по изучению темы.

- Тема содержит лекционную часть, где даются краткий обзор истории художественного перевода.
- В дополнение к лекции рекомендуется прочитать статью Л. Хамидуллина “Әдәби тәрҗемә дә бик кирәк эш” .
- В качестве самостоятельной работы предлагается работа с переводами художественных текстов разного жанра (на выбор студента); ознакомление с библиографическим списком по основным разделам дисциплины (работа в библиотеке).
- Для проверки усвоения темы имеются вопросы для изучения, также необходимо выполнить задание и отправить на проверку.

Вопросы для изучения

История художественного перевода с русского языка на татарский язык.
История художественного перевода с татарского языка на русский.
Зарубежная литература на татарском языке.

Татар теленә беренче әдәби тәрҗемәләр

Әдәби тәрҗемә, бер телдә язылган әсәрне, аның стилистик үзенчәлекләрен мөмкин кадәр саклап калырга тырышып, икенче телгә күчерү. Оригиналь иҗаттан аермалы буларак, әдәби тәрҗемәгә оригиналга бәйлелек хас. Әдәби тәрҗемә - оригиналь әсәргә карата икенчел күренеш, ул ирекле, төгәл һәм тәңгәл булырга мөмкин. Татар әдәбиятында әдәби тәрҗемә милли әдәбиятның бер өлешен тәшкил итә. Татар теленә беренче әдәби тәрҗемәләр (ирекле тәрҗемәләр) урта гасырларда ук барлыкка килә. Мәсәлән, Котб, Низаминың «Хөсрәү вә Ширин» поэмасын тәрҗемә иткәндә, аның төп идея эчтәлеген, сюжетын һәм образларын, гомуми композициясен һәм кайбер поэтик формаларын саклап калып, шул ук вакытта әсәрне төркиләр тормышына, аларның дөньяны аңлауларына яраклаштыра. Шуңа күрә, «Хөсрәү вә Ширин»нең төркичәсен, бүгенге мәгънәдән чыгып, тәрҗемә дип атап булмый, бер үк вакытта ул оригиналь әсәр дә түгел, аны ярыморигиналь, ярымтәрҗемә әсәр дип атарга мөмкин. Котбның тәрҗемә принципларын дәвам иткән урта гасыр шагыйре Сәйф Сараи да Сәгъдинең «Гөлестан»ын төгәл тәрҗемә итми, ул аны кыскарта, үзгәртә: яңа мотивлар һәм вариацияләр кертә, үзенчәлекле сурәтләү чаралары куллана. Нәтиҗәдә, аның «Гөлестан би-т-төрки»е мөстәкыйль әдәби ядкәргә әверелә. Гадәттә, милли әдәбиятларның үсеш чорына (татар әдәбиятында 19 йөзнең ахыры - 20 йөзнең башы) тәрҗемәнең активлашуы хас була һәм алар оригиналь әсәрләр кебек үк кабул ителәләр. Бу чорда традицион рәвештә Шәрекъ әдәбияты әсәрләре: «Тутыйнамә», «Кәлилә вә Димнә» (Г. Фәезханов тәрҗ.), Низаминың «Ләйлә вә Мәҗнүн»е (М. Максуд тәрҗ.), «Мең дә бер кичә»се (Ф. Халиди тәрҗ.) һ.б. тәрҗемә ителә.

Рус теленнән татар теленә тәрҗемә итү тарихы

Рус теленнән татар теленә матур әдәбият әсәрләрен беренчеләрдән булып М. Иванов тәрҗемә иткән. 1842 елны М. Ивановның “Татар хрестоматия”сендә татар теленә И.И. Хемницер, И.И. Дмитриев, И.А. Крылов әсәрләре тәрҗемә ителә. К. Насыйри - Л.Н. Толстой экиятләрен, И.А. Крылов мәсәлләрен, Т. Яхин - А.С. Пушкин, А.Н. Афанасьев экиятләрен, М. Өметбаев А.С. Пушкинның «Бакчасарай фонтаны»н тәрҗемә итә. 19 гасыр ахырында А.С. Пушкин тәрҗемә ителә башлый. Мәсәлән, аның “Бакчасарай фонтаны”, “ Балыкчы һәм балык турында экият”, “Кышкы юл”шигыре, “Евгений Онегиннан” өзекләр һ.б. тәрҗемә ителә.

20 йөз башында татар әдәбиятына рус һәм төрек әдәбиятлары аша Көнбатыш Европа әдәбияты әсәрләре керә башлый. Мәсәлән, француз әдәбияты татарларга төрек әдәбияты аша килеп ирешә. Татар теленә тәрҗемә ителгән беренче Көнбатыш Европа әдәбияты әсәре - Д.Дефоның «Робинзон Крузо» романы (С. Максуди тәрҗ., 1898). 20 йөз башында Ф. Әмирхан Г.-Х. Андерсен экиятләрен, Р. Рәкыйби Г. Мопассанның «Милон атакай» («Папаша Милон») хикәясен, С. Рәмиев Ф. Шиллерның «Перчатка» балладасын, Н. Думави Вольтерның «Мегаполис» повестен, Г. Камал Мольерның «Саран» («Скупой») пьесасын, А. Дюма-улының «Камелияле ханым» («Дама с камелиями») романын һ.б. тәрҗемә итәләр. Тәрҗемәләрдә, башлыча, рус әдәбияты:

А.С. Пушкин, М.Ю. Лермонтов, Н.В. Гоголь, И.С. Тургенев, А.П. Чехов, А.Н. Островский, Л.Н. Толстой, М. Горький һ.б. әсәрләре өстенлек итә. Актив тәрҗемәчеләр: Г. Исхакый, Г. Тукай, С. Рәмиев, Г. Камал, С. Рахманкулов, И. Багданов, Г. Рахманколый һ.б. Тәрҗемәләр, кагыйдә буларак, ирекле рәвештә эшләнә. Күп очракта оригиналь әсәрнең авторы яки исеме күрсәтелми (мәсәлән, «Шиллердан» дип кенә язалар). Аерым очракларда укучы тәрҗемәне тәрҗемәченең үз әсәре итеп кабул итә.

Тәрҗемәнең дәүләт күләмендә зур эш булып китүе Октябр революциясеннән соңгы елларга туры килә. Иҗтимагый-сәяси, фәнни әдәбиятны әдәбиятны тәрҗемә итү белән бергә матур әдәбиятны тәрҗемә итү эше дә киң колач ала. Р.Юсупов хезмәтләрендә китерелгән русчадан татарчага тәрҗемә белән бәйле кайбер саннарны карап китик:

- 1918 елдан 1968 елга кадәр 1600 матур әдәбият әсәре тәрҗемә ителгән.
- 1918-1962 елларда элекке СССРдагы һәм чит илләрдәге 114 халыкның матур әдәбият һәм фольклор әсәрләре тәрҗемә ителгән.
- 1380 нән артык язучының әсәре тәрҗемә ителгән.

40-50 елларда Сталин премиясе алган һәр әсәрне тәрҗемә итү гадәткә кереп китә. Тәрҗемә ителән әсәрләрнең күпчелеге рус һәм чит ил әдәбиятыннан. Татар теленә чыккан әсәрләренең күплеге буенча беренче урында А.М. Горький тора. 1918-1962 елларда аның әсәрләре татар телендә 64 тапкыр басылып чыккан. А.С. Пушкин -53 тапкыр, Л.Н. Толстой – 34 тапкыр, А.П. Чехов – 21 тапкыр, И.С. Тургенев – 15, М.Ю. Лермонтов – 14 тапкыр бастырыла. Шулай ук С. Маршак, А. Толстой, Н. Гоголь, Н. Некрасов, В. Маяковский, А. Гайдар, М. Шолохов, В. Шишков һәм башка язучыларның да китаплары татар теленә берничә тапкыр тәрҗемә ителә.

Күренгәнчә, татар теленә тәрҗемә тарихы бөек шагыйрь Г. Тукай исеме белән бәйле. Тукай мәдрәсәдә укыган елларда ук Крыловның 75 мәсәлен тәрҗемә иткән. Соңрак Г Тукай Пушкин, Лермонтов, Жуковский, Фет, Тютчев, Майков, Ушинский, Кольцов һәм башка язучыларның әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә.

Татар теленнән рус теленә тәрҗемә тарихы

Татар теленнән рус теленә дә тәрҗемәләр эшләнә. Мәсәлән, үзе исән вакытта ук Г. Тукайның кайбер шигырьләре П.А. Радимов тарафыннан рус теленә күчерелә. 1930 елларда рус теленә Ш. Усманов хикәяләре, М. Галәүнең «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр» романнары, 1940 елларда М. Әблиевнең «Шәмсекамәр», Т. Гыйззәтнең «Ташкыннар», Г. Камалның «Беренче театр» пьесалары, Ш. Камалның «Матур туганда» романы, Г. Тукайның, Һ. Такташның күп кенә шигырьләре, А. Алиш экиятләре тәрҗемә ителә. 1960 еллар башына рус теленә тәрҗемәләр күбәя, М. Гафури, К. Нәҗми, Ә. Фәйзи, Г. Кутуй, М. Җәлил, Г. Әпсәләмов, М. Әмир, С. Хәким, Ә. Ерикәй, Г. Бәширов әсәрләре тәрҗемә ителә.

СССР күләмендә югары бәяләнгән, дәүләт бүләкләре алган әсәрләрне тәрҗемә итү бервакыт рәсми төс алган, сәясәткә әверелгән чаклар да булды. 1940-1950 елларда югары

бәяләнгән андый әсәрләрне тәрҗемә итү мәҗбүри санала иде. Ул мәҗбүрилекнең безнең өчен уңай нәтиҗәләре дә булгалады. Нәкъ шул дәвердә 3 нче дәрәҗә Сталин премиясенә лаек дип табылган үз әсәрләребездән Гомәр Бәшировның «Намус»ы белән Кави Нәҗминең «Язгы җилләр»е күпчелек Союздаш республика халыклары телләрендә басылып чыктылар. Болгар, венгр, кытай, немец, поляк һ.б. телләрдә сөйләшүче әдәбият сөючеләр дә нәкъ шул елларда Совет чоры татар әдәбияты үрнәкләре белән таныша алдылар.

Совет чоры татар әдәби тәрҗемә өлкәсендә чын мәгънәсендә «алтын чор» булып танылa, бу дәвердә татар әдәбиятын күп кенә тәрҗемәләр белән баеткан тәрҗемә мәктәбе барлыкка килә. К.Басыйров, С.Әдһәмова, И. Гази, С.Фәйзуллин, А.Шамов, К.Миңлебаев, Р.Даутов, В.Зыятдинов, Ф.Гайнанова, Я.Халитов, Т.Нурмөхәммәтов, С.Ибраһимова, Л.Хәмидуллин (прозада); Ә.Фәйзи, Ф.Бурнаш, Ә.Исхак, Н.Арсланов, С.Баттал, Ш.Маннур, Ә.Ерикәй, Ә.Давыдов, М.Ногман, З.Нури, М.Шабаев, И.Юзеев, Р.Фәйзуллин, Г.Рәхим (поэзиядә); З.Солтанов, Г.Шамуков (драматургиядә) үзләрен татар теленә тәрҗемә итү осталары итеп таныталар. 1960 еллар башына классик рус һәм совет әдәбияты әсәрләренең бик күбесе тәрҗемә ителә. Татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү өлкәсендә Г. Шәрипова, Г. Хантимерова, Р. Фәизова, Ә. Бадюгина (прозада); А.А. Ахматова, С.Н. Иванов, А.А. Тарковский, Д.С. Самойлов, С.И. Липкин, Р.Д. Моран, В. Ганиев, М.Д. Зарецкий, Н.Н. Беляев, Г.А. Паушкин, Р. Харис, Р. Бохараев, Р. Кожевникова, Л.Н. Григорьева (поэзиядә) эшли. Бу чор әдәби тәрҗемәгә тәңгәл тәрҗемәгә омтылу хас. Рус классик әдәбиятыннан тыш, совет әдәбияты үрнәкләре дә тәрҗемә ителә: А.Н. Толстой, В.Я. Шишков, А.А. Фадеев, М.А. Шолохов, Д.А. Фурманов, Н.А. Островский, И.Г. Эренбург, В.Ф. Панова, К.Г. Паустовский, Н.Ф. Погодин, К.М. Симонов, М.М. Пришвин, А.Т.Твардовский, Н.С.Тихонов; балалар әдәбиятыннан С.Т.Аксаков, П.А.Бажов, В.Г.Короленко, С.Я.Маршак, С.В.Михалков, А.Л.Барто, В.В.Бианки, А.П.Гайдар, Б.С.Житков, В.А. Каверин, Л.А. Кассиль, В.П. Катаев, Н.Н. Носов һ.б. әсәрләре. 1990 еллардан башлап, илнең икътисади хәленә бәйле рәвештә, тәрҗемә эшчәнлеге сүлпәнәя төшә.

Бер үк әсәр берничә тәрҗемәче тарафыннан эшләнеп, төрле вариантларда басылу фактлары бар. Шундый мисаллар күрсәтергә мөмкин; А.С. Пушкинның беренче Фәтхи Бурнаш тарафыннан тәрҗемә ителгән “Евгений Онегин” романы соңыннан Ә. Фәйзи, Ә. Исхак, Ш. Маннур тәрҗемәсендә басылып чыккан. А.С. Пушкинның “Кышкы кич” шигыренең өч варианты бар: Мөхәммәт Садри, Әхмәт Ерикәй, Салих Баттал тәрҗемәләрендә; М. Горькийның “Ана” романы башта Ф. Бурнаш тәрҗемәсендә, аннары Мәхмүд Максуд тәрҗемәсендә чыккан. Грибоедовның “Акыллылык бәласе”н башта Н. Исәнбәт, Соңыннан Габдулла Шамуков тәрҗемә иткән. Билгеле бу тәрҗемәләрнең һәркайсында үзенчәлекле яклар бар, һәркайсында тәрҗемәчеләрнең уңышлары, иҗади йөзе чагыла.

Чит телләрдән татар теленә тәрҗемә итү тарихы

Чит ил әдәбияты барысы да диярлек татарчага рус теле аша тәрҗемә ителгән.

Француз әдәбиятыннан татар теленә Виктор Гюго, Жюль Верн, Анри Барбюс, Эмиль Золя, Мольер, Ги де Мопассан һәм башка язучыларның әсәрләре тәрҗемә ителгән. Алман әдәбиятыннан Г. Гейне, И. Гете, Шиллер, В. Бредел, Л. Фейхтвангер һәм башкаларның китаплары бар. Инглиз әдәбиятыннан Байрон, Э. Войнич, Д. Дефо, Шекспир әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителгән. Америка әдәбиятыннан татар теленә Бичер Стоу, Джек Лондон, Марк Твен, Эрнест Хемингуэй, У.Уитмен, Джон Рид, Теодор Драйзер һәм башка язучыларның әсәрләре тәрҗемә ителгән Шулай ук Италия, Испания, Норвегия, Дания, Төркия, Һиндстан, Иран, Япония һәм башка илләр әдәбиятыннан тәрҗемә ителгән әсәрләр бар.

Турыдан-туры чит телдән татар теленә тәрҗемә ителгәннәр дә бар. Алар арасында башкорт, казах, үзбәк, кыргыз, әзербайҗан, төрек телләреннән, шулай ук инглиз, немец, француз телләреннән дә берничә китап тәрҗемә ителүе билгеле. Татар әдәбиятында төрки халыкларның әдәбиятын татарчалаштыру үрнәкләре дә аз түгел. Бу өлкәдә Сәрвәр Әдһәмова зур уңыш казанды дисәк ялгыш булмас. Аның хезмәте нәтиҗәсендә татар укучысы казак язучысы М. Әүзовның "Абай" романы белән танышу бәхетенә ия булды. Л. Хәмидуллин исә, үзбәк язучысы Әсгать Мохтарның "Чинар" «романын яңадан эшләп чыгарды. Болар, һичшиксез, татар тәрҗемәчелеге тарихында зур казаныш буларак бәяләнергә хаклы.

Узган гасырның алтмыш-сиксәненче елларында рус, белорус, казакъ, украин, үзбәк, азәрбайҗан, грузин һәм кайбер чит ил телләрендә нәшер ителгән иң күренекле әсәрләрне үз телебездә басылды. Матур әдәбият сөючеләр кулына ул заманнарда елына кимендә җиде-сигез тәрҗемә әдәби китап барып ирешер иде. Бөтендөнья күләмендә танылган авторлардан Михаил Шолохов, Мохтар Әүэзов, Константин Симонов, Чыңгыз Айтматов, Виктор Астафьев, Василь Быков, Юрий Бондарев, Әнүәр Әлимҗанов, Роман Солнцев, Валентин Распутин, Нодар Думбадзе, Әсгать Мохтар, Гафур Голәм һ.б. әсәрләре бу чорда татар укучысы тарафыннан хуплап кабул ителделәр.

80 елларда бездә рус, азәрбайҗан, казакъ, төрекмән һ.б. халыклар әдипләренең күмәк хикәя яки повесть, шигырь җыентыклары да даими рәвештә туплап басыла килде. Мәсәлән, каракалпак халкы әдәбияты антологиясе «Арал дулкыннары», Идел буе республикалары язучыларының күмәк җыентыклары, казакъ авторлары повестьлары тупламалары «Ак дөя», «Җәйләүдә», «Дала гөлләре», союздаш һәм автономияле республикалар әдипләренең сайланма хикәяләр җыентыгы «Дуслык аланы» һ.б. бездә зур тиражлар белән нәшер ителделәр. Кардәш әдәбият вәкилләре дә бурычлы булып калмады. Казакъстанда «Дуслык көтепханәсе» сериясендә күләмле «Татар повестери» китабы, Үзбәкстанда «Йиллар ва йуллар», Каракалпакстанда «Татар гүрриңлери» исемендә хикәя җыентыклары, Украинада «Свети меня, Чулпан-заря» дип исемләнгән шигырь тупламасы һ.б.лар дөнья күрделәр. Азәрбайҗан белән Кыргызстанда да шундый ук күләмле җыентыклар басылып чыкты. Әлбәттә, ул республикаларда андый күмәк җыентыклардан тыш та татар әдипләре әсәрләре тәрҗемә ителә иде. Шул җәһәттән аеруча казакъ кардәшләрне аерым билгеләп үтү урынлы булыр. Сугыштан соңгы чорда Казакъстанда һәр елны диярлек икешәр-өчәр татар китабы дөнья күрде. Г.Тукай,

М.Җәлил җыентыклары да даими рәвештә басыла торды. Үзбәк уртаклар да алардан калышмаска тырышты. Үзбәкстанда татар әдәбияты таралышына зур әһәмият бирүчеләрдән милләттәшләребез Габдулла Уразаев белән Әсгать Мохтарны аерым искә алу кирәктер.

СССР һәм чит дөнья халыклары әдәбияты үрнәкләрен татар телендә чыгаруда актив эшләүче язучылардан дистәләгән роман вә повестьлар тәрҗемә иткән Рәис Даутов, Яхъя Халитов, Кыям Миңлебаев, Таһир Нурмөхәммәтов, Әнәс Хәсәнев, Шәһидә Максудова, Фәния Гайнанова, Наилә Вәлитова, Люция Нәҗмиеваны билгеләп үтәргә мөмкин. Кардәш төрки телләрдән тәрҗемә итүче осталар рәтендә Сәрвәр Әдһәмова, Нури Арслан, Әхмәт Исхак, Мостафа Ногман, Мәхмүт Хөсәен һәм Тәүфикъ Әйди дә ул дәвердә бик актив эшләделәр.

Бүгенге көндә татар теленнән төрек теленә тәрҗемә итү шактый популярлашып бара. Төркиядә махсус проект нигезендә 7 ел эчендә төрек әсәрләре 41 телгә тәрҗемә ителгән, 50 илдә басылып чыккан һәм алар әлегә барлыгы 748 китап. 2005-2012 еллар аралыгында Төркиядә дөнья күргән татар әсәрләре шактый. Алар түбәндәгеләр:

1. «VASIYET» исемле җыентык. «Замбак» нәшриятында 2005, 2006 һәм 2012 елларда өч басмасы дөнья күрә. Анда кергән әсәрләр профессор Хатыйп Миңнегулов тәкъдиме белән сайланып, китап аның кереш сүзе белән чыга. Тәрҗемәчеләре — Фатих Кутлу, Хамза Әрсой, Надир Тамәр Аслан. Җыентыкка кергән әсәрләр: Әмирхан Еники «Әйтелмәгән васыять», «Матурлык»; Шәриф Камал «Буранда», «Уяну»; Фатих Әмирхан «Бер харәбәдә», «Сәмигулла абзый»; Галимҗан Ибраһимов «Табигать балалары»; Мирсәй Әмир «Мөстәкыйм карт йокысы»; Фатих Хөсни «Сөйләнмәгән хикәя»; Миргазиян Юныс «Безнең өй өянкеләр астында иде».

2. Р.Вәлиевнең «MAVI HÜZÜN»(«ЗӘҢГӘР САГЫШ») җыентыгы «Da» нәшриятында 2007 елда дөнья күрә. Тәрҗемә итүчеләр — Фатих Кутлу, Харун Тосун.

3. А.Гыйләҗевның «BIR AVUÇ TOPRAK» («ӨЧ АРШЫН ҖИР») повесте Фатих Кутлу тәрҗемәсендә һәм профессор Хатыйп Миңнегуловның кереш сүзе белән «Сүтун»нәшриятында 2008 (2 басма), 2011 елларда басылып чыкты. Аяз Гыйләҗевның Фатих Кутлуга васыяте буенча тәрҗемә ителде.

4. «HECE ÖYKÜ» журналының «Хәзерге татар хикәясе» дигән 54 нче номерлы махсус «декабрь-гыйнвар» саны. Фатих Кутлу тәрҗемә иткән хикәяләр Әлфәт Закирҗановның кереш сүзе белән чыкты. Анда ун автордан берәр хикәя урын алды, алар түбәндәгеләр: Айгөл Әхмәтгалиева «Җиде ят», Асия Юныс «Бәби мунчасы»; Аяз Гыйләҗев «Күлмәк»; Галимҗан Гыйльманов «Күңел күзең күрәме?»; Дания Гайнетдинова «Бәхет яшьләре»; Зөлфәт Хәким «Чын ярату»; Марсель Галиев «Балачак әсирлегендә»; Рабит Батулла «Хәерче Габәш»; Рәмзия Габделхакова «Китүчеләр»; Ркаил Зәйдулла «Ак эт».

5. А.Гыйләҗевның «CUMA GÜNÜ, AKŞAM...» («Җомга көн, кич белән...») әсәре Фатих Кутлу тәрҗемәсендә һәм Миләүшә Хәбетдинова кереш сүзе белән «Бәнгү» нәшриятында 2013 елда дөнья күрде.

6. «Тавышсыз курай» (хәзерге татар әдәбиятыннан хикәяләр) җыентыгы «Бәнгү» нәшриятында 2013 елда басылып чыкты. Анда татар хикәләяре белән беррәттән, Рабит Батулланың «Тавышсыз курай» әкияте һәм Әсгать Салахның «Соңгы вальс» повесте да урын алган.

Список литературы

1. Байрамова Л.К. Татарстан: языковая симметрия и ассимметрия / Л.К.Байрамова. – Казань: Изд-во КГУ, 2001. – 267 с.
2. Галеева Э.Р. О переводах художественной литературы в Республике Татарстан: взгляд на историю, современное состояние и проблемы // Актуальные пролемы и перспективы развития русскоязычной литературы в контексте национальных литератур. – Казань, 2011. – С.101-106.
3. Казакова Т. А. Художественный перевод. Теория и практика. - Инъязиздат, 2006.
4. Миннибаев К.С. Перевод - это искусство. Казань, 2004.
5. Нәбиуллина Г.Ә., Мөгътәсимова Г.Р. Тәрҗемә практикасы: әдәби һәм фольклор тәрҗемәләре. Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы. - Казань: Ихлас, 2012. – 91 б.
6. Нигматуллин Э.Г. Диалог литератур: Указатель переводов произведений русской литературы на татарский язык. Казань, 2002;
7. Семенец О.Е. История перевода (Средневековая Азия, Восточная Европа XV-XVIII вв.): Учеб. пособие / О.Е. Семенец, А.Н. Панасьев. – Киев: Лыбидь, 1991. – 364 с.
8. Юсупов Р.А. Соотношение разноструктурных языков и вопросы перевода/ Р.А. Юсупов. – Казань: 2005. - 225 с.

Рекомендуемые информационные ресурсы

1. Хәмидуллин Л. Әдәби тәрҗемә дә бик кирәк эш // http://www.gabdullatukay.ru/index.php?option=com_content&task=view&id=1717&Itemid=50
2. http://nsportal.ru/shkola/rodnoi-yazyk-i-literatura/library/tukaynyn-trzhem-eshen-monsbte
3. http://russian-tatar.ru/
4. http://tatpoisk.net/dict/rus2tat/

Задания для практики по теме 2

Задание 2.1 Л. Хәмидуллинның “Әдәби тәрҗемә дә - бик кирәк эш” язмасын укып, фикер алышу.

Задание 2.2. А.М. Горький, А.С. Пушкин, Л.Н. Толстой, А.П. Чехов, И.С. Тургенев, М.Ю. Лермонтов, А. Толстой, Н.Гоголь, А. Ахматова, Блок, В. Гюго, Г.Гейне, Шекспир,

Э. Хемингуэй әсәрләренең тәрҗемәләренә күзәтү ясау.

Задание 2.3. А.М. Горькийның “Минем университетларым” (С.Әдһәмова тәрҗемәсе) әсәрләреннән алынган өзекнең тәрҗемәсен укып фикер алышу.

А.М. Горький “Минем университетларым” (С.Әдһәмова тәрҗемәсе)

Дня через три после моего приезда, утром, когда дети ещё спали, а я помогал ей в кухне чистить овощи, она тихонько и осторожно спросила меня:

— Вы зачем приехали?

— Учиться, в университет.

Её брови поползли вверх вместе с жёлтой кожей лба, она порезала ножом палец себе и, высасывая кровь, опустилась на стул, но, тотчас же вскочив, сказала:

— О, чорт...

Обернув носовым платком порезанный палец, она похвалила меня:

— Вы хорошо умеете чистить картофель?

Ну, еще бы не уметь! И я рассказал ей о моей службе на пароходе. Она спросила:

— Вы думаете — этого достаточно, чтоб поступить в университет?

В ту пору я плохо понимал юмор. Я отнесся к её вопросу серьёзно и рассказал ей порядок действий, в конце которого предо мною должны открыться двери храма науки. (М. Горький «Мои университеты»)

Мин килгәннән соң, ике-өч көн үткәч, иртә белән балалар йоклыйлар иде әле, мин кухняда аңа яшелчә арчырга булыша идем, ул саклык белән акрын гына миңа сорау бирде:

— Сез нигә килдегез?

— Университетта укырга килдем.

Аның кашлары маңгаеның сары тиресе белән бергә югары күтәрелделәр, ул пычак белән бармагын кисте, һәм канын суыра-суыра урындыкка утырды да, шунда ук тагын сикереп торып:

— О, шайтан... — диде.

Киселгән бармагын кулъяулыгы белән ураганнан соң, мине мактап куйды:

— Сез бәрәңгене оста арчыйсыз икән.

Арчый белмәскә ни! Һәм мин аңа үземнең пароходта хезмәт итүем турында сөйләдем. Ул:

— Университетка керер өчен, шул җитә дип уйлыйсызмы? — дип сорады.

Көлеп әйтелгән сүзне аңлап җиткерми идем әле мин ул чакта. Аның соравын чынга алып, үземнең нәрсәләр эшләячәгемне һәм шуннан соң минем каршымда фән йортының ишеге ачылырга тиешлеген тезеп сөйләп бирдем. (И. Гази тәрҗемәсе).

Тема 3. ӘДӘБИ ТӘРҖЕМӘНЕҢ МИЛЛИ-МӘДӘНИ ҺӘМ ХРОНОЛОГИК ЯКТАН ТӘҢГӘЛЛӘШТЕРҮ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

Лекция № 4.

ӘДӘБИ ТӘРҖЕМӘДӘ МИЛЛИ КОЛОРИТНЫ ЧАГЫЛДЫРУ

Аннотация. Данная тема раскрывает особенности передачи национально-культурного колорита при переводе художественной литературы.

Ключевые слова. Әсәрнең милли-мәдәни үзенчәлекләре, милли колорит, тәрҗемәдә текстның «экзотизация»се, реалияләр, этнографик реалияләр.

Методические рекомендации по изучению темы

- Тема содержит лекционную часть, где излагаются проблемы национально-культурной особенности художественного текста при переводе.
- Для проверки усвоения темы имеются вопросы для изучения, также необходимо выполнить задание и отправить на проверку.

Вопросы для изучения

Национально-культурные особенности произведения.

Сохранение национальной окраски при переводе художественных произведений.

Особенности и приемы перевода реалий.

Фоновые знания в художественном переводе.

Проблема переводимости-непереводимости.

Әсәрнең милли колориты. Реалияләр

"Заман сынавын узган һәм оригинал хәлендә үзенең укучыларын елдан-ел ишәйткән әсәрне икенче телгә төкми-чәчми күчереп кую ансат башкарыла торган эш түгел. Бердән, оста художник кулы белән язылган китапның теле ифрат үзенчәлекле һәм бай була - тәрҗемәчедән үз ана телен әйбәт белүне һәм ул байлыктан оста файдалануын сорый; икенчедән, ул бай һәм камил телнең бөтен нечкәлекләрен, нюансларын үз теленә күчерергә, ә моның өчен оригиналга тәңгәл килердәй тәгъбирләр табарга кирәк була; өченчедән, олуг художник ул әсәрен иҗат иткән дәвердә нинди настроениедә яшәгән, аның арасына салган бизәк-оттеноклары нидән гыйбарәт - боларның һәммәсен ныклап өйрәнү һәм үз телендә шуларны мөмкин кадәр тулы, хыянәтсез чагылдыру таләп ителә... Димәк, тәрҗемәче татар теленең лексик составы, телнең эчке мөмкинекләре, парадигматик һәм синтагматик кануннары, мәгънәви күчешләр, лексик-семантик интерференция кебек категорияләрдән яхшы хәбәрдар булырга тиеш" [2]. К.Миңлебаев тәрҗемәнең сыйфатын билгеләүче үзенчәлекле "индикатор" тәкъдим итә. Аның фикеренчә, "тәрҗемәнең сыйфатын билгеләү өчен, текстны үзгәртеп укырга кирәк. Әгәр дә аны адым саен үзгәртеп була икән, ул тәрҗемәне уңышлы дип әйтеп булмый. Ә инде һәр җөмләсе ныклап уйланган, һәр сүзе урынына куелган икән - андый тәрҗемәне һич тә үзгәртү мөмкин түгел. Оста кулы белән эшләнгән тәрҗемә китабында да шулай ук: бер генә сүзен алсаң да - сүтелә, укылмый, җырламый башлый".

Әдәби тәрҗемәнең күп кенә мәсьәләләре әсәрнең милли колоритын саклау һәм тәңгәлләштерүгә бәйле. Тәрҗемәче теге яки бу илнең тормышын, гореф-гадәтләрен, йолаларын, гомумән, милли үзенчәлекләрен чагылдырган кайбер реалияләрне тәрҗемә иткәндә, кыенлыклар кичерә. Тәрҗемә, иң беренче чиратта, укучыга аңлаешлы адекват мәгънәгә ия булырга тиеш. Әгәр дә бу үзенчәлек тулысынча исәпкә алынмаса**,** тәрҗемәдә текстның «экзотизация»се барлыкка килә, әгәр дә кирәгеннән артык бирелсә, «креолизация» барлыкка килә.

Әлеге мәсьәләне хәл итү автор ниятен, максатын дөрес аңлауга, анализлауга бәйле. Әгәр әсәрнең авторы реалияләрне милли колорит элементы буларак максатчан куллана икән, транслитерация алымын киң файдалану урынлы була. Ләкин монда да текстны экзотизмнар белән артык чуарларга ярамый. Мәсәлән, Л.Н. Толстойның “Егетчак” әсәрен тәрҗемә иткәндә, К.Миңлебаев реалияләрнең кайберләрен үзгәртеп-беркадәр татарчалаштырып-аңлатып бирсә, икенчеләре исә үзгәрешсез кабул ителгәннәр: *Он сшил себе модное платье – оливковый фрак, модные панталоны со штрипками и длинную бекешу, которая очень шла к нему... — Папа үзенә модалы киемнәр – яшькелт-сары фрак белән тасмалы, модалы панталон, өстендә ятып торган озын бекеша (биле бөрмәле бишмәт) тектерде...; Теперь она мечтала уже выйти замуж не за гусара, а за певца или музыканта и с этой целью усердно занималась музыкой. — Хәзер инде ул, гусарга чыгам дип түгел, бәлки берәр җырчыга яки музыкантка чыгам, дип хыяллана һәм шуңа күрә музыкага чынлап торып өйрәнә иде.*

Реалия атамаларын тәрҗемә итү милли һәм тарихи үзенчәлекләрне бирү процессында туган авырлыкларның зур өлешен алып тора. Милли колоритны чагылдыра торган сүзләр буларак, реалияләр бары илленче елларда гына өйрәнелә башлаган. Аларны Л.Н.Соболев, Г.В.Чернов, М.П.Алексеев, Г.В. Шатков, А.В. Федоров, Я.И. Рецкер, А.Е. Супрун кебек галимнәр тикшергән. Элек реалияләрне рус галимнәре экзотик лексика, безэквивалентная лексика дип атаганнар. Реалия сүзе латин телендә “вещественный», «действенный» мәгънәләрен белдерә. Алар – һәрвакыт табигый рәвештә халыкның милли карашы һәм көнкүреше белән тыгыз бәйләнгән сүзләр.

Тәрҗемә белгечләре реалияләрне төркемләүнең төрле юлларын тәкъдим итәләр. И.С.Алексеева классификациясендә реалияләр өч төргә бүленә:

1. Географик реалияләр: а) физик география терминнары: прерия, саванна; б) эндемика (билгеле бер урынга гына хас хайван, кош-корт, үсемлек төрләре) терминнары: баобаб, кенгуру.

2. Этнографик реалияләр: а) кием-салым: кимоно; б) корылмалар һәм көнкүреш җиһазлары: сауна; в) милли эшчәнлек төрләре: икебана, скоморох; г) йолалар, ырымнар, уеннар: вендетта, тамада; д) мифология һәм культлар: тролль, синагога; е) үлчәү һәм акча берәмлекләре: аршин.

3. Иҗтимагый-сәяси реалияләр: кантон, большевиклар [1: 181].

Р.А.Юсупов реалияләрне тәрҗемә итүнең өч юлын күрсәтә:

1. Тулы яки өлешчә транслитерация (реалия исемен турыдан-туры алу яки аның тамырын тәрҗемә теле аффикслары белән бергә куллану).

2. Реалияне белдерү өчен, тәрҗемә теле элементлары һәм морфологик үзенчәлекләр җирлегендә яңа сүз ясау.

3. Функциясе буенча чит тел реалиясенә якын торган әйбер яисә төшенчәне белдергән сүздән файдалану.

Нигездә реалияләрне тәрҗемә итүнең өч ысулын билгелиләр. Кайбер галимнәр (Влахов, Флорин, Виноградов, Швейцер һ.б.) реалияләрне тәрҗемә итүнең тагын берничә төрен аерып күрсәтәләр: транскрипция һәм транслитерация; яңа катлаулы сүз уйлап табу; тиңләштерә торган тәрҗемә; контекстуаль тәрҗемә; гипонимик тәрҗемә; реалияне алыштыру.

Реалияләрне тәрҗемә иткәндә, кайбер кыенлыклар белән очрашырга туры килә: тәрҗемә ителә торган телдә тәңгәл килгән сүз, эквивалент, аналог булмавы; реалиянең мәгънәсе белән беррәттән, колоритын, милли һәм тарихи үзенчәлеген бирү зарурлыгы. Нейтраль лексик берәмлекләрдән реалия барлыкка китерә торган күренешне колорит дип атыйлар. Колорит билгеле бер халыкка, илгә, конкрет бер тарихи дәвергә хас булган, аның мәдәниятенә, яшәү рәвешенә генә туры килгән үзенчәлекләрне чагылдыра.

Реалия атамалары транслитерация, функциясе буенча чит тел реалиясенә якын торган күренешне белдергән сүздән файдаланып, аңлатма, тасвирлама бирү ысулы, реалия атамасын әсәр әсәр ахырында урнаштырылган сүзлекләрдә, комментарияләрдә, исемлектә бирелеп тәрҗемә ителә ала.

Р.А.Юсупов фикеренчә, “бер телдән икенче телгә һичьюгында тасвирлау юлы (аңлатмалы юл) белән тәрҗемә ителмәслек сүз юк. Ләкин, оригинал телендәге лексик кыскалыкны саклау һәм бирелгән әйбер яки төшенчәнең специфик характерын күрсәтү өчен, транслитерация алымы кулайрак” [8].

Тәрҗемәчегә реалийларны тәрҗемә итү, яраклаштыру җиңел түгел. Уңышлы тәрҗемә итә алмаса, әсәрнең әдәби доминантасы бозылырга мөмкин һәм укучыга тексттагы концептуаль информация дөрес җиткерелми. Моның ике сәбәбе бар: беренчесе - текстның экзотизациясе, ягъни текстта чит тел сүзләре кирәгеннән артык кулланыла, һәм укучыга текстны кабул итү, аңлау кыенлаша башлый. Икенче сәбәбе – текстның «креолизацисе», ягъни тәрҗемәче текстның мәдәни фонын укучының фон белемнәренә якынайтырга, яраклаштырырга омтыла, әсәрдәге чит мохит югала башлый. Бу бигрәк тә кеше исемнәрен тәрҗемә итүдә күренә: *Mary - Маша, Jonny – Ванюша, Яшка – Jacob, Каштанка – Chestnut Tree, Демьянова уха – Soup of Master John.* Исемнәрне руслаштыру яисә татарчаларштыру бигрәк тә 19 гасыр тәрҗемәләрендә популяр була. «Одиссеи»да мәсәлән, *Зевс – Батька Небес, Геркулес – Ярослав.*

Күп нәрсә тәрҗемәченең субъектив сайлавына бәйле. С. Флорин «Муки переводческие» хезмәтендә: «Как больно только транскрибировать все украинские имена в переводах «Вечеров на хуторе близ Диканьки»: Бульба! Чуб! Ведь это чистая потеря для всех литератур мира» дип аңлата [6].

Этнографик реалияләр – чыганак текстның милли колоритын, үзенчәлекләрен аңлата торган берәмлекләре. Телләрнең лексик-семантик системаларының милли үзенчәлекләргә ия булуы лексик чараларны тәрҗемә итү эшен катлауландыра. Чыганак

сүзенә тәңгәллек табылмау очраклары, нигездә, икенче бер халыкның көнкүрешендә һәм төшенчәләрендә булмаган җирле күренешне белдерә торган сүзләрне тәрҗемә иткәндә була.

Л.Н. Толстойның “Анна Каренина” романында да мондый этнографик реалияләр шактый. Тәрҗемәче аларны шактый уңышлы тәрҗемә иткән: *... но если бы Каренин не назначил своего* ***шурина*** *на это место, то чрез сотню других лиц,* ***братьев, сестер, родных, двоюродных дядей, теток****, Стива Облонский получил бы это место или другое подобное ...* - *... ләкин Каренин бу урынга үзенең* ***каененесен*** *билгеләмәгән булса да, йөзләрчә бүтән кешеләр аркылы,* ***агай-энеләр, апа-сеңелләре, туганнан-туган абыйлары, тутакайлары*** *аркылы ...; Долли задумчиво смотрела мимо* ***золовки****, слушая ее слова – Долли,* ***каен сеңелесенең*** *йөзенә игътибар белән текәлеп карап ....* Рус телендәге свояченица һәм золовка сүзләрен татарча бирү шактый кызыклы һәм авыр, чөнки русча-татарча сүзлектә свояченица – (старшая) каенигәч (хатынның апасы); (младшая) балдыз (хатынның сеңелесе) дип, ә золовка – (младшая) каен сеңел; (старшая) каенигәч дип бирелгән.

Л.Н.Толстойның “Анна Каренина” романындагы этнографик реалияләрнең кайберләрен М. Максуд транслитерация белән генә бирә алган. Алар арасында экономка, кухарка, кучер, повар, риза, шампанское кебек сүзләр бар: *Я что хочешь, только немного,* ***шампанское****. – Ни теләсәң шуны, мин бераз* ***шампанский*** *гына эчәм; Дети бегали по всему дому, как потерянные; англичанка поссорилась с* ***экономкой*** *и написала записку приятельнице, прося приискать ей новое место;* ***повар*** *ушел вчера со двора, во время самого обеда; черная* ***кухарка*** *и* ***кучер*** *просили расчета. – Балалар тәрбиясез калган кебек, бөтен өй буйлап чабалар; англичанка* ***экономка*** *белән әрләште дә, берәр яңа урын караштыруын үтенеп, дус хатынына записка язды;* ***повар*** *кичә көндезге аш вакытында ук инде йорттан китеп барды;* ***кухарка*** *белән* ***кучер*** *расчет сорадылар.* Транслитерация юлы белән бирелгән тәрҗемәләрнең күбесен реалияләрнең татар телендә булган сүзләре белән бирергә мөмкин булыр иде. Мәсәлән, шампанское – шампан шәрабе, кухарка – пешекче хатын дип бирелсә, тәрҗемә уңышлырак булыр иде.

Тәрҗемә ителә алу-алмау мәсьәләсе

Тәрҗемәдәге фон белемнәре тәрҗемә итә алу-алмау мәсьәләсе белән тыгыз бәйләнгән. Әдәби әсәрне тәрҗемә иткәндә, фон белемнәре өч төрле аспектта кулланыла. Беренче чиратта, язучының һәм оригиналны укучының фон белемнәре турында сүз бара. Укучы дигәндә, әлбәттә, теге яки бу колллективка хас стандарт дәрәҗәдә белемгә ия гадәти укучы күз алдында тотыла. Тәрҗемәченең кабул итүе - бу икенче аспекты. Өченче аспект - чит ил кешесенең тәрҗемә аша стандарт күзаллаулар җыелмасы. Әлбәттә, укучы белән тәрҗемәче текстны бөр төрле кабул итми. Шул рәвешле тәрҗемәченең максаты - текстны мөмкин кадәр аңлаешлы итү, шул ук вакытта чит ил тормыш-көнкүрешен чагылдырган әсәрнең сәнгати дөньясын, әдәби матурлыгын, уникальлеген, үзенчәлеген бозарга ярамый. Кызганычка каршы, тәрҗемә практикасы

шуны күрсәтә: тәрҗемәче еш кына укучының фон белемнәрен тиешенчә бәяләп бетерми, яисә кирәгеннән артык бәяли.

Тәрҗемә ителә алу-алмау мәсьәләсе озак еллар бәхәсле сорау булып тора. Тәрҗемә ителә алмый дип санаучы галимнәр, һәр тәрҗемә ул күп төрле югалтуларга дучар була, оригиналга тиң әсәр тудырып булмый, диләр. Тәрҗемә ителә ала дип санаучылар исә, милли төсмерләргә ия булган лексик берәмлекләргә кадәр тулысынча тәрҗемә итәргә мөмкин дигән караштa торалар, моны алар аерым элементлар түгел, ә тулысынча әсәр тәрҗемә ителә дип дәлиллиләр.

«Алиса в стране чудес» әсәрендә гусеницага «сэр» дип эндәшә, рус тәрҗемәсендә (переводчик – Н.М.Демурова) – «сударыня» дип бирелгән. Инглиз теленнән рус теленә, татар теленә тәрҗемә иткәндә, *сез* һәм *син* сүзләрен бирү зур сорау тудыра, чөнки инглиз телендәге *сез* татар һәм рус телләренә *син* һәм *сез* дип бирелә. Әйтик, М.Достоевскийның «Униженные и оскорбленные» әсәрендә Алеша Катя белән дуслыгын түбәндәгечә тасвирлый: *Мы с ней уже теперь на ты*. Тәрҗемәче О.Шарце болай дип тәрҗемә итә: *We call each other Katya and Alyosha.*

Татар телендә дусларга карата якын итеп эндәшеп әйтүне белдергән *малай* сүзе кулланыла. Рус теленә *мальчик* дип тәрҗемә ителсә, мәгънәсе бөтенләй югалачак: - *Каршыма Апуш килә: - Их,* ***малай****, бәхетең бар икән... Исән калган бит, - ди. (Г. Ибраһимов "Алмачуар") - Навстречу шёл Апуш: - Эх* ***брат****! Счастливый ты – жив остался. (Г. Ибрагимов «Чубарый»).*

Тагын бер мисал, мәктәптә, укытучыларга карата *апа, абый* дип эндәшү гадәти күренеш булса да, рус теленә аны турыдан-туры *тетя, дядя* дип әйтү функциональ яктан бөтенләй туры килми: *Абый, Исмәгыйль абый, - дип урыныннан торды Әлтафи, кисәк кенә. – Безнең бит кичә бәрәңге җирендә чиләкләр калды. (М.Мәһдиев "Без кырык беренче ел балалары") – Исмагил Идрисович, неожиданно, вставая с места, заговорил Альтафи. – Вчера на картофельном поле у нас остались ведра (М.Магдиев «Мы – дети сорок первого»)*

Кыш бабай (Дед Мороз) и Санта Клаус үзләренең функцияләре белән туры килсә дә, мәгънәләре аерыла. Яңа ел образында да берникадәр аермалар бар. Рус телендә Новый год – малай образында бирелсә, инглиз телле мәдәниятта иске һәм яңа еллар апалы-сеңелләр. Иске ел – картайган, арган, иске киемнәрдә, кулына калын елъязма-журнал тоткан, Яңа ел – ленталар белән бизәлгән, җиңелчә күлмәк кигән, кулына өмет-хыялларны белдергән розалар салынган кәрҗин тоткан яшь матур кыз образында бирелә.

Мондый күзәтүләрне әкиятләр нигезендә дә күзәтергә мөмкин: рус урманнарында лешийлар яшәсә, татар урманнарында шүрәле көн итә, инглиз урманнарында гоблинннар яши. Инглиз гоблины – кечкенә шайтан, рус лешие – зур гәүдәле кешесыман хайван, җәнлек тиресен ябынган.

Р.Бохараев Г.Тугай шигырьләрен тәрҗемә иткәндә, күп очракта **дини, мифик** реалияләрне транскрипция һәм транслитерация ысуллары ярдәмендә тәрҗемә итә:

Әллә ник истән дә чыккан ,
сүз башым бит ***"Шүрәле"***

How could I forget the title
of this poem is ***Shuraleh?***

Шүрәле- Shuraleh (әлеге реалиянең оригиналдагы фонетик формасы бирелгән. Равил Бохараев әлеге реалияне транскрипция юлы белән тәрҗемә иткән, “ш” хәрефе инглиз телендә ике хәреф белән бирелә “sh”).

Төрле ***албасты, убырлар****, шүрәлеләр бар, диләр...*
Chostly forms like ***albasti***
And ***ub’r*** *and even shuraleh!*

Албасты- albasti , убырлар – ub’r (әлеге реалияләрнең оригиналдагы фонетик формасы бирелгән. Равил Бохараев әлеге реалияләрне транслитерация юлы белән тәрҗемә иткән).

Әдәби текстта тәрҗемә итә алу-алмау мәсьәләсе үзенчәлеккә ия, чөнки тарих, көнкүреш өлкәләренә караган реалияләр белән дә эш итәргә туры килә, әсәрнең уникальлеген тәэмин иткән образлар, элементлар белән дә очрашырга туры килә. Күп кенә галимнәр гомуми тел нормасына туры килмәгән аерым сүзләр генә тәрҗемә ителә алмый дип саныйлар. Болар - диалектизмнар, билгеле бер урынчылыкны, җирле бизәккә ия булган жаргонннар, «варваризмнар» ягъни башка телдән кергән чит тел сүзләре, сүзләрне үзгәртеп, бозып сөйләү. Мәсәлән, Крылов кулланган «*Лабердан!» или «вояжировка»*; *«ваперы да мигрень»* сүзләрен турыдан-туры тәрҗемә итеп булмый, тәрҗемәдә мондый элементларның комизмы югала, әлбәттә.

М.Мәһдиевнең «Без кырык беренче ел балалары» әсәрендә, укытучылар рус сүзләре кыстырып сөйләшәләр *«ребятки, пнимаеш, шту син…»*Мәсәлән, рус теле укытучысы балаларга «*ребятки*» дип эндәшә. Рус теленә тәрҗемәсендә дә ул *ребятки* буларак бирелә. Шул ук әсәрдә зоология дәресендәге бер күренештә Әркәшә ата кара тараканның кан әйләнеше турында сөйләгәндә тотылыгып, каушап, сүзләрне бутап бетерә: *«Ата кара таракаттык… Кара ата таракаттык… гаять… гаять….»* Тәрҗемәдә гади генә итеп, *«Кровообращение черного таракана очень… » первое предложение для Аркаши стало капканом»* - дип бирелә, һәм Әркәшәнең кичергән хис-тойгылары, каушавы автор сүзләре аша җиткерелә.

Милли-мәдәни компонентлар реалийлардан тыш, фразеологизмнар, ымлыклар һ.б. лексик-грамматик чаралар аша да белдерелә. Мәсәлән, иркәләп-кечерәйтеп әйтүне белдергән кушымчалар, сүзләр төрлечә тәрҗемә ителәләр: ингл.: *honey (бал) – дорогая, кадерлем, duck (утка) – зайка, куяным.*

Мәдәниятккә, традицияләргә, гомумән, чит ил цивилизациясенә бәйле төшенчәләрне игътибарсыз калдырырыга ярамый.

Димәк, тәрҗемәнең тагын бер мөһим өлеше булып, тәрҗемә иткәндә милли колоритны саклап калу тора. Чөнки башка халыклар сүзнең нәрсә турында барганын кузалларга, аңларга тиеш. Милли колорит сакланмаса, укучы сүзнең мәгънәсенә тулаем төшенеп, нәрсә турында сүз баруын әйтеп бирә алмас иде.

Список литературы

1. Алексеева И.С. Введение в переводоведение: Учеб. пособие для студ. филол. и лингв. фак. высш. учеб. заведений / И.С.Алексеева. – СПб.: СПбГУ; М.: Издательский центр “Академия”, 2004. – с 181.

2. Кыйблага тугрылык: Әдип һәм тәрҗемәче Кыям Миңлебаевка 75 яшь тулуга багышланган библиографик мәгълүматлар һәм мәкаләләр җыентыгы (Мөхәррире И.Г.Һадиев). – Казан: Милли китап, 2004. – 139 б.

3. Казакова Т. А. Художественный перевод. Теория и практика. - Инъязиздат, 2006.

4. Нәбиуллина Г.Ә., Мөгътәсимова Г.Р. Тәрҗемә практикасы: әдәби һәм фольклор тәрҗемәләре. Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы. - Казань: Ихлас, 2012. – 91 б.

5. Попович А. Проблемы художественного перевода / А. Попович. – М.:Выш. шк., 1980.

6. Флорин С. Муки переводческие. Практика перевода. – М.: Высш. шк., 1983. – 184 с.

7. Фененко Н.А. Язык реалий и реалии языка. - Воронеж, 2001.

8. Юсупов Р.А. Тәрҗемә һәм сөйләм культурасы / Р.А.Юсупов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008 -74 б.

Рекомендуемые информационные ресурсы

1. Войнич И.В. Стратегии лингвокультурной адаптации художественного текста при переводе : автореф. дис. … канд. филол. наук / Войнич И.В. ; [Перм. гос. техн. ун-т]. - Пермь, 2010. - 19 с. ; То же [Электронный ресурс]. - URL: http://www.psu.ru/psu2/files/0503/Voinich_27_05_10.doc (18.11.2011).

2. Шәйхетдинова Г.И. Татар реалияләрен инглиз теленә тәрҗемә итү ысуллары (Равил Бохараев тәрҗемәләре мисалында) http://shelly.kpfu.ru/e-ksu/docs/F1337688815/%D0%E5%E0%EB%E8%FF%20%D0%E0%E2%20%C1%F3%F5%20.pdf

3. http://nsportal.ru/shkola/rodnoi-yazyk-i-literatura/library/tukaynyn-trzhem-eshen-monsbte

4. http://russian-tatar.ru/

5. http://tatpoisk.net/dict/rus2tat/

Лекция № 5.

ӘДӘБИ ТӘРҖЕМӘНЕ ХРОНОЛИК ТӘҢГӘЛЛӘШТЕРҮ МӘСЬӘЛӘСЕ

Аннотация. Данная тема раскрывает особенности хронологической адаптации художественного текста при переводе.

Ключевые слова. Хәзерге әдәбиятны тәрҗемә итү, искергән сүзләр, тарихи сүзләр, арихаизмнар, «архаизация» алымы, «модернизация» алымы.

Методические рекомендации по изучению темы.

- Тема содержит лекционную часть, где излагаются проблемы хронологической адаптации художественного текста при переводе.
- В дополнение к лекции имеется презентация.
- Для проверки усвоения темы имеются вопросы для изучения, также необходимо выполнить задание и отправить на проверку.

Вопросы для изучения

Проблема хронологической адаптации в художественном переводе.
Историзмы и архаизмы в оригинале и переводе.
Перевод классических произведений.
Передача устаревшой лексики в исторических романах.

Төрле сәбәпләр аркасында (сүзнең аерым бер мәгънәсе югалу, теге яки бу төшенчәнең телдән бөтенләй югалуы) кулланылыштан төшеп калган сүзләр тел гыйлемендә искергән сүзләр рәтендә өйрәнелә. Мондый сүзләрне тарихи сүзләр дип атыйлар. Алар белдергән төшенчәләрнең башка исемнәре юк, бу төшенчә үзе инде телдә кулланылмый. Мәсәлән, *патша, хан, алпавыт, морза, ясак* һ.б.

Тарихи сүзләр халыкның үткәнен иҗтимагый-сәяси тормышка караган сүзләр (*җария - рабыня, сарайби - придворный, пайтәхет, ханбалык - столица, карачы - высший сановник, бәк - князь*) аша, хәрби лексика (*йөзбашы - сотник, чирү - войско, кыны - футляр, кирмән - военный лагерь, алай - отряд*), савыт-саба атамалары (*чапчак - кадка, аяк - сосуд, кубәтә - ёмкость для супа, таскак - деревянная полка*), кием-салым атамалары (*көбә күлмәк - военная одежда из железа, очлым - головной убор, тирлек - нижнее белье, көртәй - одежда из меха*) аша чагылдыралар.

Искергән сүзләрнең тагын бер төркеме - архаизм - нинди дә булса бер төшенчәнең искергән атамасы. Мондый искергән сүзләр урынына телдә яңалары кулланыла башлый, мәсәлән, утлап йөрү сүзтезмәсендә эзләре сакланып калган ут сүзе, исем мәгънәсендә *ат* сүзе (*атказанган, атаклы* сүзләрендә сакланган), көн сүзе дә кайчандыр кояшны белдергән. Матур әдәбият әсәрләрендә, чор үзенчәлекләрен бирү максатыннан, архаизмнар актив кулланылалар.

Архаизмнарның семантик, фонетик һәм морфологик төрләре бар. Семантик архаизмнарның бер генә мәгънәсе искергән була: *ярык* сүзенең яктылык мәгънәсе искереп, ачыклыкны белдергән мәгънәсе генә сакланган. Фонетик архаизмнар аваз составы ягыннан аерылалар: *сарыг - сары, тулуг - тулы, еглау - елау*. Морфологик архаизмнарның формасы гына искергән була: *укымак - укырга, килмеш - килгән*.

Узган гасырның классик әсәрләрен укып, без үткән тормыш атмосферасына чумып, бүгенге көннәрдән аерылып торган чор аермасын тоябыз. Оригиналның билгеле бер вакытка, чорга каравы тәрҗемәдә ни дәрәҗәдә әһәмияткә ия соң?

Бу сорауга җавап бирер алдыннан, тәрҗемәдә вакыт мәсьәләсенә ачыклык кертеп узарга кирәк. А.Попович фикеренчә, тәрҗемә гыйлемендә вакыт дигәндә, тәрҗемә һәм оригиналның төрле чорларда язылуына бәйле факторларны билгеләүче коммуникатив шартлар аермасы күз алдында тотыла [8]. Биредә ике төп тәрҗемә тибын аерып күрсәтергә кирәк: хәзерге әдәбиятны тәрҗемә итү («тарихи синхрон тәрҗемә») һәм заманнан ераклашкан әсәрләрнең тәрҗемә итү.

Хәзерге әдәбиятны тәрҗемә итүче замандашын, чордашын яңадан кабатлый, ә классик әсәрләрне тәрҗемә итүче вакыт яссылыгында автордан азмы-күпме ераклашкан була. Нәтиҗәдә, чор колоритын белдергән элементларны, реалийларны белү зарури. Бу очракта ике тәрҗемә методы кулланыла: берсе «архаизация», икенчесе «модернизация» алымы дип атала. Аерым лексик берәмлекләрнең тәрҗемәсендә карап үтик: *туташ-сударыня, барыня, госпожа; әни* - *маменька, матушка, мама; пәлтә – манто, пальто, салоп.*

Тәрҗемәдә махсус рәвештә оригиналның вакыт ягыннан хәзерге чордан, телдән аермасына, ягъни тарихилыкка басым ясалырга мөмкин, яисә киресенчә хәзерге чорга яраклаштырып тәрҗемә ителергә, нәтиҗәдә, вакыт каршылыгы тулысынча юкка чыгарга мөмкин.

В.Н.Комиссаров хаклы рәвештә билгеләп үткәнчә, архаик сүзләр, формалар ярдәмендә әсәрнең чор рухын, тарихилыгын саклап калу әһәмиятле [4: 30]. Тәрҗемәче алдында вакыт аермасы, архаизация һәм модернизация алымнарын ни дәрәҗәдә куллану кебек сораулар килеп баса. Татар тәрҗемә гыйлемендә хронологик тәңгәлләштерү, тарихи-мәдәни мәгълүматны чагылдыру мәсьәләсе, С.Файзуллин, Р.Ю. Юсупов, К.С. Миннибаев, Л.К. Байрамова һ.б. хезмәтләрендә билгеле бер күләмдә яктыртылган булса да, бу турыда махсус язылган тикшеренүләр юк дәрәҗәсендә. Тарихи романнарның тәрҗемәсенә күз салсак, теге яки бу лексемада тарихи колоритның чагылышын күрергә мөмкин. Мисал өчен Н.Фәттах, М.Хәбибуллин, Р.Батулланың тарихи романнарда һәм аларның тәрҗемәләрендә күпсанлы искергән сүзләрнең кулланылышын күрәбез: атак 'известность', аркыш 'караван', калуг 'ворота', улак 'лодка' , ат 'имя', баба 'дед', олан 'ребенок', ут 'трава' һ.б. Тарихи берәмлекләр арасында татар халкының тарихын, иҗтимагый-сәяси тормышын, хәрби өлкәне, тормыш-көнкүрешне, гаилә, туганлык атамаларын чагылдырган сүзләр шактый булуы күзгә ташлана:

1) иҗтимагый-сәяси лексика (карабаш 'рабыня', тамга 'печать'); военная лексика (азат 'воин',албагар 'дозорный', атчабар 'гонец' и др.);

2) һөнәр, шөгыльне белдергән атамалар (базарган 'купец', битекче 'писарь', каравыш 'служанка' и др.);

3) көнкүреш лексикасы (агыл 'загон для скота', агылык 'помещение, где хранится казна' и др.);

4) туганлык атамалары (аба 'старший брат', ага 'дядя' и др.).

Күренгәнчә, әсәрне тәрҗемә иткәндә, аның «яшен» исәпкә алу зарур. Бу бигрәк тә лексик тәңгәллекләр сайлап алганда әһәмиятле. Шунысын да исәпкә алырга кирәк: күп

кенә тарихи сүзләр укучы өчен аңлашылып бетмәскә мөмкин. Бу очракта комментарийларга мөрәҗәгать итү урынлы.

Искергән сүзләрне тәрҗемә иткәндә, түбәндәге алымнар кулланыла:

1. Эквивалент тәрҗемә:

Кем бар анда? Ни сэбэптэн акыра тоткавыл? — диде турэ. - Эмир потребовал узнать, почему вопят привратники [Сююмбике— царица казансая 2001 65]

2. Эквивалентсыз тәрҗемә: транслитерация, калькалаштыру, тасвирлама тәрҗемә; аңлатма бирү, лексик-семантик алмаштыру, төшереп калдыру.

Мәсәлән, - Улакчы килде, улакчы,- диде Чынташ Ашыгыч битек китергэн. - Улакчи прибыло ответил стражник - Доставил важный битэк [Ител суы ака торур [Итиль- река течет 1980 83]

Кайбер очракларда тарихи сзләр тәрҗемә теленең тарихи сүзләре белән тәрҗемә ителергә мөмкин: яргу — суд (тяжба), яугир — воин (воякъ), диван — собрание (вечье), пыскый - факел (лучина), улак- лодка (челн). Бу ысул тарихи колоритны, чор рухын, тарихи романга хас жанр үзенчәлекген сакларга ярдәм итә.

Чор үзенчәлекләрен чагылдырган берәмлекләр реалияләр аша да белдерелергә мөмкин:

Мәсәлән, А.А.Блокның бер шигырендә шундый юллар бар:

Вагоны шли привычной линией,
Подрагивали и скрипели
Молчали желтые и синие
В зеленых плакали и пели.

Биредә вагон төсләре пассажирлар классын белдерә, (1, 2, 3 - желтый, синий и зеленый). Тәрҗемәче шушы реалияләрнең мәгънәсенә төшенеп, тәрҗемәдә чор үзенчәлекләрен сакларга тиеш.

Хәзерге әдәбиятны тәрҗемә иткәндә, тәрҗемәче шулай ук реалияләр белән эш итә, ләкин кагыйдә буларак, җирле бизәк булып торалар. Бу әсәрләр киләчәктә тәрҗемә ителсәләр, бу реалиялардан вакыт ягыннан ераклашу проблемасы килеп туачак һәм замана укучысы өчен аларның мәгънәсен аңлау кыенлаша. Шуңа күрә тәрҗемәче, текстны экзотизмнар җыелмасына әйләндерергә тиеш түгел, икенчедән, чор колоритын саклап эш итәргә тиеш. Тәрҗемә әсәре архаик әсәр булырга да, борынгы әдәби ядкарь, хәзерге язучының тарихи әсәре булырга да мөмкин.

Югарыда әйтелгәнчә, элек иҗат ителгән әсәрләр күп тапкырлар тәрҗемә ителгән һәм хәзер дә зур вакыт аермасы белән тәрҗемә ителеп килә. Бу әсәрне язучылар шул чорга хас телдә язганнар, шул чорга хас реалияларны кулланганнар. Нәтиҗәдә, тәрҗемәче өчен алдында ике яклы проблема килеп туа: автор иҗат иткән чор һәм хикәяләү чоры.

Шуның белән бергә тәрҗемәче алдында тәрҗемә эше барышында оригиналның тарихи дөреслеген саклау мәсьәләсе килеп баса. Тәрҗемәче әсәрне төрлечә тәрҗемә итәргә мөмкин: әсәрдәге тарихилыкка басым ясарга, вакыт аермасын чагылдырырга яисә

аны заманчалаштырып, хәзерге телгә яраклаштырып үзгәртергә мөмкин. Беренче очракта «архаизация» принцибы саклана, икенче очракта «модернизация» принцибы.

Хәзерге заманнан ераклашкан әсәрләрне тәрҗемә иткәндә, тәрҗемәче һәр сүзнең “яшь үзенчәлекләрен” исәпкә алырга тиеш, стилистик кулланылышына бәйле рәвештә тарихи сүзләр, архаик чаралар белән эш итү зарур.

Бөек әдипләрнең күренекле әсәрләрен бер телдән икенчесенә тәрҗемә итү кызыклы һәм кирәкле гамәл исәпләнә. Шунлыктан классик әсәрләрнең берничә телгә тәрҗемәләре бар, ә кайберләренең бер үк телдә дә берничә тәрҗемәсе булырга мөмкин.

Список литературы

1. Виноградов В. С. Темпоральная (временная) стилизация как переводческий прием // Филологические науки, 1997. - № 6. - С. 54-59.
2. Зәкиев М.З. Классик әсәрнең тәрҗемәсе // Совет әдәбияты . – 1952. №2. - Б.119-122.
3. Казакова Т. А. Художественный перевод. Теория и практика. - Инъязиздат, 2006.
4. Кыйблага тугрылык: Әдип һәм тәрҗемәче Кыям Миңлебаевка 75 яшь тулуга багышланган библиографик мәгълүматлар һәм мәкаләләр җыентыгы (Мөхәррире И.Г.Һадиев). – Казан: Милли китап, 2004. – 139 б.
5. Комиссаров В.Н. Современное переводоведение: Учеб. пособие / В.Н. Комиссаров. – М.: ЭТС, 2004. – 420 с.
6. Любимов Н. М. Перевод – искусство. - М., 1982.
7. Нәбиуллина Г.Ә., Мөгътәсимова Г.Р. Тәрҗемә практикасы: әдәби һәм фольклор тәрҗемәләре. Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы. - Казань: Ихлас, 2012. – 91 б.
8. Попович А. Проблемы художественного перевода / А. Попович. – М.:Выш. шк., 1980.
9. Юсупов Р.А. Соотношение разноструктурных языков и вопросы перевода/ Р.А. Юсупов. – Казань: 2005. - 225 с.

Рекомендуемые информационные ресурсы

1. Ланчиков В. К. Историческая стилизация в синхроническом художественном переводе. http://www. thinkaloud. ru/sciencelr. html.
2. http://nsportal.ru/shkola/rodnoi-yazyk-i-literatura/library/tukaynyn-trzhem-eshen-monsbte
3. http://russian-tatar.ru/
4. http://tatpoisk.net/dict/rus2tat/

Задания для практики по теме 3

Задание 3.1 А.С. Пушкинның “Зимний вечер” шигыреннән алынган өзекнең тәрҗемәләрен чагыштырыгыз. Чорга хас тел үзенчәлекләре ни дәрәҗәдә чагылыш табуын мисаллар нигезендә дәлилләгез.

Зимний вечер

Буря мглою небо кроет,
Вихри снежные крутя;
То, как зверь, она завоет,
То плачет, как дитя,
То по кровле обветшалой
Вдруг соломой зашумит,
То, как путник запорздалый,
К нам в окошко застучит.
(А.С. Пушкин, 1825).

Кышкы буран

Күкне тәмам каблаган
Буран караңгылыгы.
Карлы давыл бүредәй
Улый, баладай җылый,
Иске түбәгә менеб,
Шаулата саламларын,
Гәh[1] кичекгән юлчы күк,
Кага тәрәзә рамларын.
(Г.Рахманколый, 1906).

Кышкы төн

Буран өермә бөтерәдер,
Уйный, кар җирдән ала;
Йә җанварлардай үкерәдер,
Йә егълый гүя бала.
Йә бер крыша ябучыдай,
Түбә саламын чәчә,
Йә кич калган бер юлчыдай,
Тәрәзә капкачын әчә. (Дәрдмәнд, 1900).

Кышкы кич

Күкне буран чорнап ала,
Ак карларны туздыра.
Я бала кебек елый ул.
Я ерткычтай ыжгыра.
Я менә дә өй башына
Саламны селкетә ул,
Я соңлаган юлчы кебек,
Тәрәзәне чиртә ул.
(Ә.Ерикәй, 1940).

Кышкы кич

Өермәләр күкне каплый,
Җил карларны бөтерә,
Я балалар төсле елый,
Я ерткычтай үкерә.
Я ул түбәнең тузгыган
Саламын кыштырдата,
Я ул кичеккән юлчыдай,
Тәрәзә шакылдата.
(С.Баттал, 1949)

Кышкы кич

Каплый күкне җил дә давыл,
Кар, буран уйнап йөри,
Бер бүре кебек улый ул,
Бер бала кебек елый.
Я кинәт кыштырдый капшап, -
Йорт саламын туздыра,
Я шакый тәрәзәне, охшап
Соңга калган юлчыга.
(М.Садри, 1949)

[1] Гәh – әле, кайчак, кайчакта.

Задание 3.2 Л.Н.Толстойның “Юность” әсәрендә кулланылган реалияләрне табыгыз һәм тәрҗемәдә биерелешен тикшерегез.

1) Он сшил себе модное платье – оливковый **фрак,** модные **панталоны** со штрипками и длинную **бекешу,** которая очень шла к нему… — Папа үзенә модалы киемнәр – яшькелт-сары **фрак** белән тасмалы, модалы **панталон,** өстендә ятып торган озын **бекеша** (биле бөрмәле бишмәт) тектерде... 2) Теперь она мечтала уже выйти замуж не за **гусара,** а за певца или музыканта и с этой целью усердно занималась музыкой. — Хәзер инде ул, **гусарга** чыгам дип түгел, бәлки берәр җырчыга яки музыкантка чыгам, дип хыяллана һәм шуңа күрә музыкага чынлап торып өйрәнә иде. 3) Духовник стал перед **налоем** и медленно обратил ко мне свое лицо. — Тәүбә кылдыручы **налой** (иконалар һәм дини китаплар куя торган авыш өстәл) алдында тора иде, ул ашыкмый гына миңа таба борылды. 4) Я узнал от Николая, потому что **папа** ничего не рассказывал нам про свои игорные дела, что он особенно счастливо эту зиму; выграл что-то ужасно много, положил деньги в ломбард и весной не хотел больше играть. — Мин бу кышны **папаның** картадан бәхете булганын Николайдан ишеттем, чөнки **папа** үзе уйнавы хакында безгә бер сүз сөйләмәс иде, искиткеч күп откан акчасын да **ломбардка** салган, ә язын башка уйнамаска булган. 5) В одной руке я держал изорванную мягкую «Алгебру Франкера», в другой – кусок мела, которым испачкал уже обе руки, лицо и локти **полуфрака. —** Бер кулымда Франкерның ертылып, таушалып беткән “Алгебра”сы, икенче кулымда кеп-кечкенә бур, аның белән инде мин кулларымны да, битемне дә, **кыска фрагымның** җиңнәрен дә буяп бетергәнмен. 6) Но так, как линейки у меня не нашлось, я употребил для этого **латинский лексикон. —** Линейка тапмаганга **латин лексиконын** кулландым. 7) Иногда возьму с собой что-нибудь закусить: сыру, или **пирожок** от Педотти, или что-нибудь. — Кайвакыт анда капкалап алырга берәр нәрсә: сыр яисә Педоттидан **пирожок**, я булмаса берәр нәрсә алып барырмын. 8) Я чувствовал себя снова в том бесконечно веселом расположении духа, в котором я пять лет тому назад танцевал с ней **гросфатер** на бабушкином балу. — Мин моннан биш ел элек әби балында аның белән **гросфатер танцевать** иткәндәге шикелле гамьсезлек чамалап алдым, күңелле булып китте. *(К.Миңлебаев тәрҗемәсе).*

Задание 3.3 Г.Тукайның “Китмибез” (1907) шигырен укыгыз, искергән сүзләрне табып тәрҗемәдә бирелешен тикшерегез. Сезнеңчә тарихилык саклангонмы?

Китмибез

Кара йөзләр безне булмас эшкә тәклиф иттеләр:
— Сезгә монда юк ирек, солтан җиренә кит! — диләр.

Китмибез без, безгә анда мондагыдан эш кыен:

Мондагы ун урнына ул җирдә унбиш шпион.

Мондагы төслүктер анда һәм казаклар гаскәре;
Камчылар — шул иске камчы, башкалык — тик фәсләре!

Анда бит бардыр хәзинәне талаучылар, шөкер;
Ач мужиктан соң кисәкне тарткалаучы бар, шөкер!

Без җүләрме, үзебезне утка илтеп ник терик?
Бу кызу җирдән чыгып, тагын сәкарьгә ник керик?

Без күчәрбез, иң элек күчсен безем әмсарымыз,
Һәм дә кайтсын монда үткәргән безем әгъсарымыз.

Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл;
Бәйләмеш бу җиргә безне Тәңребез (Гыйззе вә Җәл).

Иң бөек максат безем: хөр мәмләкәт — хөр Русия!
Тиз генә кузгалмыйбыз без, и гөруһе русияһ!*

Ап-ачык бу бер җаваптыр, сүздә түгел, басмада:
— Если лучше вам,
Туда сами пожалте, господа!**

**Гөрүһе русияһ — кара йөз димәктер (фарсыча) (Г.Тукай искәрмәсе).*
***Сезгә яхшырак булса, үзегез шунда рәхим итегез, әфәнделәр.*
Тәклиф итү — катгый рәвештә тәкъдим итү.
Сәкарь — тәмуг.
Әмсар — шәһәрләр.
Әгъсар — гасырлар буенча үткән еллар.
Гыйззе вә Җәл — кодрәтле һәм шанлы.

Не уйдем! (Пер. Р.Бухараева)

Кое-кто с кривой душою нам пустой дает совет:
Уходите в край султана, здесь для вас свободы нет!

Не уйдем! Горька отчизна, но в чужбину не уйдем!
Вместо десяти шпионов там пятнадцать мы найдем!

Что за разница, казаки ль там нагайкой бьют сплеча,
Там казачье войско в фесках, но камча — везде камча!

Слава богу, казнокрады и в чужбине есть пока,
И в чужбине баи рады рвать кусок у мужика!

Разве мы ума лишились, чтобы, родину кляня,
В полымя бежать чужое из привычного огня?!

Мы уйдем, когда за нами вдаль уйдут и города,
Цепь лихих тысячелетий, наши горькие года.

От рожденья до кончины за родной живя чертой,
Мы срослись навеки плотью с почвой родины святой!

Вольная страна Россия — наша цель, и до конца
Не уйдем, и не зовите, криводушные сердца!

Отвечаем не изустно, но в печати - навсегда:
Если лучше вам, туда пожалте сами, господа!

ТЕМА 4. ӘДӘБИ ТӘРҖЕМӘ ПРИНЦИПЛАРЫ

Лекция № 6

Аннотация. Данная тема раскрывает основные принципы художественного перевода.

Ключевые слова. Тәрҗемәнең төп принциплары, тәрҗемә эшчәнлеге, әдәби тәрҗемәнең адекватлыгы, әдәби тәрҗемә механизмнары, әдәби-эстетик юнәлеш, лингвистик юнәлеш, эчтәлек берлеге принцибы, стилистик берлек принцибы, иҗадилык принцибы, эстетик тәэсир итү.

Методические рекомендации по изучению темы.

- Тема содержит лекционную часть, где излагаются основные принципы и направления художественного перевода в связи с эволюцией переводческих принципов.
- Для проверки усвоения темы имеются вопросы для изучения, также необходимо выполнить задание и отправить на проверку.

Вопросы для изучения

Истоки литературной переводческой концепции.
Основные направления художественного перевода.
Принципы художественного перевода.

Принцип содержательной общности.
Принцип стилистической общности оригинала и перевода.
Принцип эстетического воздействия.
Принцип адекватного освоения и выражения художественного творения.

Әдәби тәрҗемә концепциясенең башлангычы

Тәрҗемәнең төп принциплары барлык телләр, тәрҗемә ителә торган барлык материал өчен уртак. Иң мөһиме – төп нөсхәнең эчтәлеге һәм формасы берлеген мөмкин кадәр тулырак саклау бурыч итеп куела. Тарихи яссылыкта караганда тәрҗемә принциплары, тәрҗемәгә куелган таләпләрнең үсеш-үзгәреше күзгә ташлана.

Тәрҗемә принциплары турында күп кенә фәнни-теоретик хезмәтләрдә өйрәнелә. Тәрҗемә гыйлеме тарихында төрле принциплар алга сөрелә: кайбер галимнәр оригинал мөмкин кадәр тулы, төгәл булырга тиеш дип санаганнар, икенчеләр исә иҗади булырга тиеш дигән таләпне куйганнар. Совет тәрҗемә практикасында бу ике таләпне да нигез итеп алган тәрҗемә үрнәкләре барлыкка килә.

Матур әдәбиятны тәрҗемә итү – катлаулы өлкә. Аның бурычы белем, мәгълүмат бирү генә түгел, матур әдәбият теле күңелгә хуш килүе белән дә матурлык хисе тәрбияләргә һәм укучы тарафыннан яратып укылырга тиеш. Матур әдәбият тәрҗемәсенә куелган принциплар В.Г. Белинский, Ф. Батюшков, А.Агатов, татар тәрҗемә гыйлемендә Г. Ибраһимов, Г.Хәбиб, И. Гази, Г. Кутуй, С. Фәйзуллин, Р. А. Юсупов, Г. Хантимерова һ.б. хезмәтләрендә өйрәнелә.

Әдәби тәрҗемә мәсьәләләре белән кызыксыну XIX гасыр ахыры – XX гасыр башларына туры килә. Моңа, беренчедән, русчадан тәрҗемәләрнең саны арту, икенчедән, татарлар арасында рус теле укытыла башлау этәргеч ясый. Әдәби тәрҗемә мәсьәләләрен өйрәнүчеләр, нигездә, матур әдәбиятны тәрҗемә итү белән шөгыльләнгән авторлар – шагыйрьләр, язучылар, әдәбият белгечләре, тәнкыйтьчеләр. Бу чорда махсус фәнни хезмәтләр язылмаса да, татар матбугаты битләрендә тәрҗемә мәсьәләләрен яктырткан күпсанлы мәкаләләр басылып чыга. Мәкалә авторлары тәрҗемә практикасын нигезләргә, төп принципларын билгеләргә омтылыш ясаганнар.

Әдәби тәрҗемә өлкәсендә күренекле әдип, телче галим һәм педагог Каюм Насыйриның үз чорында әйтеп калдырган гаять төпле фикерләре бүген дә үзенең актуальлеген югалтмый. Ул һәр телнең үзенчәлекләре барлыгын, тәрҗемәдә менә шуны исәпкә алырга кирәклеген күрсәтә: «Мәгънәсе-эчтәлеге... тәрҗемә кылыначак шигырь, бәет һәм башкалар икенче телдә тәфсилләп бирелмәсә, икенче телдәге мәгънәсендә ул ләтафат булмас. Телдән-телгә күчергәндә, бу хикмәтне белмәк лазем”.

Тәрҗемә эшчәнлеге белән шөгыльләнгән Г. Тукай “Русчадан дөрес тәрҗемәләр” дигән памфлетында мәсәлән, чит телнең формасын күчерүчеләрне нык тәнкыйтьләп, халыкчан, аңлаешлы, югары сәнгатьле тәрҗемә принцибы ягында тора.

С. Сүнчәләй, 1913 елда Г. Гейненың “Әлмансури” әсәрен тәрҗемә иткәндә, үзе дөрес дип тапкан тәрҗемә алымын болай дип нигезли: “Әлмансурины” тәрҗемәгә

күчергәндә, кайбер урыннарын төшергәләдем, кыскарткаладым һәм үзгәрткәләдем, кайсыбер урыннарын арттыргаладым, озайтыбрак, ачыграк итеп “милли” итәргә тырыштым, асылыннан читкәрәк китеп булса да. миллирәк эшләргә теләдем һәм максатыма ирештем дә бугай”. XX йөз башында “милләтләштерү” тәрҗемә эше өчен характерлы үзенчәлек булып тора. Бу чорда тәрҗемә ителгән А.С. Пушкин, И. А. Крылов, Н.А. Островский, Л.Н. Толстой һәм башка классик рус язучылары әсәрләре шундый өстәү-кыскартулар, үзгәртүләр белән тәрҗемә ителгәннәр.

Тел үсешендәге зур борылыш вакытында тәрҗемәчеләр алдына тәрҗемә мәсьәләләрен генә түгел, тел мәсьәләсен дә хәл итү бурычы килеп баса. Гарәп-фарсы теле белән чуарланган язма әдәби телне халык теленә якынайту, алардан арыну, үз телебездә эквивалент табу кирәк була. Мондый шартларда рус теленнән татар теленә тәрҗемә мөмкинлекләре чикләнгән, татар телен ярлы дип карауларчылар да була. Кайбер буржуаз тәнкыйтьчеләр “... безнең әдәби телебез юктыр... Урам телләре илә Толстойны, Золяны, Гюгоны тәрҗемә итеп булмый”, - дип язып чыгалар (“Йолдыз” газетасы, 1906, 22 февраль). Тәрҗемә мәсьәләсенә кагылышлы мәкаләләрдә сүз, башлыча, тәрҗемәнең авырлыгы турында бара.

Г. Хәбиб үзенең 1926 нчы елда басылган мәкаләсендә заманы өчен шактый әһәмиятле фикерләр әйткән. Галим тәрҗемә практикасында кулланылган 3 принципны күрсәтә:

1) Төп язучының аерым-аерым сүзләрен җәяләр эченә алып, сүзгә-сүз тәрҗемә итү, тешкә йомшаграк җер сүз чыкса, шул уңайдан файдаланып, битләрчә сүз боткасы пешерү... Бу юл дини китапларны тәрҗемә итүдә йөртелә торган ташландык бер юл;

2) Төп оригиналдагы сүзләрнең турыдан-туры лөгать мәгънәләрен саклап, җөмләне җөмләләп тәрҗемә итү. Бу да мактаулы бер юл түгел, аңлануны авырайта торган юл;

3) ...халыкчыл уйлап, шул халыкның сүз сөрешенә, җөмлә төзелешенә туры китереп тәрҗемә итү. Берничә җөмләне бергә генә калдырырыга, читләтеп әйтелгән сүзләрне турылап, турылап әйтелгән сүзләрне читләтеп әйтергә мөмкин. Монда иң төп язучының әйтергә теләгән нәрсәсен тулы рәвештә бирүне генә күздә тотарга. Минем үземчә, тәрҗемәдә иң туры һәм иң файдалы юл шушы соңгысы булырга тиеш.

Әлбәттә, әйтелгәннәрдә фикер төгәлсезлекләре бар. Автор ни өчендер хәзерге терминологиядә иректә тәрҗемә дип йөртелә торган юлны сүзгә-сүз тәрҗемәне һәм җөмләгә-җөмләне тәрҗемә итүне яраксыз дип таба, ләкин шул ук вакытта кыскартып тәрҗемә итүне (оригиналның синтаксисын җимерүне) яклап чыга.

Егерменче елларның азагына кадәр ижтимагый-сәяси, фәнни-популяр тәрҗемәләр өстенлек алып торса, соңга таба әдәби тәрҗемәләр активлаша. Һәм тәрҗемәне теоретик өйрәнү дә шул юнәлештә дәвам итә. (Бу чорларда тәрҗемә төрләре аерып каралмый). Әдәби тәрҗемә мәсьәләсен өйрәнеп язылган аерым күзәтүләр барлыкка килә. Язучы Г. Кутуй үзенең “Тәрҗемә әдәбият турындагы”(1930) мәкаләсендә әдәби тәрҗемәнең төп принципларыннан берсе итеп, “тәрҗемәнең оригиналга җавап бирерлек дәрәҗәдә дөрес” булырга тиешлеген әйтә.

И. Гази үзенең “Тәрҗемә принциплары турында”гы мәкаләсендә (“Совет әдәбияты”, 1936, №3) әдәби тәрҗемәнең адекватлыгын билгели торган критерийлар итеп түбәндәгеләрне күрсәтә:

1) Мәгълүм бер эпоха өчен характерлы әсәрне тәрҗемә иткәндә, (мәсәлән, Бальзак әсәрләрен) шул эпоханы билгели торган бөтен үзенчәлекләр. Шул эпохага гына хас моментлар тулы көенчә тәрҗемәгә күчәргә тиеш. Шунсыз әсәрнең познавательный кыйммәте юкка чыгачак;

2) әсәрнең эчтәлеге, идеясе, тулы, дөрес алынырга тиеш;

3) әсәрдәге образлар – типларның мәгънәләрен дөрес аңлап тулы һәм дөрес гәүдәләндерергә кирәк;

4) заманның лексик үзенчәлеге сакланырга тиеш.

Язучы, бу критерийларны бербөтен итеп карарга кирәклеген искәртә: «Әсәрнең идеясе образ аркылы һәм шул образны билгели торган художество үзенчәлекләре аркылы бирелә, - ди ул, - образ үзе дә әсәрнең идеясен тулы чагылдыру өчен генә хезмәт итә».

Әлеге хезмәтләрдән күренгәнчә, әдәби тәрҗемәнең алымнары тәрҗемәчеләрнең, тәрҗемә белгечләренең игътибар үзәгендә булган. Тәрҗемәнең әдәби һәм тел ягына кагылышлы төп мәсьәләләр, әдәби тәрҗемә механизмнары тикшерелә, әдәби тәрҗемә процессында идея, эчтәлек, чор үзенчәлекләре, төп фикер бирелеше, образ, тойгы бирелеше, лексик, грамматик, стилистик проблемалар кебек төп төшенчәләр ачыклана.

Әдәби тәрҗемәнең төп юнәлешләре

1. **Әдәби-эстетик юнәлеш**. Бер төркем галимнәр тәрҗемәнең әдәби-эстетик ягына, художество – сурәтләү чараларының бер телдән икенче телгә ничек күчерелүенә аеруча зур игътибар бирәләр һәм әдәбият белеме категорияләренә таянып эш итәләр. XX гасырга кадәр әдәби тәрҗемә буенча тикшеренүләр әдәбият белеме карамагында булды. Бу җирлектә әдәби тәрҗемәнең мөһим принциплары: тәрҗемә әсәренең идея-тематик эчтәлеген дөрес бирү, эчтәлек һәм форма берлегенә ирешү, әсәрнең милли колоритын, авторның идеалектын саклау, формализмга юл куймау кебек әһәмиятле принциплар билгеләнә. А.В.Федоров, И.И.Ревзин, В.Ю.Розенцвейг тәрҗемә мәсъәләләрен өйрәнеп, беренчеләрдән булып әдәби карашны тәнкыйтьләп чыгалар. Нәтиҗәдә, әдәби тәрҗемә, гомумән, тәрҗемә теориясе өчен әдәби-эстетик юнәлеш кенә җитми, лингвистик караш кирәклеге ачыкланды.

2. **Лингвистик юнәлеш.** Бу юнәлеш тарафдарлары тәрҗемә мәсьәләләрен тел белеме җирлегендә карыйлар, оригинал белән тәрҗемә арасындагы лексик-грамматик, стилистик үзенчәлекләрне ачыклауны максат итеп куялар. Бу юнәлешкә нигез салучыларның берсе - галим Я.И. Рецкер.(“О закономерных соответствиях при переводе на родной язык” мәкаләсе 1950). Соңрак А.В. Федоров үзенең 1953 нче елда чыккан “ Введение в теорию перевода” китабында тәрҗемә практикасы һәм теориясе өчен тирән

лингвистик нигез, аерым телләр арасындагы мөнәсәбәт закончалыкларын белү кирәклегенә басым ясый.

Бу ике юнәлеш - әдәби-эстетик һәм лингвистик юнәлешне яклаучы галимнәр арасында каршылыклы фикерләр, бәхәсләр берничә ел буе дәвам итә. Мәсәлән, В. Россель, Я. Соболев, И. Кашкин һ.б. лингвистик карашны “яраксыз формаль караш» дип аңлаталар, әдәби-эстетик карашны исә «бердәнбер дөрес иҗади караш”дип яклап чыгалар. Соңрак бу бәхәскә нокта куела: тәрҗемә теориясе тел һәм әдәбият белеменең тыгыз бәйләнешен, хезмәттәшлеген сорый.

Әдәби тәрҗемәнең дүрт принцибы

Хәзерге әдәби тәрҗемә фәнендә түбәндәге приниплар аерып карала: эчтәлек берлеге принцибы; стилистик берлек принцибы; иҗадилык принцибы, эстетик тәэсир итү.

1) Тәрҗемәнең төп принципларыннан берсе һәм иң әһәмиятлесе – оригиналның мәгънәсе, эчтәлек берлеге. Мәгънәне, эчәлекне тулы бирү принцибы тәрҗемә төгәл булырга тиеш дигән таләп белән аерылгысыз бәйләнгән. Тәрҗемә төгәл булмаса, тәрҗемә ителә торган әсәрнең мәгънәсе тулы бирелә алмый. Бу турыда В.Г. Белинский болай дип яза: “Матур әдәбият тәрҗемәсендә бернинди төшереп калдырулар да, өстәүләр дә булырга тиеш түгел”. Мәгънә ялгышлыклары әсәрнең милли колоритына, сәнгать дәрәҗәсенә зыян китерергә мөмкин.

2) Тәрҗемәдә төп нөсхәнең форма үзенчәлекләре, автор стиле, сәнгать-милли үзенчәлеге мөмкин булганча тулы гәүдәләнергә тиеш. Күренекле тәрҗемәчеләр, тәрҗемә белгечләре бу принципка элек-электән зур игътибар итеп килгәннәр һәм тулы кыйммәтле тәрҗемәгә ирешү өчен, форма элементларын да мөмкин кадәр тулы сакларга кирәк дип исәпләгәннәр. Форма төгәллегенә ирешү автор стилен саклауга кайтып кала. Төп нөсхәнең үзенчәлекләре: сурәтләү чаралары, образлылык элементлары, интонациясе һ.б. автор стиленә яраклаштырып бирелсә, бу – тәрҗемә оригиналга стиле буенча тиң дигән сүз дип аңлата Р. А. Юсупов. Бу очракта авторга хас язу алымнарына, аерым алганда, тропларга, фразеологизмнарга, гади сөйләм сүзләренә, диалекталь сүзләргә, билгеле бер төрле җөмлә төзелешләренә туры килерлек чаралар таба алу әһәмиятле. Ләкин һәр очракта да даими эквивалентлар табарга мөмкин булмый. Бу очракта тәрҗемәче күп төрле вариантларның берсен, эчтәлеге һәм формасы белән оригиналга мөмкин кадәр туры килгән тел чараларын сайлап ала.

3) Сайлап алу, эзләү тагын бер әһәмиятле принципка килеп тоташа. Иҗадилык принцибы – матур әдәбият тәрҗемәсендә, бигрәк тә поэтик тәрҗемәдә әһәмиятле принцип. Үз вакытында рус шагыйре-тәрҗемәче В.А. Жуковскийның иҗат иреге турында әйткән сүзләре бүген дә үзенең әһәмиятен югалтмый: «Проза тәрҗемәчесе – кол, шигырь тәрҗемәчесе – көндәш». Бу принцип поэтик чаралар сайлап алганда, сүз белән сурәт тудыруда чагыла. Шулай да тәрҗемәче иҗат ирегеннән дөрес файдалана белергә тиеш, чама хисен аңларга, сак килергә тиеш. Тәрҗемәче, үзе теләгәнчә, текстны

үзгәртеп, үзирекле тәрҗемә белән мавыгып, авторга хыянәт итә алмый. Дөрес, тәрҗемә тарихында авторны төзәтү, әсәрне шомарту күренешләре дә күзәтелә. 19 гасырда шундый тәрҗемә нәтиҗәсендә көнбатыш язучылары руслаштырылган, әсәрдәге вакыйгалар Россия җирлегенә күчерелгән, Париж Мәскәүгә, Пьер Иванга әверелдерелгән – ягъни, әсәргә җан кертелгән. “Үзгәртеп” тәрҗемә итүнең нигезендә берничә сәбәп яткан. Беренчесе – укучы чит язучы әсәрен җиңелрәк үзләштерсенннәр, тулырак аңласыннар дигән теләк белән тәрҗемә әсәрен укучыга якынайту. Икенчесе – тәрҗемәченең оригиналны ошатмыйча, үзе теләгәнчә төзәтеп, кыскартып, яисә бөтенләй төшереп калдырып тәрҗемә итүендә. Өченче сәбәп тәрҗемә эшенең кыен эш булуында. Кайвакыт тәрҗемә итүгә караганда яңача әйтү, арттырыбрак эшләү җиңелрәк була башлый. Гомерның “Илиада”сын тәрҗемә иткән Н.И. Гнедич болай дип язган: “Бизәү, Гомер шигырен безнең төскә буяп җибәрү бер дә авыр эш түгел, ул купшырак, зиннәтлерәк булып күренәчәк, һәм безгә ныграк ошаячак, ләкин аны нәкъ Гомердагыча итеп саклау шактый кыен эш”.

4) Һәр әдәби тәрҗемә әсәре - һичшиксез, тәрҗемәченең интеллектуаль һәм иҗади хезмәт нәтиҗәсе. Әдәби тәрҗемә сыйфатын бәяләүнең төп критерие булып тәрҗемәнең эстетик тәэсир итүе буенча оригиналга туры килүе, ягъни адекват булуы тора. Аңлашылганча, тәрҗемәче иҗаты бары тик тел өлкәсенә генә карый. Оригиналның эчтәлегенә, мәгънәсенә, сәнгатьлелегенә, стиль үзенчәлекләренә килгәндә, тәрҗемәченең иҗаты турында бернинди сүз дә булырга мөмкин түгел. В. Г. Белинский сүзләре белән әйткәндә, тәрҗемәче таланты ул – форма таланты, чит әсәрләрнең рухына төшенү, аларның матурлыгын тою сәләтендә күренә.

Список литературы

1. Алпаров Г.Х. Тәрҗемә эшендә игътибарсызлыкка чик куярга кирәк // Яңалиф. - 1932. - №1-2. - 82-84 б.
2. Ахунҗанов Г.Тәрҗемә практикасында үзенчәлекле бер уңыш/ Г.Ахунҗанов// Казан утлары. - 1969. - №12.
3. Гази И. Тәрҗемәдә формализмга каршы // Совет әдәбияты. -1952. - №4.- Б.105.
4. Ганиев В. Тәрҗемәдәге төгәллек һәм нәфислек // Совет әдәбияты. - 1963. - №12. - 125-135 б.
5. Ибрай Г. Тәрҗемә принциплары турында Бөтенсоюз тәрҗемәчеләр киңәшмәсе турындагы докладның кыскартылган стенограммасы // Совет әдәбияты, 1936.- №3. - 52-56 б.
6. Ибраһимов Г. Тәрҗемә вә аның шартлары // Әдәбият мәсьәләләре. - Казань: Таткнигоиздат, 1960. - 49-52 б.
7. Максуд М. Бер тәрҗемәнең ялгышлары // Совет әдәбияты. - 1936. - №3. - 57-64 б.

8. Нәбиуллина Г.Ә., Мөгътәсимова Г.Р. Тәрҗемә практикасы: әдәби һәм фольклор тәрҗемәләре. Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы. - Казань: Ихлас, 2012. – 91 б.
9. Попович А. Проблемы художественного перевода / А. Попович. – М.:Выш. шк., 1980.
10. Солодуб Ю.П. Теория и практика художественного перевода / Ю.П. Солодуб. – М.: Издательский центр “Академия”, 2005. – 304 с.
11. Юсупов Р.А. Тәрҗемәнең теоретик һәм практик мәсьәләләре. – Казан: ТДГПУ, 2011. – 312 б.

Рекомендуемые информационные ресурсы

12. Тукай Г. Русчадан дөрест тәрҗемәләр // http://gabdullatukay.ru/index.php?option=com_content&task=view&id=473&Itemid=40
13. http://nsportal.ru/shkola/rodnoi-yazyk-i-literatura/library/tukaynyn-trzhem-eshen-monsbte
14. http://russian-tatar.ru/
15. http://tatpoisk.net/dict/rus2tat/

Задания для практики по теме 4

4.1.В. Ганиевның Тәрҗемәдәге төгәллек һәм нәфислек (Совет әдәбияты. - 1963. - №12. - 125-135 б.) һәм Г. Ибраһимовның Тәрҗемә вә аның шартлары (Әдәбият мәсьәләләре. - Казань: Таткнигоиздат, 1960. - 49-52 б.) мәкаләләрен укып фикер алышу.

4.2 Г.Тукайның «Русчадан дөрест тәрҗемәләр” паемфлетында автор кайсы хаталарны күрсәтергә тели. Бө җөмләләрне дөрес тәрҗемә итеп языгыз.

Русча: Я перешел через мост.
Тәрҗемә: Мин чыктым аркылы күпер.
Русча: Соглашение между Францией и Испанией будет подписано в конце текущей недели.
Тәрҗемә: Килешү арасы Франция һәм Испания булыр имза ителгән ахырында агып барган атнаның.
Русча: Это глухое место.
Тәрҗемә: Бу чукрак урын.
Русча: Лев Толстой умер.
Тәрҗемә: Арыслан җуан үлде.
Русча: Жили-были дед да баба.
Тәрҗемә: Торды-булды бабай да әби.

Русча: Дай сюда поднос!
Тәрҗемә: Бир монда борын астын!
Русча: Разрешена постройка новой каменной мечети взамен существующей деревянной, сильно обветшалой и тесной.
Тәрҗемә: Рөхсәт бирелгән салу яңа таш мәчет алмашынуга булып торган агач, көчле искергән һәм тарның.
Русча: При одновременной подписке на газету и журнал, подписчики уплачивают вместо 10 р. только 8 р.
Тәрҗемә: Каршы бервакытлы астына язганда гәзитә өстенә һәм журналга астына язучылар түлиләр урынына 10 тәңкә тик 8 тәңкә.
Русча: Около Приштины албанцы напали на местных властей, спасавшихся лишь благодаря прибытию войск.
Тәрҗемә: Янында Приштинә арнаудлар өсткә җыгылдылар урын өстендәге көчләргә, котылмышларга тик рәхмәт укый-укый каршы килгән гаскәргә.
Русча: Было мне годов восемь.
Тәрҗемә: Булды миңа яшьләр сигез.
Русча: След рыбы.
Тәрҗемә: Эзе балыкның.
Русчадан тәрҗемә итдегем бу үрнәкләрне мин үземнең мөтәрҗимлек эшендә мәһарәтемне гаммәгә күрсәтер өчен яздым. Ничә еллардан бирле "Баянел хак" кеби милли вә олугъ көндәлек гәзитләрнең хәбәрләр кыйсьмендә югарыдагы үрнәкләрдән бик күп начар дәрәҗәдә тәрҗемә ителгән сәтырларга очраганым булганга, үземне, билифтихар вәлгорур, бөтен татар гәзитә вә журналлары идарәсенә мөтәрҗим буларак тәкъдим итәрмен.[2]

ТЕМА 5. ТӨРЛЕ ЖАНРДАГЫ ҺӘМ ТӨРДӘГЕ ӘСӘРЛӘРНЕ ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Лекция № 7

ПРОЗА ТӘРҖЕМӘСЕ

Аннотация. Данная тема раскрывает особенности прозаического перевода.

Ключевые слова. Проза тәрҗемәсе, әдәби тәрҗемә, эстетик адекватлылык, интерпретация.

Методические рекомендации по изучению темы.

[2]*Мөтәрҗимлек — тәрҗемәчелек.*
Гаммә — халык.
Сәтыр — юл (язмада).
Билифтихар вәлгорур — мактанып һәм горурланып.

- Тема содержит лекционную часть, где излагаются основные проблемы прозаического перевода.
- Для проверки усвоения темы имеются вопросы для изучения, также необходимо выполнить задание и отправить на проверку.
- В качестве самостоятельной работы предлагается написать реферат на тему «Татарская проза на русском языке».

Вопросы для изучения

Особенности перевода художественного текста.
Интерпретация при переводе художественного текста.
Взгляды А.Поповича на перевод художественного текста.
6 основных правил Х. Беллока для переводчика прозаических текстов.
Трансформации в художественном переводе.

Тәрҗемә өлкәсендә үзенә игътибарны җәлеп иткән тагын бер күренеш оригинал текст белән чагыштырганда тәрҗемәнең күләме зуррак булу белән бәйле. Кайбер белгечләрдә бу факт ризасызлык уятса, тәнкыйтьләнсә, икенче берәүләр моны бер телдәге сүзнең мәгънә күләме икенче телдәгесе белән туры килмәү (лексик-семантик интерференция), телләрнең грамматик төзелешендәге үзенчәлекләр белән аңлаталар. Тәрҗемәчеләрне яклап, К.Миңлебаев болай дип яза: "Безнең тәрҗемәләрдә күләмнең чак кына артуына кайбер иптәшләрнең капризы дип кенә карарга һич ярамый: аның сере тирәндәрәк ята. Тәрҗемәчеләребез сабый чактан ук татар әдәбиятының сихри дөньясы белән рухланып үскән, шуның традицияләренә мөкиббән китеп мыек чыгарган кешеләр, һәм аларның азмы-күпме тәфсилләбрәк сурәтләргә яратулары табигый хәл. Шул ук вакытта, җитлеккән сүз остасы буларак бүгенге көндә бәйге тоткан тәрҗемәчеләребезнең үзләренең иҗади йөзләре, почерклары бар." Моны раслау максатында бер үк авторның төрле тәрҗемәчеләр тарафыннан әзерләнгән әсәрен чагыштырып карау да җитә. Мисал өчен, "рус әдәбияты классигы И.С.Тургенев повестьларын тәрҗемә иткәндә, Ф Гайнанова да, В. Зыятдинов та көчләрен кызганмыйча эшләп, шактый гына уңышка ирештеләр. Әмма авторның стилен икесе ике төрлерәк һәркайсы үзенчәрәк кабул итү сәбәпле, аларның җитлеккән тәрҗемәче буларак үз йөзе, үз каләме булу сәбәпле, тәрҗемәләр бер-берсеннән аерылып тора. Татар теленнән рус теленә проза әсәрләрен тәрҗемә итү өлкәсендә Г. Шәрипова, Г. Хантимерова, Р. Фәизова, Ә. Бадюгина зур эшчәнлек алып барганнар. Рус классик әдәбиятыннан А.Н. Толстой, В.Я. Шишков, А.А. Фадеев, М.А. Шолохов, Д.А. Фурманов, Н.А. Островский, И.Г. Эренбург, В.Ф. Панова, К.Г. Паустовский, Н.Ф. Погодин, К.М. Симонов, М.М. Пришвин, А.Т. Твардовский, Н.С. Тихонов әсәрләре тәрҗемә ителгән.

Проза тәрҗемәсен өйрәнүгә поэтик тәрҗемәләрне өйрәнүгә караганда игътибар чагыштырмача азрак бирелгән. Бу мөгаен поэзиянең статусы югарырак булу белән

аңлатыладыр. А.Попович тикшеренүләреннән күренгәнчә, прозаны тәрҗемә иткәндә, түбәндәге күчешләр барлыкка килергә мөмкин:

1) мәгълүматны дөрес тәрҗемә итмәү;

2) оригиналга тиешле дәрәҗәдә интерпретация ясамау;

3) интенциональ коррелятларны өстән-өстән генә интерпретацияләү.

Тәрҗәчеләр проза әсәрләрен җиңелләштереп тәрҗемә итәргә омтылалар, шул сәбәпле оригинал текстның авыр, озын, катлаулы җөмләләреннән качарга котылырга тырышалар.

Инглиз язучысы Хилэр Беллок проза текстларын тәрҗемә итүчеләр өчен 6 кагыйдә тәкъдим итә:

1) тәрҗемәче авырлык белән сүзне сүзгә, җөмләне җөмләгә тәрҗемә итүгә “бәйләнергә тиеш” түгел;

2) Тәрҗемәче идиоманы идиома белән бирергә тиеш түгел. Семантик тәңгәллек булырга тиеш;

3) тәрҗемәсе сүзнең мәгънәсенә игътибарлы булырга тиеш;

4) тәрҗемәче “ялган дуслары” (сүзләр, җөмләләр) белән сак булырга тиеш;

5) тәрҗемәче текст белән кыю эш итәргә тиеш, чөнки Беллок сүзләре белән әйткәндә “туган тәндә чит хикәя туа” («возрождение чужого рассказа в родном теле”);

6) тәрҗемәче беркайчан да әсәрне бизәргә тиеш түгел.

Бу кагыйдәләр техник һәм приницципиаль моментларны чагылдыра. Тәрҗемәче оригинал прозик текстны билгеле бер структурага ия текст буларак кабул итәргә һәм шул ук вакытта тәрҗемә теленең синтаксик, стилистик кагыйдәләрен истә тотып тәрҗемә итәргә тиеш. Тәрҗемәче, әлбәттә, текстны беркадәр үзгәртә ала,ләкин “әхлакый” җаваплылык тотарга тиеш. Нәтиҗәдә, укучы үз телендәге стилистик, идиоматик нормаларга тәңгәл килгән текстны кабул итә. Башкача әйткәндә, тәрҗемә тәңгәллеге таләбен саклау зарур: Париж Мәскәүгә, Пьер Петрга әйләнергә тиеш түгел.

Күренгәнчә, чыганак телдәге теге ки бу структураның функциясен билгеләү әһәмиятле, аннары гына тәрҗемә телендәге тәңгәл функциягә ия булган структураны табарга мөмкин. Еш кына тәҗемә телендә тәңгәл структура булмаска да мөмкин. Бу очракта тәрҗемә теленең үз мәдәни һәм тел закончалыкларына нигезләнеп эшләү сорала.

XX гасырның 60 елларында тәрҗемәчелек эшчәнлеге һәм аның алдында торган бурычлар хакында фикер йөртеп, галим: В.Ганиев "Безнең алда торган бурычлар: юморны юмор белән, сатираны сатира стиле белән, көлдергеч фразаны көлдергеч итеп, җылата торганын күздән яшь чыгарлык итеп тәрҗемәләү. Кыскасы, үзебезнең бай телебез халык авызында һәм каләм осталары кулында ничек матур, көчле яңгыраса, тәрҗемәдә дә шулай яңгырарга тиеш! Телнең көче зур. Үтергән дә - тел, тергезгән дә - тел, ди халык" - дип яза.

Күпчелек галимнәрнең фикере уртак: тәрҗемәчеләрнең татарча уйлап, үз телебез рухыннан чыгып тәрҗемә итүе әһәмиятле, сүзгә яки җөмләгә, абзацка ябышып ятарга ярамый. Ягъни укучы алдында эчтәлеге-идеясе белән белән дә, рухы белән дә, теле-сөйләме белән дә татарныкы булган китап ятарга тиеш. Бары шул вакытта ул безнең аңыбызны, рухыбызны, мәдәниятебезне баета алу сәләтенә ия булачак.

К. Миңлебаев әлеге мәсьәлә хакында "эчтәлекне төгәл бирү - хәзерге буын тәрҗемәчеләре өчен проблема булудан туктады шикелле: һәр ике телне җитәрлек дәрәҗәдә белүче тәрҗемәчеләребез инде автор әйтергә теләгән фикерне, автор сурәтләгән картинаны, һич тә хилафлык китермәстән, укучыларыбызга җиткерергә өйрәнделәр дип әйтергә була... Әдәби әсәрнең кыйммәте аның кайсы телдә иҗат ителгән булу-булмавына бәйләнмәгән, бәлки эчтәлеге һәм формасының бердәм булуына, автор яки тәрҗемәченең сурәтләү чаралары һәм теле ягыннан ни дәрәҗәдә камиллеккә ирешә алуына бәйләнгән. Професиональ тәрҗемәчеләр кулыннан узган китапны укыганда, әсәрнең эчтәлеге турында мәгълүмат алу белән генә чикләнеп калмыйча, авторның тел байлыгын, андагы үзенчәлек-нюансларны, язу стилен тулысынча аңлап, бу хакта җәелеп фикер йөртергә мөмкин", дигән фикер әйтә. Аңлашылганча, әлеге юлларның авторы профессиональ тәрҗемәчегә хас иң әһәмиятле сыйфатларны билгеләүгә ирешкән. Бары шул очракта гына тәрҗемә әсәре үзенә йөкләнгән вазифаны үтәү сәләтенә ия була.

К.Миңлебаев шулай ук, 1970 нче елларда тәрҗемәчеләрнең “стиль ягыннан үзләренә якынрак торган, яхшы аңлаешлы, яраткан авторларның аларын тәрҗемә итүне мәгъкуль күрүләрен” ассызыклый. Моның уңай ягы, автор фикеренчә, тәрҗемәченең әсәрдә тасвирланган вакыйгаларны үзебезнең әдәбият җирлегенә күчереп куярга, оригиналдагы персонажларга тәңгәл килердәй типларны иҗат итәргә омтылышында күренә.

Проза әсәрләрен тәрҗемә иткәндә, төп принциплар итеп түбәндәгеләрне күрсәтергә кирәк:

- Матур әдәбият әсәренең эчтәлек һәм форма бердәмлеге укучыда билгеле бер эмоцияләр, кичерешләр тудыра, ягъни билгеле бер эстетик әһәмияткә ия була. Тәрҗемә ителгән әсәр дә шундый эстетик әһәмиятен югалтмаска тиеш.
- Тәрҗемәче һәр ике телне дә яхшы белергә тиеш. Тәрҗемәче өчен оригинал һәм тәрҗемә телләренең әдәби формаларын гына белү җитми, халык сөйләм телен, диалектларын да, ягъни бөтен нечкәлекләрен белергә тиеш.
- Тәрҗемә теле дөрес булырга, әдәби нормаларга туры килергә, оригиналдагыча җанлы, бай, эмоциональ булырга тиеш.

Тәрҗемә әсәренең укучыга яисә тыңлаучыга эстетик тәэсир итүдә югары дәрәҗәдә адекват булуына ирешү өчен, иң беренче чиратта, әдәби әсәрнең идея, тематик юнәлешен аңлау зарур. Тәрҗемәче тәрҗемә итәргә алынган әсәрнең нинди жанрда булуына карамастан, авторның дусты, фикердәше булырга, аның әйтергә теләгән фикерен, хисләрен (интенциясен) билгеләргә тиеш. Шул нигездә, тәрҗемәче тәрҗемә ителә торган әсәрнең образлылык системасын, авторның тел үзенчәлекләрен тасвирлауда адекват тел чараларын табарга тиеш.

Әдәби тәрҗемәнең эстетик адекватлылыгына ирешү өчен, тәрҗемәче беренчел һәм икенчел образлылыктагы (туры һәм күчерелмә мәгънәдәге) тел-сурәтләү чараларын саклык белән сайлап ала белергә тиеш. Бу автор “идиолектына” карата игътибарлы булуны таләп итә. Идиалект дигәндә билгеле бер телдә сөйләүче, ягъни безнең очракта

язучы яки шагыйрь теленә хас формаль һәм стилистик чараларның җыелмасын аңларга кирәк. Шагыйрьнең яки язучы сөйләменең формаль һәм стилистик үзенчәлекләре телнең төрле яссылыгында – фонетик, сүз ясалышы, морфологик, лексик, фразеологик, синтаксик яссылыгында чагылыш таба.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, эстетик яктан адекват әдәби тәрҗемәгә ирешү өчен төп өч фактор әһәмиятле: төп нөсхәнең идея-тематик эчтәлеген тирән аңлау, автор интенциясенә (теләк, омтылышларына) үтеп керү; төп нөсхәнең образ системасына, беренче һәм икенчел образлылыкка сакчыл мөнәсәбәт булдыру; автор идеалектына шулай ук сакчыл мөнәсәбәттә булу.

Шул рәвешле, әдәби тәрҗемә процессында төп ике кагыйдәне истә тотарга кирәк:

1) Тәрҗемәнең тышкы формаль ягы – бер тел чараларына алмаш (эквивалент) итеп икенче тел чаралары алыну;

2) Тәрҗемәнең эчтәлек ягы – берсен берсе алмаштырган чараларның мәгънәви-стилистик, эмоциональ-экспрессивлык үзенчәлекләре белән туры килүе.

Список литературы

1. Алпаров Г.Х. Тәрҗемә эшендә игътибарсызлыкка чик куярга кирәк // Яңалиф. - 1932. - №1-2. - 82-84 б.
2. Ахунҗанов Г.Тәрҗемә практикасында үзенчәлекле бер уңыш/ Г.Ахунҗанов// Казан утлары. - 1969. - №12.
3. Гази И. Тәрҗемәдә формализмга каршы // Совет әдәбияты. -1952. - №4.- Б.105.
4. Ганиев В. Тәрҗемәдәге төгәллек һәм нәфислек // Совет әдәбияты. - 1963. - №12. - 125-135 б.
5. Кыйблага тугрылык: Әдип һәм тәрҗемәче Кыям Миңлебаевка 75 яшь тулуга багышланган библиографик мәгълүматлар һәм мәкаләләр җынтыгы (Мөхәррире И.Г. Һадиев. — Казан: Милли китап, 2004. — 139 б.
6. Нәбиуллина Г.Ә., Мөгътәсимова Г.Р. Тәрҗемә практикасы: әдәби һәм фольклор тәрҗемәләре. Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы. - Казань: Ихлас, 2012. – 91 б.
7. Попович А. Проблемы художественного перевода / А. Попович. – М.:Выш. шк., 1980.
8. Солодуб Ю.П. Теория и практика художественного перевода / Ю.П. Солодуб. – М.: Издательский центр “Академия”, 2005. – 304 с.
9. Юсупов Р.А. Тәрҗемәнең теоретик һәм практик мәсьәләләре. – Казан: ТДГПУ, 2011. – 312 б.

Рекомендуемые информационные ресурсы

10. http://nsportal.ru/shkola/rodnoi-yazyk-i-literatura/library/tukaynyn-trzhem-eshen-monsbte
11. http://russian-tatar.ru/
12. http://tatpoisk.net/dict/rus2tat/

Лекция № 8

ПОЭЗИЯ ТӘРҖЕМӘСЕ

Аннотация. Данная тема раскрывает особенности стихотворного перевода.

Ключевые слова. Шигырь тәрҗемәсе, ритм, рифма, шигырь калыбы, ритмик төзелеш, формаль тәрҗемә, букваль тәрҗемә, функциональ тәрҗемә, әдәби тәрҗемә, стильгә салынган тәрҗемә.

Методические рекомендации по изучению темы.

- Тема содержит лекционную часть, где излагаются основные проблемы стихотворного перевода.
- Для проверки усвоения темы имеются вопросы для изучения, также необходимо выполнить задание и отправить на проверку.
- В качестве самостоятельной работы предлагается написать эссе на тему «Татарская поэзия на русском языке».

Вопросы для изучения

Перевод стихов.
Стихотворный перевод.
Виды переводов стихов.
Стилизованный перевод.
Буквальный перевод.
Функциональный перевод.
Художественный перевод.
Формалистический перевод.
Трудности стихотворного перевода.

“Прозаны, драматургияне тәрҗемә итү ни дәрәҗәдә иҗаттыр, мин анысын белеп бетермим, әмма шигырьне тәрҗемә итү – авыр иҗат. Авторның җаны ни кадәрле катлаулы булмасын, аны аңлау – мөмкин эш. Шагыйрь – үз шигыриятенең хуҗасы, ә тәрҗемәче – шигырьнең колы булырга мәҗбүр. Ә кол хезмәтен күз алдына китерергә була...

Тәрҗемә берничә принципка таянып эшләргә була. Әйтик, тәрҗемә, оригиналның эчтәлегенә тугрылыклы калган хәлдә, аның формасын да, рифмалау ысулын да,

ритмикасын да, яңгыраш стилен дә, метафора һәм сурәтләү чаралары үзенчәлеген дә мөмкин булганча сакларга тиеш. - дип яза Р. Харис шигырь тәрҗемәсе турында.

Шигырь тәрҗемәсе - авыр, бик катлаулы эш. Шигъри сүз-җөмләне башка телгә зур төгәллек белән күчерү осталары бик сирәк очрый. Бигрәк тә ике телне камил белүчеләр бик сирәк. Габдулла Тукай, Дәрдемәнд, Муса Җәлил, Һади Такташ кебек олуг шагыйрьләребезнең иҗади мирасын рус дөньясына таныткан элекке шундый тәрҗемәче шагыйрьләрдән Вил Ганиев, Шамил Анак-Мәхмүдев, Равил Бохараевны атарга мөмкин. Бүген аларга алмашка ике телне дә яхшы белүче Роза Баубекова-Кожевникова, Рөстәм Сабиров, Сергей Малышев, Лилия Газизовалар килде. Марк Зарецкий да татар әдәбиятын, татар шигъриятен үз итеп, рухи якын күреп эшләүчеләрдән булды. Олуг шагыйрьләребездән Дәрдемәнд, Габдулла Тукай шигырьләре дә аның тәрҗемәсендә бик килешле итеп эшләнеп, рус телле укучыга тәкъдим ителде. Мария Аввакумова да, кайбер чордаш шагыйрьләренең әсәрләрен уңышлы тәрҗемә итеп, аларның ил күләмендә танылуына үз өлешен кертте.

Ике телне белмичә, фәкать сүзгә-сүз тәрҗемәләр белән эш итүче шагыйрьләр еш кына шигырь эчтәлеген ярлыландыралар. Алар формаль рәвештә шигырь юллары, сүз иҗекләре санын сакларга тырышалар. Ягъни тышкы, формаль тәңгәллеккә омтыла. Андый тәрҗемәләрдә еш кына шагыйрьнең укучысына әйтәсе, җиткерәсе фикере нык гадиләштерелә. Тәрҗемә белән шөгыльләнүчегә, ике тел мохитен дә күпмедер дәрәҗәдә белү кирәклегенә мисал итеп, әдәбият галимнәре еш кына Самуил Маршакның бер тәрҗемә үрнәген китерәләр. У.Шекспирның сонетларын тәрҗемә иткәндә, ул, инглиз телен дә белүе сәбәпле, сонетларга хас ундүрт юллыклар белән генә чикләнмичә, юллар санын арттырып тәрҗемә итә. Шул рәвешле рус телендә сонетларның мәгънәви эчтәлеген тулырак бирүгә ирешә. «Аның тарафыннан иң уңышлы тәрҗемә ителгән сонет егерме дүрт юллы булып чыккан. Ләкин моның өчен берәү дә аны гаепли алмый — шул рәвешле ул шигырьнең тулы эчтәлеген укучысына җиткерә алган», — дип язалар әдәбият галимнәре. Ә үзебезнең милли телләрдән тәрҗемә итүче шагыйрьләрнең күпчелеге исә еш кына формаль тәңгәллеккә ирешү белән чикләнделәр. Һәм: «Һади Такташ, Хәсән Туфан кебек шагыйрьләрнең катлаулы эчтәлекле шигырьләрен рус телле укучы кабул итәрдәй дәрәҗәдә эшләү бик авыр», — дип аңлаталр.

В.Ганиев хезмәтләренә караганда, татар поэзиясе үрнәкләре беренче тапкыр рус теленә XIX гасырда күренә башлый. Н.Берг тарафыннан бастырып чыгарылган "Төрле халыкларның җырлары” исемендәге җыентыкта татар халык җырлары да булган. П.И Пашино "Современник" журналында Казан татарлары турында мәкаләсендә Калачев тарафыннан тәрҗемә ителгән татар шигыреннән мисал китергән. Татар поэзиясен русчага тәрҗемә итүдә беренче адымнар шушы булган. Дөрес, бу тәрҗемәләр сыйфат ягыннан мактарлык түгел. Мәсәлән, Н.Берг татар халык җырларының эчтәлеген бөтенләй бирә алмаган. Әмма бу факт татар, милләте белән "кызыксыну шул вакытлардан ук булганлыгын раслаучы күренеш буларак әһәмияткә ия.

М.Горькийның узган гасырның 90 елларында татар әдәбиятына багышланган русча җыентык чыгарырга тырышуы да игътибарга лаек. Әмма бу хыял тормышка ашмый кала.

Ләкин татар әдәбиятын популярлаштыру өчен А.М. Горький башка юллар тапкан. Ул Н. Думавиның татар мәдәнияте һәм әдәбияте турындагы мәкаләсен үзе редакцияләп чыга һәм “Современник” журналында бастыра. Шулай ук Г.Тукайның кайбер шигырьләре А.М.Горький катнашы белән русчага тәрҗемә ителеп дөньяга чыга.

В.Ганиев сүзләренә караганда, татар шагыйрьләренең әсәрләрен тәрҗемә иткәндә, рус шагыйрьләре С.Липкин, Л.Пеньковский, М.Тарловский, К..Липскеров ҺӘМ башкалар Урта Азия әдәбиятлары әсәрләрен тәрҗемә итү өчен әзерлек үтәләр. (В. Ганиев. “Тәрҗемәдә төгәллек һәм нәфислек”, Совет әдәбияты, 1963, №12, 126 б.) Димәк, татар поэзиясе Көнчыгышка капка ролен үтәгән.

Безгә якын дәвердә яшәп иҗат иткән классик әдип вә шагыйрьләребезнең мирасын һәм исемнәрен дөнья мәйданына чыгару эше әлегә ярыйсы ук сүлпән бара. Бүгенге көнгә хәтле бөек Тукаебызның күп кенә шигырь һәм поэмалары тиешле дәрәҗәдә рус теленә дә тәрҗемә ителмәгәннәр. Дөньяның киң таралышлы башка телләре турында инде әйтеп торасы да түгел. (Дөрес, соңгы елларда берничә шагыйрнең әсәрләре чит телләрдә дә күренә башлады. Утыз биш еллар элек Дәрдемәнднең шигъри мирасын рус телле укучыга җиткерү талпынышы да булып алган иде. 1970 елда нәшер ителгән «Стихи» китабын дөньяга чыгаручылар күренекле шагыйрьләребез Сибгат Хәким белән Ренат Харис булды. Иҗаты белән исеме бөтен дөньяга танылган Муса Җәлил бу җәһәттән беркадәр бәхетлерәк. Аның шигырь һәм поэмалары рус теленнән тыш башка бик күп телләргә тәрҗемә ителде. М.Җәлил әсәрләре бүгенге көндә илле дүрт телдә басылып чыккан. Тәрҗемәләренең кат-кат эшләнүе, андый җаваплы эшкә илебезнең иң тәҗрибәле тәрҗемәчеләренең җәлеп ителүе нәтиҗәсендә аларның сыйфаты да канәгатьләнерлек.

Поэтик тәрҗемәнең үзенчәлекле яклары, проза тәрҗемәсеннән аермасы турында А.В. Федоровның “О Художественном переводе (1941)” китабында ачык әйтелгән. Аның фикеренчә, поэзия тәрҗемәсенең үзенчәлекләре шигырьнең жанр табигатенә бәйле. Сүз шигырьдә яңа мәгънә төсмерләре, эмоциональ чынбарлык ала. Сүзләр тәртибе дә башкача була. Шигырьгә ритмик формадан тыш, аерым синтаксис хас. “ Бер яктан, ритм, рифма, строфаны гәүдәләндерү, икенче яктан, сүзне бирү таләбе, кайчак, проза тәрҗемәсенә караганда кискенрәк була: еш кына теге яки бу сүз яисә сүзтезмә шигырьгә «сыймый» яки аны киресенчә тутырып бетерми. Шунлыктан ритм, рифма таләпләренә җавап бирә торган сүзләр сайлау таләп ителә. Менә шуңа күрә дә сүзгә-сүз төгәллек карашыннан чыгып эш иткәндә, шигырь тәрҗемәләре, кагыйдә буларак, проза тәрҗемәләренә караганда, оригиналдан һәрвакыт ераграк була. Ритм-рифма закончалыклары мәгънәви һәм лексик адекватлыкка ирешүдә кыенлыклар китереп чыгара, нәтиҗәдә шигъри әсәрләрдә тәрҗемә белән оригинал арасында аерма килеп чыга. В. Коптилов, К. Чуковский, Н. Соколов һәм башка галимнәрнең фикеренчә, поэзия әсәрләре тәрҗемәчедән шактый зур ирек таләп итә.

Күренгәнчә, бер яктан идея-эчтәлекне бирергә, икенче яктан шигырь калыбын, үлчәмен, ритм-рифма үзенчәлеген дә сакларга кирәк. Бу ике якны да, ягъни мәгънә һәм форма ягын саклау җиңел түгел – авазлар ягын сакласаң, эчтәлеген төгәл бирим дисәң, мәгънәгә зыян килә. Поэтик тәрҗемәдә, кагыйдә буларак, оригиналга тиң эмоция

тудыру, укучының хисләренә тәэсир итү күздә тотыла. Нәтиҗәдә, төп нөсхәнең авазлар төзелешен, сәнгатьлелек чараларын саклау беренче планга чыга. Дөрес, кайбер илләрдә, аерым алаганда Франциядә хәзер дә поэзияне проза белән тәрҗемә итәләр. Бу оригиналның мәгънәсен бирү өчен шулай эшләнә. Бу алымның уңайсыз ягы шунда – шигырь шигырь булудан туктый, нәтиҗәдә, эстетик әһәмияте югала.

Әхмәт Исхак илле ел дәвамында тәрҗемә иҗаты белән шөгыльләнгән, тәрҗемә эшен чын иҗат эше итеп санаган бик сирәк шагыйрьләребезнең берсе һәм танылганы. Аның үз тәрҗемә стиле, үз алымнары, шигъри тәрҗемәгә үз мөнәсәбәте бар. Ул болай дип яза: «Тәрҗемә иткәндә мин төрҗемә итүнең төп принцибын – бернинди ireklelekkә бирелмәү, авторның төп фикерен һәм кичерешләрен укучыга тәгәл ирештерү, оригиналның ритмик төзелешенә туры килә торган үлчәмне табып куллану…үзлегеңнән бер генә сүз һәм бер генә образ да өстәмәү яки төшереп калдырмау…принцибын үтәүгә бөтен көч һәм сәләтемне куярга тырыштым», – дип яза. Бу, әлбәттә, тәрҗемә өлкәсендә иң киң таралган принцип. Күпләр шулай тәрҗемә итәләр һәм уңышка да ирешәләр. Ләкин болай тәрҗемә итүнең дә үз кимчелекләре, үз минуслары табыла. Чөнки бер телдән икенче телгә тәрҗемә барышында, телләрдәге сүз һәм шигырь үзенчәлекләре аркасында, кайбер образлар төссезләнә яки бөтенләй югалырга мөмкин. Я булмаса, бер телдәге сурәтләү чаралары, шигъри детальләр икенче тел өчен гадәти сүз тезмәләре генә булып калуы бар. Нәтиҗәдә, тәгәл тәрҗемә аркасында шигырьнең тәэсир итү көче кими. [http://www.robertminnullin.ru/index. php?option=content&task=view&id=133].

Шигырь тәрҗемәчесе күпмедер дәрәҗәдә үзе дә шагыйрь булырга тиеш. Шигырьне тәрҗемә итүчегә, проза тәрҗемәчесенә караганда, шактый иркенрәк эш итәргә мөмкинлек туа Бу очракта тәрҗемәченең иҗади мөмкинлекләре ачыла, үз стиле, алымнары ачыграк чагыла башлый. – тәрҗемә тәрҗемәче ирегенә бәйле була. Тәрҗемә әсәре тәрҗемәченең үз иҗаты өчен нигез булып китә. Мәсәлән, Пушкинның, Лермонтовның, Блокның, Тукайның күп кенә тәрҗемәләре шундый.

Шигырьнең ритмик төзелеше, билгеле булганча, нигездә, дүрт төргә: тоник, силлабо-тоник, силлабик һәм метрик төрләргә бүленә. Тәрҗемәчеләргә нигездә менә шндый системалардагы шигырьләр белән эш итрәгә туры килә, һәм әсәр тәрҗемә ителгән тел башка фонтик үзенчәлекле икән, шшигырьне бер системадан икенче системага күчерергә кирәк була. Шуның өстенә бер телдәге шигырь үлчәве, рифма формалары икенче телдә табылмаса да башка стилистик мөмкинлекләрдән файдаланырга кирәк.

Билгеле булганча, татар телендә шигырь төзелеше силлабик системага нигезләнә. Тәрҗемәдә рус теленең силлабо-тоник һәм бигрәк тә тоник яңгырашы тулысынча чагылдыра алмый, аның каравы шигырь үлчәве һәм рифма формалары бик иркен рәвештә күчерелә ала, моның өчен телнең барлык мөмкинлекләреннән файдала белергә генә кирәк.

Мәсәлән, түбәндәге шигырьне алып карыйк. Бу тәрҗемә оригиналдан тел-стиль үзенчәлекләре, лексик мәгънәсе, образлылыгы, рифма, строфа буенча шактый аерыла.

Рус поэзиясенең классик шигырь үлчәве – тугыз-сигез иҗекле үлчәве, С. Есенинның “Анна Снегина” поэмасында ун-тугыз үлчәве белән бирелгән.

Село, значит, наше-Радово, (9)	*Безнең авыл – шул Радово инед (10)*
Дворов, почитай, два ста. (7)	*Булса ике йөзләп өй бар (9)*
Тому, кто его оглядывал, (9)	*Килгән кеше бик яратып китә (10)*
Приятственны наши места (8)	*Безнең якта тормыш көе бар (9)*
Богаты мы лесом и водью, (9)	*Урман-суга шактый бай яшибез (10)*
Есть пастбища, есть поля (7)	*Көтүлек бар, кыр бар, болын бар (9)*
И по всему угодью (7)	*Ә басулар буйлап тезелеп киткән (11)*
Рассажены тополя (7)	*Без утырткан яшел тупыллар. (9)*

Оригиналның ритмикасын татар поэзиясе җирлегенә күчерү өчен, тәрҗемәче Г. Рәхим ун-тугыз үлчәве ала. Һәр юлда бер-ике иҗек артык чыга, ләкин, аның каравы тәрҗемә саф татарча яңгырый. Чөнки үлчәү үзенең бүгенге татар поэзиясендәге стилистик әһәмияте, яңгырашы ягыннан оригиналдагы үлчәүгә якын килә.

Оригиналның үзенчәлеген бирергә тырышып, тәрҗемәчеләр хәзерге татар әдәбиятында башка күп кенә үлчәүләрне дә кулланганннар һәм кулланалар. Бу тәрҗемәченең автор фикерләрен оригинал үлчәвенә яки шуңа якын үлчәүгә генә сыйдырып бетерә алмавыннан килеп чыга.

Шигырьнең музыкальлеге, эмоциональлеген арттыруда шигырь юлларын билгеле бер тәртиптә строфага берләштерүдә рифманың роле зур. Ә рифма оригиналда да, тәрҗемәдә дә икенче һәм дүртенче юлларда туры килә.

Каких уж тут ждать обилий, -	*Кая инде анда байлык, муллык* -
Была бы душа жива.	*Исән була күрсен тик җаны.*
Украдкой они рубили	*Сизмисең дә алар төнлә килеп*
Из нашего леса дрова.	*Тунап китә безнең урманны.*

Мәгънәгә зыян килмәгәндә, тәрҗемәнең сүзгә-сүз яки юлга юл килүе, әлбәттә, бик яхшы. Аерым очракларда исә мәгънә төгәллегенә һәм телнең төзеклегенә ирешү өчен, строфа эчендә юлларны алыштырырга, чагыштыруларны, заман, яки зат формаларын үзгәртергә туры килә.

Был вечер задумчиво чудный,	*Якын дустың елмаюы сыман*
Как дружба улыбка в лице.	*Гүзәл бер кич иде дөньяда.*

Монда шигырь юлларының тәртибе үзгәргән, ләкин аңа карап, мәгънәгә, шигырьнең интонацион, эмоциональ яңгырашына бернинди зәгыйфьлек килмәгән – әсәрнең идея- эчтәлеге оригиналдагыча сакланган, тик шигырь үлчәве генә юл саен берәр иҗеккә артып киткән, димәк, форма ягы туры килеп бетә алмый.

Тәрҗемәче татар теленең үзенчәлекләрен файдаланып, мәгънә сакланырлык итеп, башка сүзләр белән алмаштырып бирә:

Приятственны наши места	*Без бит чабаталы кұндәм халык.*
Безнең якта тормыш көе бар.	*Настал ожидаемый час*
А мы лишь простой народ.	*Сукты тәки безнең сәгать.*

Димәк, идея-художество үзенчәлекләренә, эчтәлегенә зыян килмәгәндә, тәрҗемәче кайбер детальләрне, чагыштыруларны, сурәтләү алымнарын, чараларын әдәби формага яраштырып үзгәртә яки төрле-төрле эквивалентлар белән алыштыра ала.

Күренгәнчә, тәрҗемәче шигырьне тәрҗемә иткән вакытта бер яктан, ритм, рифма, строфа, икенче яктан, лексика таләпләренә җавап бирерлек тел чараларын сайлап ала белергә тиеш. Татар теленең төрле-төрле үлчәүдәге шигырьләрне, төрле-төрле формадагы строфаларны оригиналдагыча итеп бирергә мөмкинлекләр җитәрлек, тик ул мөмкинлекләрдән файдаланырга, поэтик тәрҗемәдә эчтәлеккә түгел, поэтик формага нык игътибар бирергә кирәк.

Шунысы кызыклы: күп очракта бер үк поэзия әсәрләре төрле кешеләр тарафыннан кат-кат тәрҗемә ителә. Поэзияне тәрҗемә итү белән, гадәттә, шагыйрьләр шөгыльләнә һәм алар еш кына тәрҗемә әсәрләрен үз җыентыкларына кертәләр. Бер үк шигырьнең тәрҗемәләре арасындагы аерма бер үк проза әсәрләре арасындагы аермадан шактый зур була.

Шигъри тәрҗемәнең түбәндәге төрләре билгеле:

- ✓ **Стильгә салынган тәрҗемә** – тәрҗемәнең ирекле төре, гомуми мәгънә, эчтәлек саклана, ләкин төзелеше, формасы буенча оргиналыннан шактый ерак. Бу тәрҗемә төре шактый сирәк кулланыла.
- ✓ **Букваль тәрҗемә** – оригиналга ияреп тәрҗемә итү, сәнгатчә эшләнеше, шигри калып югалырга мөмкин. Бу тәрҗемә икенче төрле «подстрочный перевод» дип тә атала.
- ✓ **Функциональ тәрҗемә** – тәңгәллекләр сайлауга нигезләнә, текст оригиналга яраклаштырып эшләнә. Бу төр тәрҗемә киң таралган.
- ✓ **Әдәби тәрҗемә** – оргиналга ияреп тәрҗемә итү, шул ук вакытта тәрҗемә теле үзенчәлекләренә яраклаштырып эшләнә. Төп максат булып шигырнең стилен мөмкин кадәр саклау.
- ✓ **Формаль тәрҗемә** – кирәкле рифма һәм әйләнмәләр сайлап алып, сүзгә сүз тәрҗемә итү. Бу төр тәрҗемә иң идеаль санала.

Күренгәнчә, шигъри тәрҗемәдә төп авырлык тәрҗемәнең шигъри структурасы белән бәйле. Эш шунда: тәрҗемә иткән вакытта, тәрҗемә оригиналдан аерылырга мөмкин. Тәрҗемәче тәрҗемә итә башлагач, иң беренче булып шуны истә тотарга тиеш: шигырь юллары оригиналга якын килерме яисә юкмы. Беренче очрак авыр,ләкин иң кулае. Әгәр тәрҗемәче шигырьнең структурасын үзгәртергә тели икән, аңа нинди структура әйбәт икәнлекне ачыкларга кирәк. Бу вакытта шулай ук шигырьнең мәгънәви яктан тулыландыру турында да уйларга кирәк. Әсәрнең тышкы формасы, аның мәгънәсенә туры килергә тиеш. Кайбер очракларда татар теленнән рус теленә тәрҗемә иткәндә юлларда строфалар санын арттыру мөһим. Мәсәлән, дүрт стопалы ямбны,биш стопалы итү мөмкин. Шунысы ачык күренә: төгәл һәм сүзгә-сүз тәрҗемә булуы бик сирәк. Һәм ул кирәкми дә! Төп таяныч булып, оригинал текстагы фикерне, мәгънәне җиткерә алу һәм саклау. Укучы тәрҗемә текстын укыганын түгел, ә авторның оригинал

текстын укыган итеп тоелсын. Шигырьне тәрҗемә итүдә кайсы төргә нигезләнү, нинди алымнар куллану – барысы да тәрҗемәченең таланты һәм осталыгыннан тора.

Список литературы

1. Байрамова Л.К. Трансформация в переводах Тукая в басен И.А. Крылова //Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте: шагыйрьнең 110 еллыгына багышланган халыкара конференция метариаллары.– Казань, 1997. – С. 249-254.
2. Ганиев В. Тәрҗемәдәге төгәллек һәм нәфислек // Совет әдәбияты. - 1963. - №12. - 125-135 б.
3. Гривенко А.Н. Русский поэтический перевод в культурном контексте эпохи романтизма. — Москва: Изд-во УРАО, 2000. — 236 с.
4. Миннибаев К.С. Перевод – это искусство. Золотой век. – Казань: КГУ, 2004.
5. Курбатов Х. Татар телендә шигырь тәрҗемәсе (А.С. Пушкин тәрҗемәләре буенча) // Совет әдәбияты. – 1955. —№9. – 96б.
6. Курбатов Х. Шекспир сонетлары татар телендә // Совет әдәбияты. – 1957. № 6- Б. 117-119.
7. Нәбиуллина Г.Ә., Мөгътәсимова Г.Р. Тәрҗемә практикасы: әдәби һәм фольклор тәрҗемәләре. Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы. - Казань: Ихлас, 2012. – 91 б.
8. Юсупов Р.А. Тәрҗемәнең теоретик һәм практик мәсьәләләре. – Казан: ТДГПУ, 2011. – 312 б.

Рекомендуемые информационные ресурсы

9. http://nsportal.ru/shkola/rodnoi-yazyk-i-literatura/library/tukaynyn-trzhem-eshen-monsbte
10. Исхак Ә. Илһамнар хәзинәсе // http://www.robertminnullin.ru/index.php?option=content&task=view&id=133
11. http://russian-tatar.ru/
12. http://tatpoisk.net/dict/rus2tat/

Лекция № 9

ДРАМАТУРГИЯ ӘСӘРЛӘРЕН ТӘРҖЕМӘ ИТҮНЕҢ ТӨП АЛЫМНАРЫ

Аннотация. Данная тема раскрывает основные подходы к переводам драматургических произведений.

Ключевые слова. драманы тәрҗемә итү, драматургия тәрҗемәсе, әдәби текст, “уку өчен текст” (әдәби текст) һәм “сәхнәләштерү өчен текст”, милли-тарихи үзенчәлек, туры күчерү, адаптация, алмаштыру, семантик тәрҗемә, әдәби алым.

Методические рекомендации по изучению темы.

- Тема содержит лекционную часть, где излагаются основные подходы к переводам драматургических произведений.
- Для проверки усвоения темы имеются вопросы для изучения, также необходимо выполнить задание и отправить на проверку.

Вопросы для изучения

Исследования по переводу драматургических текстов.
Особенности драматургического перевода.
Перевод драмы, предназначенный для дальнейшей публикации и чтения.
Перевод драматургического текста с целью дальнейшей постановки.
Передача культурного компонента при драматургическом переводе.
Перевод имен собственных и титулов в драматических произведениях.

Сәнгатьнең бер төре булган театр борынгы чорлардан алып, бүгенге көнгә кадәр күңел ачуда гына түгел, кешеләрне тәрбияләү, мәгърифәтле итү һәм әхлакый чистарыну эшендә дә зур роль уйный. Бер сүз белән әйткәндә, театр, көндәлек тормышта да, сәхнәдә дә кеше, җәмгыять тормышы белән бәйләнештә тора. Эсхил, Калидаса, Кальдерон, Лопе де Вега, Шекспир, Расин, Мольер, Островский, Чехов, Ибсен, Шоу кебек дөнья әдәбияты авторларының тәрҗемә ителгән драмалары башка халыкларның әдәбиятын да баеткан. Ләкин, моңа карамастан, жанр буларак драманы тәрҗемә итү бүгенге көндә дә тәрҗемәчелекнең иң аз тикшерелгән аспектларының берсе булып тора. Әлеге мәсьәләгә багышланган бүгенге көн әдәбиятын анализлау, драматургия тәрҗемәсенең тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгәнлеге турында сөйли. Алман галиме Б.Шульц фикеренчә, поэзия һәм прозаны тәрҗемә итүнең теоретик һәм практик аспектларына багышланган хезмәтләр, бәлки, берничә киштәдә урын алырлар иде, ә драманы тәрҗемә итү һәм тәрҗемә итү стратегияләренә багышланган хезмәтләр зур булмаган бер китапка сыеп бетәрләр иде. Драманы тәрҗемә итү мәсьәләләрен үзләренең хезмәтләрендә А.Чередниченко, В.Коптилов, Т.Казакова, Н.Бидненко, П.Пави, Э.Кари, Б.Хатим, Р.-Ж.Пупар, Ю.Найда, Д.Жиль, С.Аалтонен, С.Тоцева һ.б. анализлыйлар.

Драматургия тәрҗемәсе әдәби әсәр тәрҗемәсе генә булып калмый. Тәрҗемәче аның сәхнә өчен булганын аңларга тиеш. Ләкин бик еш драматургия тәрҗемә авторлары, театрга хас булган “әйтем ситуациясен” исәпкә алмыйлар: текстның актер тарафыннан билгеле бер урында һәм билгеле бер вакытта, берьюлы һәм текстны, һәм аның куелышын кабул итүче конкрет аудитория өчен әйтелү ситуациясе. Раматургия

тәрҗемәсенә йогынты ясый торган факторлар, бу өлкәдә уңай нәтиҗәләргә ирешү өчен, әдәбият галимнәренә, режиссер, актер һәм продюсерларга мөрәҗәгать итүнең кирәклеген күрсәтәләр.

Драма үзенчәлекле статуска ия: ул әдәбият һәм театр чикләреннән тора. Бу икетөрлелек, шулай ук драма әсәренең театральләшүе актерларның, режиссерның, декораторларның, гримерларның, техникларның һ.б. күмәк иҗат җимеше булуы факты, драматургия текстының үзенчәлекләрен билгеләү мәсьәләсен катлауландыра.

Театраль сәнгать теоретиклары (Патрис Пави) «драматургия тәрҗемәсен», беренче чиратта, тәрҗемә ителгән пьесаның сәхнәдә куелышы контекстында карасалар, тәрҗемәчелек өлкәсендә эшләүче галимнәр әлеге мәсьәләгә башкачарак карыйлар. Б.Шульц драма тәрҗемәсен төгәл рәвештә икегә аера: публикация һәм уку өчен булган, ягъни әдәби текст буларак драма әсәре һәм сәхнәләштерү максаты белән тәрҗемә ителгән драма тексты. Тәрҗемә ителгән пьеса ике вариантта булырга мөмкин: “уку өчен текст” (әдәби текст) һәм “сәхнәләштерү өчен текст”. Аерым бер тәрҗемәчеләр драматургия текстының ике төрен дә бер вариантта бирә алганнар.

Сәхнәләштергән текстның уңышлы булу максатыннан, тәрҗемәче чыганак драманың мәдәни компонентын тапшыру мәсьәләсенә зур игътибар җирергә тиеш. Оригиналның милли-тарихи үзенчәлеген тәрҗемәдә кабат тудыру зур мәгънәгә ия, чөнки театрда, тормыштагыча, - бөтен нәрсә тамашачылар алдында. Тәрҗемәче башка тел реалийларына комментарийларда аңлатмалар китерә алмый, чөнки һәр тәрҗемә ителгән сүз (автор ремаркаларыннан кала) актер тарафыннан сәхнәдә әйтелә. Патрис Пави «тамашачыларның шәрехли белү компетенциясе” терминын кертә: башка мәдәният драмасын адекват рәвештә аңлау өчен, аудитория билгеле бер “мәдәни багаж”га ия булырга тиеш.

Драматургия тәрҗемәсендә мәдәни компонентны тапшыру ялгызлык исемнәрен һәм театраль пьеса персонажларының титулларын тәрҗемә итүдә ачык күзәтелә. Персонажларның исемнәре кебек үк, титуллар, мөрәҗәгать итүләр үзләрендә билгеле бер мәдәни-тарихи йөләнеш йөртәләр, тамашачылар тарафыннан исемнең өлеше буларак кабул ителәләр, һәм шуңа күрә аларны тәрҗемә итүдә үзенчәлекле якын килү таләп ителә.

Персонаж исемнәренең әлеге компонентларын тәрҗемә иткәндә, төрле методларны куллану зарур. Мәсәлән, Б.Шульц ялгызлык исемнәрне тәрҗемә итү өчен түбәндәге алымнарны тәкъдим итә:

1. туры күчерү;
2. адаптация;
3. алмаштыру;
4. семантик тәрҗемә;
5. әдәби алым.

Чыганак тел дә, тәрҗемә теле дә латин алфавитын кулланган очракта, персонаж исемен турыдан күчерергә була. «Адаптация» термины ялгызлык исеменең тәрҗемә телендәгечә уку һәм әйтү кагыйдәләренә туры китерелүен аңлата, икенче төрле әйткәндә,

бу – «транскрипция». Чыганак тексттагы исемнең тәрҗемә телендә аналогы булган очракта, алмаштыру алымы кулланыла ала: мәсәлән, рус исеме Иван инглиз телендә «John», алман телендә «Hans» буларак биреләчәк. Тәрҗемәче исемгә кертелгән денотатив мәгълүматны гына түгел, ә өлешчә коннотатив мәгълүматны да җиткерергә теләсә, семантик тәрҗемә кулланыла. Әдәби алым («transfer of an artistic device») автор тарафыннан уйлап чыгарылган исемнәрне тәрҗемә иткәндә кулланылырга мөмкин.

Титулларны тәрҗемә итүгә карата түбәндәге классификацияне китерик:

1. төшереп калдыру;
2. өстәү;
3. туры тәрҗемә;
4. адаптация;
5. семантик тәрҗемә;
6. алмаштыру.

Драма әсәрләрендәге ялгызлык исемнәрне һәм титулларны тәрҗемә итү тәрҗемәчедән иҗади якын килүне һәм төшеп калган өлешләрне компенсацияли белүне таләп итә.

Драматургия тәрҗемәсендә исем һәм титулларның тоткан ролен билгеләгәндә, драманың ике катлы табигате турында онытмаска кирәк. Иң беренче чиратта, исем һәм титулларның чыганак текстның кайсы урыннарында кулланылганнарын билгеләргә кирәк: катнашучылар исемлегендә генә әйтелеп китәләрме, яки автор ремаркаларында гына кулланылалармы, яки алар актерлар өчен булган диалог текстларына кертелгәннәрме. Тәрҗемә барышында диалогларда булган исем һәм титулларның кемгә караганлыгын да исәпкә алырга кирәк: әңгәмәдәшкәме яки сәхнәдә бөтенләй булмаган өченче заткамы. Мәсәлән, исем һәм титулын әйтеп, өченче зат турында сөйләү, аның сәхнәдәге геройлар белән мөнәсәбәтен күрсәтә ала.

Исем һәм титуллар, беренче чиратта, билгеле бер телнең, әдәбиятның, мәдәниятнең, театраль традициянең чагылдыручылары булып торалар. Ләкин алар берьюлы тәрҗемә ителгән тел йөртүчеләр аудиториясенә дә карарга мөмкин. Исем һәм титуллар мәдәниятнең дөньяви хәзинәсенә дә карарга мөмкин (Библия тәрҗемәсе). Һәм соңгысы, драма авторы махсус рәвештә нинди дә булса милли-мәдәни контекстка бәйле булырга теләмәгән очракта, исем һәм титуллар бөтенләй нейтраль булырга мөмкин.

Список литературы

1. Байрамова Л.К. Трансформация в переводах Тукая в басен И.А. Крылова //Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте: шагыйрьнең 110 еллыгына багышланган халыкара конференция метариаллары.– Казань, 1997. – С. 249-254.
2. Ганиев В. Тәрҗемәдәге төгәллек һәм нәфислек // Совет әдәбияты. - 1963. - №12. - 125-135 б.

3. Гривенко А.Н. Русский поэтический перевод в культурном контексте эпохи романтизма. — Москва: Изд-во УРАО, 2000. — 236 с.
4. Миннибаев К.С. Перевод – это искусство. Золотой век. – Казань: КГУ, 2004.
5. Курбатов Х. Татар телендә шигырь тәрҗемәсе (А.С. Пушкин тәрҗемәләре буенча) // Совет әдәбияты. – 1955. —№9. – 96б.
6. Курбатов Х. Шекспир сонетлары татар телендә // Совет әдәбияты. – 1957. № 6- Б. 117-119.
7. Нәбиуллина Г.Ә., Мөгътәсимова Г.Р. Тәрҗемә практикасы: әдәби һәм фольклор тәрҗемәләре. Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы. - Казань: Ихлас, 2012. – 91 б.
8. Юсупов Р.А. Тәрҗемәнең теоретик һәм практик мәсьәләләре. – Казан: ТДГПУ, 2011. – 312 б.

Рекомендуемые информационные ресурсы

9. http://nsportal.ru/shkola/rodnoi-yazyk-i-literatura/library/tukaynyn-trzhem-eshen-monsbte
10. Исхак Ә. Илһамнар хәзинәсе // http://www.robertminnullin.ru/index.php?option=content&task=view&id=133
11. http://russian-tatar.ru/
12. http://tatpoisk.net/dict/rus2tat/

Задания для практики по теме 5

5.1. **А.Толстойның “Анна Каренина**”әсәреннән алынган өзекнең тәрҗемәсенә анализ ясагыз.

Вронский удовлетворял всем желаниям матери. Очень богат, умен, знатен, на пути блестящей военной карьеры и обворожительный человек. Нельзя было ничего лучшего желать.

Вронский на балах явно ухаживал за Кити, танцевал с нею и ездил в дом, стало быть нельзя было сомневаться в серьезности его намерений. Но, несмотря на то, мать всю эту зиму находилась в страшном беспокойстве и волнении.

Сама княгиня вышла замуж тридцать лет тому назад, по сватовству тетки. Жених, о котором было все уже вперед известно, приехал, увидал невесту, и его увидали; сваха тетка узнала и передала взаимно произведенное впечатление; впечатление было хорошее; потом в назначенный день было сделано родителям и принято ожидаемое предложение. Все произошло очень легко и просто. По крайней мере так казалось княгине...

Вронский исә ананын барлык теләкләренә туры килә_иде. Бик бай, акыллы, атаклы, хәрби хезмәттә — сарай хезмәтендә аны менә дигән карьера көтә, үзе бик сөйкемле кеше. Анардан да яхшыракны теләү мөмкин дә түгел.

Вронский балларда ачыктан-ачык Кити артыннан ухаживать итә, анын белән танцевать итә, өйгә килеп йөри, димәк, ниятенең житди икәнлегенә шикләнү мөмкин түгел. Ләкин, шуна карамастан, бу кышны ана бик борчылып, бик дулкынланып үткәрде.

5.2 Дәрдмәнднең “Кораб” шигырен укып, фикер алышыгыз. Сезнеңчә, бу шигырь уңышлы тәрҗемә ителгәнме?

Кораб	Корабль
Шаулый диңгез,	И день и ночь
Җил өрәдер,	Грохочет море,
Җикәнен киргән кораб.	А паруса рвет ветер злой.
Төн вә көндез	Не превозмочь,
Ул йөрәдер:	Не переспорить,
Юл бара ят ил карап...	Несет корабль к земле чужой.
Чыкты җилләр,	Волна нагрянет,
Купты дулкын,	Ее кручина
Ил корабын җил сөрә...	Швырнет корабль страны
Кайсы юллар	родной.
Нинди упкын,	Какая тянет
Тарта безне җан сорап?	Нас пучина
	И жертвы требует какой?

5.3. А.П.Чеховның “Вишневый сад” әсәрен тәрҗемә итегез.

Яша остается, сидит возле часовни. Входят Любовь Андреевна, Гаев и Лопахин.

Лопахин. Надо окончательно решить, —время не ждет. Вопрос ведь совсем пустой. Согласны вы отдать землю под дачи или нет? Ответьте одно слово: да или нет? Только одно слово!

Любовь Андреевна. Кто это здесь курит отвратительные сигары... *(Садится.)*

Гаев. Вот железную дорогу построили, и стало удобно. *(Садится.)* Съездили в город и позавтракали... желтого в середину! Мне бы сначала пойти в дом, сыграть одну партию...

Любовь Андреевна. Успеешь.

Лопахин. Только одно слово! *(Умоляюще.)* Дайте же мне ответ!

Гаев *(зевая)*. Кого?

Любовь Андреевна *(глядит в свое портмоне)*. Вчера было много денег, а сегодня совсем мало. Бедная моя Варя из экономии кормит всех молочным супом, на кухне старикам дают один горох, а я трачу как-то бессмысленно. (Уронила портмоне, рассыпала золотые.) Ну, посыпались... *(Ей досадно.)*

Яша. Позвольте, я сейчас подберу. *(Собирает монеты.)*

Любовь Андреевна. Будьте добры, Яша. И зачем я поехала завтракать... Дрянной ваш ресторан с музыкой, скатерти пахнут мылом... Зачем так много пить, Леня? Зачем так много есть? Зачем так много говорить? Сегодня в ресторане ты говорил опять много и все некстати. О семидесятых годах, о декадентах. И кому? Половым говорить о декадентах!

Лопахин. Да.

Гаев *(машет рукой)*. Я неисправим, это очевидно... *(Раздраженно, Яше.)* Что такое, постоянно вертишься перед глазами...

ТЕМА 6. ӘДӘБИ ТӘРҖЕМӘНЕҢ ЛЕКСИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Лекция № 10

Аннотация. Данная тема раскрывает лексические особенности художественного перевода.

Ключевые слова. Лексик мәгънә, сүз тәңгәллекләре, телләрнең лексик-семантик системасы, диалекталь сүзне тәрҗемә итү, гади сөйләм сүзләрен тәрҗемә итү.

Методические рекомендации по изучению темы.

- Тема содержит лекционную часть, где излагаются основные лексические особенности художественного перевода.
- Для проверки усвоения темы имеются вопросы для изучения, также необходимо выполнить задание и отправить на проверку.

Вопросы для изучения

Значение слова в художественном переводе.
Адекватность и эквивалентность слова при переводе.
Семантические соответствия между лексическими единицами двух языков.
Полное соответствие слова.
Частичное соответствие слова.
Отсутствие соответствия.
Перевод диалектизмов.
Перевод просторечных слов.

Әдәби тәрҗемәдә сүзнең мәгънәсен бирү

Лексик мәгънә берничә компоненттан торган структура: сигнификатив, денотатив, этномәдәни. Мәсәлән, *елга, урман* сүзләре һәр телдә дә бер үк конкрет мәгънәне белдереп килә аларда денотатив компонент өстенлек итә; *мәһәббәт, изгелек* сүзләре исә абстракт мәгънәне белдереп, сигнификатив компонент өстенлек итә. *Гөслә* (борынгы рус уен коралы), *сомбреро* (Испаниядә, Латин Америкасы илләрендә кояштан саклану өчен кия торган җиңел эшләпә), лорд (Англиядә нәселдән килә торган дворян титулы). Этнокультур компонент денотатив һәм сигнификатив компонентлар белән дә тыгыз бәйләнгән. Лексик мәгънәсе этнокультур компонент белән характерланган сүзне (икенче төрле реалияләр дип тә атап йөртәләр) тәрҗемә итү авыр. Мәсәлән, *Вон за рощей <u>деревня</u>, вон подальше другая с белой <u>церковью</u>, вон березовой лесок на горе, за ним болото, куда вы едете (Тургенев. Лес и степь).*

Сүз номинатив (атау) һәм коннотатив (эмоциональ-бәяләү) функция үти. *Кош, туган, лес, дом* дигәндә чынбарлыктагы предмет-күренешләрне турыдан-туры атыйбыз, *кошчык, туганкай, домище, лесок* дигәндә турыдан-туры атап кына калмыйча, экспрессив чаралар нигезендә позитив бәяләү, эмоциональ төсмер салына. Кошчык сүзен маленькая птичка дип тәрҗемә итү дөрес булса да семантик яктан тулысынча адекват түгел. Иркәләү-кечерәйтү кушымчалары модальлекне, субъектив бәяләүне белдереп киләләр. Рус телендә арттыру мәгънәсен белдереп килгән модаль чаралар да бар. Мәсәлән, *Вот это домище! Какая сегодня жарище!*

Эмоциональ тонны саклаган хәлдә, мондый сүзләрне тәрҗемә итү, экспрессивлыкны тулысынча чагылдыру җиңел түгел,. (мәсәлән инглиз телендә рус һәм татар телләренә караганда, эмоциональ-бәяләү төсмерен белдерүче чаралар чагыштырмача сирәгрәк күзәтелә poetaster – поэтишка, oldster – старикашка). Бу очракта өстәмә рәвештә ярдәмлек сүзләр куллану кирәк була. Төрле телләрне чагыштырып өйрәнү шуны күрсәтә: субъектив бәяләүне белдерә торган кушымчалар универсаль чара түгел: славян, роман телләрендә киң таралган, герман телләрендә төрлечә чагылыш таба: алман телендә күбрәк, инглиз телендә, чагыштырмача азрак., сакндинавия телләрендә бөтенләй юк диярлек, төрки һәм монгол телләрендә оачрый (кытай, вьетнам телләрендә юк).

Сөйләмнең экспрессиясен белдерүче экспрессив-стилистик синонимнар исә (алар бары тик номинатив функция генә үтиләр) универсаль характерга ия. Сүзне тәрҗемә иткәндә, аның мәгънәсе, контекстта кулланылышы, эчтәлеге белән бергә, телдә лингвистик үзенчәлеге дә исәпкә алына.

Әлбәттә, һәр очракта да аерым сүз аерым бер сүз буларак тәрҗемә ителә алмаска да мөмкин. Бер сүз берничә сүз белән, киресенчә берничә сүз бер сүз белән тәрҗемә ителергә мөмкин, төп нөсхәнең кайбер сүзләре бөтенләй тәрҗемәдә бирелмәскә дә мөмкин.

Сүз тәңгәллекләре

Матур әдәбият тәрҗемәсендә сүз тәңгәллекләре шактый зур урын тота. Сүз тәңгәллекләре, мәгънәләре буенча, берничә төрле була.

1) оригинал сүзе дә, тәрҗемә сүзе дә туры мәгънәләрдә кулланыла.

2) оригинал сүзе дә, тәрҗемә сүзе дә күчерелмә мәгънәдә кулланыла, һәм сурәтләү чарасы булып тора. Мәсәлән*, Наступила золотая осень – Алтын көз җитте (Алекс., Коп. вит.)*

3) оригинал сүзе күчерелмә мәгънәдә, тәрҗемә сүзе туры мәгънәдә кулланыла.(*Небось, на нас не сунутся; а насунутся, так я такую задам отраску, что лет на десять угомоню. – Уйлама да, безгә килеп бәйләнәчәк түгелләр; ә инде бәйләнәләр икән, мин аларны шундый итеп кыздырырмын, бер ун ел тавыш-тыннарын чыгармаслар (Пушкин. Кап. дочка).*

4) оригинал сүзе туры мәгънәдә, тәрҗемә сүзе күчерелмә мәгънәдә кулланыла, һәм образлылык чарасын тәшкил итә. *Малышки обрадовались и стали приглашать Знайку в дома, чтобы он посмотрел внутреннее устройство. – Кызларның түбәләре күккә тия, алар аны, өй эчен дә күреп чыгарсың дип, өйләренә чакыра башлый.(Носов. Бел. Маҗ.)*

Кайбер очракларда образлы сүзгә икенче телдә тиң чара табып булмый, шуңа күрә сүз түңгәллекләренең соңгы ике төре, ягъни компенсация ысулы файдаланыла.

Аңлашылганча, сүз тәңгәллеге тәрҗемәдә сүзнең матди-логик мәгънәсен генә түгел, ә экспрессив-эмоциональ, стилистик мәгънәсен бирүне күздә тота. Эквивалентлы булган сүзләр, (аларны икенче төрле Р. Юсупов туры һәм даими тәңгәллекләр дип атый) – сүз тәңгәллегенең нигезен тәшкил итә.Әдәби тәрҗемәдә эквивалентлы булмаган сүз тәңгәллекләре дә очрый. Мәсәлән, *сказочник – мәзәкче, гомер – жизнь, моң – мелодия* һ.б. Сүз тәңгәллекләренә карамаган сүзләр дә очрый – алар оригиналда махсус тәрҗемә ителмичә төшеп калган, яисә киресенчә, тәрҗемәдә өстәп бирелгән сүзләр булалар.

Телләрнең лексик - семантик системаларындагы аерымлыклар сүзләрне тәрҗемә итү эшен катлауландыра. Тәрҗемә процессында ике тел сүзләре арасында төрле мөнәсәбәтләр урнаша.

- бер сүз берничә сүз белән тәрҗемә ителә: *Лучше если бы вы сами. – Сез үзегез барсагыз яхшырак булыр иде (М. Горький. Васса Железнова); Железнов возвращается к двери. Железнов кергщн ишегенщ таба кайта. (М. Горький. Васса Железнова); Действуйте. – Барыгыз, эшләгез (М. Горький. Васса Железнова)*
- берничә сүз тәрҗемәдә берничә сүз белән тәрҗемә ителә: *А мальчик будет жить у чужих людей, в чужой стороне – сиротой. – Сине төрмәләргә, сөргеннәргә куарлар, ә бала чит илләрдә (чит як, чит җир)ятим булып яшәр. (М. Горький).*
- бер тамырдан торган сүз кушма яисә тезмә сүз белән тәрҗемә ителә, яисә киресенчә, кушма, тезмә сүзләр бер тамырдан торган сүз белән тәрҗемә ителә: *домработница – асрау, мгновенно – күз ачып йомганчы, ладонь- уч төбе. Видешь, какой разностороний. – Кара син аны, нинди төрле яклы кеше (М.Горький. Васса Железнова).*

Күренгәнчә, әдәби тәрҗемәдә сүз белән эш иткәндә, иң беренче таләп – төп нөсхә сүзенә зур саклык белән карап, тәрҗемә телендә аңа функциональ-эстетик яктан төп-төгәл туры килерлек тәңгәллек табу. Оригинал сүзнең мәгънәсен контексттан чыгып

билгеләмәү, мәгънәсенә төшенмәү, эстетик тәсир көченә игътибар итмәү кебек хаталар мәгънә ялгышлыкларына, кытыршы тәрҗемәләргә китерә.

Мәсәлән, М. Шолохов әсәрләренең тәрҗемәсендә тәрҗемәчеләр рус крестьяны телендәге сүзләрне дөрес билгели алмаганнар. *Докажу, конечно, лишаю слова, даю отвод* сүзләрен кулланып сөйләү рус крестьяны өчен табигый булса да, татар крестьяны өчен, бигрәк тә 30 еллар өчен *исбат итәм, әлбәттә, сүздән мәхрүм итәм, отвод бирәм, шушы моментта* дип сөйләү гадәти түгел. Бу мәгънәләрне гадирәк сүзләр белән бирергә мөмкин иде. Бу – тәрҗемә стиль ягыннан туры килеп бетми дигән сүз.

Тын Дон" романында карт Лисницкий Аксиньяны начар эшләве өчен ачуланып, ′если так будет повторяться, ...то я тебя уволю" ди. Татарчага тәрҗемәдә шулай бирелгән: *«шушылай кабатлана торган булса, мин сине эшеңнән азат итәм".* Азат итү, гомуми мәгънәсе буенча уволить мәгънәсенә туры килсә дә, контекстуаль-стилистик мәгънәсе буенча дөрес алынмаган – *эштән чыгаралар* яисә, *эштән куалар* дип әйтү күбрәк туры килер иде. Мәсәлән, М. Горькийның "Васса Железнова" әсәрендә *А мальчик будет жить у чужих людей, в чужой стороне – сиротой* җөмләсе *Сине төрмәләргә, сөргеннәргә куарлар, ә бала чит илләрдә (чит як, чит җир)ятим булып яшәр. (М. Горький).* дип тәрҗемә ителгән. Бу тәрҗемәдә сүзләрнең мәгънәләрен дөрес бирмәү күзәтелә. *Чужая сторона чит ил* буларак тәрҗемә ителгән. Оригиналда чужая сторона чит як, чит җир мәгънәсендә кулланылган, чөнки Васса Железнова өчен Коляның чит илгә генә китүе генә түгел, ә Россиянең башка почмакларында каңгырып йөрүе дә чит төбәк санала.Чужая сторона үзенең мәгънәсе белән чит илгә караганда күпәк иңрәк һәм тирәнрәк. Шул ук әсәрдә Страшная вы фигура җөмләсе – Куркынычлы кеше сез дип бирелгән. Монда да фигура сүзе кеше (человек) лексемасы алып килгән мәгънәдән күпкә тирәнрәк. Фигура дигәндә, әлеге контекстта көчле эмоциональлек күзгә ташлана. Фигура сүзе билгеле бер тискәре сыйфатларга ия булган тип буларак аңлашыла. Анда да кешегә хас булган җанлылык тоемланмый. Рашель Вассага шундый бәя бирә дә. Фигура сүзенең аналогы татар телендә булмау сәбәпле, аны үзгәртмичә куллану күпкә отышлырак булыр иде.

Оригиналдагы әдәби сүзне гади сөйләм сүзе, яисә диалекталь сүз белән тәрҗемә итү дә зур стиль хатасы булып тора.

Кайбер очракларда тәрҗемәдә ителгән җөмләдә сүз өстәлү күренеше күзәтелә. Җөмләдәге эмоциональлекне, экспрессияне татар телендә мөмкин кадәр тулырак җиткерү максатында, тәрҗемәчеләр модаль сүзләр, кисәкчәләр кулланалар. шулар арасында иң актив формалар булып әйе, юк, инде, үк, гына сүзлүре кулланыла.

Мәсәлән,

Теперь что будет? – Хәзер нәрсә булыр инде?

У меня - дочери.- Минем бит кызларым бар.

Этого – не жди.- Ансын көтмә инде.

Ну и дура! – Ну, җүләр дә соң син! (М. Горький. Васса Железнова)

Билгеле мондый берәмлекләр әсәр тукымасына килеп кергәч, гомумконтекстка үзләреннән билгеле бер мәгънә төсмере өстиләр. Мисаллардан аңлашылганча, бу өстәмә

эмоциональлек тудыру белән бәйле. Бу үз чиратында, интонациянең дә үзгәрүенә китерә. Барлык очракларда да тәрҗемәдә сүзләр өстәлү уңай күренеш буларак бәяләнә алмый. Артык сүзләр өстәү еш кына фикерне җыйнаксызландыра, төссезләндерә.

Лиза вносит маленький самовар, за ней – Наталья с подносом посуды.

Лиза кечкенә самовар кертә, аның артыннан – Наташа поднос белән савыт-саба күтәреп керә. (М. Горький. Васса Железнова)

Күтәреп керә һәм кертә фигыльләре, икесе дә, нигездә, бер үк эш-хәрәкәтне белдерә. Тәрҗемәне җыйнакландыру максатыннан, ике иягә бер хәбәр калдыру отышлырак булыр иде – *Кечкенә самовар күтәреп Лиза, аның артыннан поднос белән савыт-саба тоткан Наташа күренә.*

Тәрҗемәдә сүзләр өстәлү бөтен очракларда да тәрҗемәче теләге булмыйча, ә бәлки мәҗбүри бер фактор буларак та кертелергә мөмкин. Мисал өчен, алдагы җөмләдә дождевой зонтик яңгырдан саклый торган дип бирелә. Билгеле, җәенке аергыч килеп чыкккан, әмма бу очракта башкача мөмкин дә булмас иде.

Диалектизмнарны, гади сөйләм сүзләрен тәрҗемә итү

Диалектизмнар, гади сөйләм сүзләре матур әдәбият әсәрләрендә шактый киң кулланыла һәм әһәмиятле сурәтләү чараларын тәшкил итәләр. Диалектизмнар һәм гади сөйләм сүзләре персонажларның нидивидуаль сөйләмен белдерүгә ярдәм итәләр. Диалектизмнарны һәм гади сөйләм сүзләрен тәрҗемә итү мәсьәләсе озак еллар буе бәхәсле мәсьәлә булып торды. Күп кенә тәрҗемәчеләр, аерым алганда, А.В. Федоров һ.б. оригинал диалектизмнарын диалекталь сүзләр белән тәрҗемә итеп булмый дип саныйлар. Ләкин моңа карап кына диалекталь сүзләрнең адекват тәңгәллеген, функциясен икенче телдә бирү мөмкин түгел дигән сүз түгел. Диалектизмнарны һәм гади сөйләм сүзләрен икенче телдә гәүдәләндерүнең төрле чаралары бар. Р. А. Юсупов та “ ...гомумән алганда, әсәрләрдә диалектизмнарны гәүдәләндерү тулы кыйммәтле тәрҗемә таләпләренә җавап биреп бетерә алмый”, дигән караштa тора. Бу специфик катлам тәрҗемәдә тулы яки өлешчә транслитерация яисә тәрҗемә телнең морфологик чаралары өстәлеп бирелә, Мондый сүзләрне оригиналдагыча калдыру милли колоритны бирүгә дә хезмәт итә.

М. Шолоховның “Күтәрелгән чирәм” әсәрендә түбәндәге диалектизмнар һәм гади сөйләм сүзләре очрый: *трошки, нехай, теперича, с энтих пор, столечко, насбираю, возля, сымали, зараз, дюже, гутарить, иттить, сполняю, сурьезный, шутейный, плант, пущай, ноне, с коньми, н природу интересоваться, шорт, жизня, езать*. Татар теленә тәрҗемәдә гади халык сөйләменең матур бизәкләре югалган, Шолоховның җанлы, бай, көчле теле фәкыйрьләнгән. “Тын Дон” әсәренең тәрҗемәсендә исә кайбер диалекталь һәм гади сөйләм сүзләрен очратырга мөмкин: *әкертен, бер шәй, катын, перәме, алдамакчы келиләр, гарык, шул тиклем, иңгәвәле, валла, апкитәм, кортка, нибуч, цинең, бурыцың* һ.б.Бирелә **ч** урынына мишәр диалекты вәкилләренә хас **ц** авазы куллану, һәм шулай ук лексик диалектизмнар (Татарстанның көнчыгыш районнарында яшәүчеләр

телендәге кортка сүзе), - мак кели формасын куллану хас. Нәтиҗәдә Донда булган вакыйгалар, андагы кешеләр Татарстанның һәм башка өлкәләрнең аерым районнары территориясенә күчерп куелган кебек була.

Диалектизмнарны ткенче телдә шундый ук чаралар белән бирергә ярамый, тәрҗемәдә аларның эстетик әһәмиятләрен бирерлек чаралар эзләргә туры килә. Иң әһәмиятле чараларның берсе – үзенчәлекле бизәкләре булган, гади халык сөйләме элементларыннан торган персонаж теле белән тәгъбир итү. Укучыны персонаж сөйләменең конкрет нинди тел чараларыннан торуы кызыксындырмый, аның өчен әдәби нормаларга нигезләнгән гадәти телдән аерылып торган үзенчәлекле телен тою әһәмиятле. Тәрҗемәченең бурычы - әсәрне икенче телдә укучыда да шундый ук тойгы туарлык итеп эшләү. Персонажларны әдәби булмаган телдә сөйләтү әһәмиятле. Укучыга аңлашылырлык гади сөйләм сүзләрен, архаизмнар, жаргон сүзләр, диалекталь характеры аз гына сизелерлек сүзләрне файдаланырга мөмкин. Әлбәттә, һәр очракта да тәңгәллекләр табу мөмкин түгел. Шуңа күрә күпчелек очракларда компенсация алымын кулланырга туры килә. Бер урында диалектизм яки гади сөйләм сүзе әдәби сүз белән тәрҗемә ителсә, икенче бер урында оригиналның әдәби элементы гади сөйләм сүзе ярдәмендә бирелә. Мәсәлән, “ Күтәрелгән чирәм”дә ***гутарить*** ны ***сөйләшү*** дип тәрҗемә итәбез икән, ***жена*** сүзен ***катын*** дип тәрҗемә итәргә мөмкин. Компенсация бер үк герой телендәге сүзләрдә генә ясалырга тиеш, әлбәттә. Югыйсә, бу оригинал геройлары телен үзгәртүгә һәм, димәк, төп нөсхәне бозуга китерер иде.

Матур әдәбияттта лексик, фонетик, морфологик диалектизмнардан тыш, синтаксик диалектизмнар да кулланылырга мөмкин. Әдәби тәрҗемәдә инверсия ысулын һәм әдәби яктан дөрес төзелмәгән җөмләләрне уңышлы файдаланып төзелгән җөмләләрне очратырга мөмкин. Мәсәлән, “Тын Дон”ның тәрҗемәсендә *Менә, ни, без килдек инде, Мирон Григорьевич, сезнең уегызны белергә дип...; Безнең казаклар бит сөйләгәннәр иде, Степан күз алдыбызда үлеп калды, дип.* Бу җөмләләрдә максат хәле һәм иярчен тәмамлык җөмлә инверсияләнеп килгәннәр.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, диалектизмнарны һәм гади сөйләм сүзләрен тәрҗемә иткәндә, файдаланыла торган чаралар укучыларга аңлаешлы булырга, диалекталь характеры бик сизелеп тормаска тиеш.

Список литературы

1. Байрамова Л.К. Татарстан: Языковая симметрия и ассиметрия/Л.К. Байрамова. — Казань: КГУ, 2001. — 267 с.
2. Виноградов В.В. Лексические вопросы перевода художественной прозы/В.В. Виноградов. — М.: Изд-во МГУ, 1978. — 174 с.
3. Иванов А.О. Безэквивалентная лексика и её перевод на русский язык. Уч. пособие. - Л., 1985.
4. Комиссаров, В. Н. Лингвистика перевода. – М.: ЛКИ, 2007. – 165 с.

5. Латышев Л.К. Эквивалентность перевода и способы её достижения. - М.: Междунар. отношения, 1981. - 248 с.
6. Миннибаев К.С. Перевод – это искусство. Золотой век. – Казань: КГУ, 2004.
7. Нәбиуллина Г.Ә., Мөгътәсимова Г.Р. Тәрҗемә практикасы: әдәби һәм фольклор тәрҗемәләре. Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы. - Казань: Ихлас, 2012. – 91 б.
8. Черняховская Л.А. Перевод и смысловая структура: М., Междунар. отношения, 1976 - 264 с.
9. Юсупов Р.А. Тәрҗемәнең теоретик һәм практик мәсьәләләре. – Казан: ТДГПУ, 2011. – 312 б.

Рекомендуемые информационные ресурсы

10. http://nsportal.ru/shkola/rodnoi-yazyk-i-literatura/library/tukaynyn-trzhem-eshen-monsbte
11. http://russian-tatar.ru/
12. http://tatpoisk.net/dict/rus2tat/

Лекция № 11

ЛЕКСИК СУРӘТЛӘҮ ЧАРАЛАРЫН ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ЫСУЛЛАРЫ

Аннотация. Данная тема раскрывает способы перевода лексических средств.

Ключевые слова. Лексик сурәтләү чаралары, метафоралар, чагыштырулар, эпитетлар, сүзгә-сүз тәрҗемә, компонентны үзгәртеп тәрҗемә итү, алмаштыру, компенсация ысулы.

Методические рекомендации по изучению темы.

- Тема содержит лекционную часть, где излагаются способы перевода лексических средств.
- Для проверки усвоения темы имеются вопросы для изучения, также необходимо выполнить задание и отправить на проверку.

Вопросы для изучения

Способы перевода лексических средств.
Полное соответствие.
Частичное соответствие.
Замена.
Компенсация.

Перевод сравнений.
Перевод метафор.
Перевод эпитетов.

Лексик сурәтләү чараларына фразеологик әйтелмәләр, метафоралар, чагыштырулар, эпетитлар һ.б. керә. Әдәбият белемендә аларны икенче төрле поэтик чаралар дип атыйлар, стилистик фигуралар рәтендә дә карыйлар. Бу чаралар матур әдәбиятның икенчел образлылык системасын тәшкил итәләр.

Төрле телләр өчен сүзләрнең фразеологик бәйләнешендә, образлылык системасында уртак һәм үзенчәлекле яклар бар. Чөнки төрле халыкларның тормыш-көнкүрешендә, яшәешендә, хисләрендә, сәнгатьчә фикерләвендә, табигать, җәмгыять күренешләрен күзаллау, үзләштерү характерында һәм уртак һәм аермалы сыйфатлар бар. Бертөрле фәлсәфи караш, сәнгатьчә фикерләү нәтиҗәсе буларак ике телдә дә мәгънәләре һәм образлары бертөрле булган сурәтләү чаралары бар. Шуңа бәйле рәвештә, әдәби тәрҗемә процессында андый чараларны төгәл яки турыдан-туры тәрҗемә итү мөмкинлеге туа.

Шул ук вакытта һәр телнең үзенә генә хас образлылык чаралары бар. Мәсәлән, татарларда кара күзне шомыртка охшату бар, русларда андый чагыштыру юк. Карчыга русларда уңай образ, ә татарларда тискәре. Мондый лексик сурәтләү чараларын исә турыдан-туры тәрҗемә итү мөмкин түгел. Тәрҗемәче эмоциональлеге, эстетик тәэсир итү көче буенча оригиналга тиң булырлык сурәтләү чараларын эзләп таба. Ләкин тәрҗемәче бер үк вакытта төп нөсхәнең милли колоритын, үзенчәлеген, авторның индивидуаль стилен (идеалектын) сакларга тиеш.

Лексик сурәтләү чараларын тәрҗемә иткәндә, 4 ысул файдаланыла:

a. төгәл яки сүзгә-сүз тәрҗемә;
b. аерым компонентларын үзгәртеп тәрҗемә итү;
c. тәрҗемә телендәге әзер сурәтләү чарасы белән алмаштыру;
d. компенсация ысулы белән тәрҗемә итү.

Чагыштырулар, метафора, эпитетлар – лексик сурәтләү чаралары, икенче төрле аларны әдәбият белемендә троплар дип тә атыйлар. Фразеологизмнар, һәм мәкаль-әйтемнәр кебек алар да 4 ысул нигендә тәрҗемә ителәләр. Иң актив ысулларның берсе - сүзгә-сүз, ягъни калькалаштырып тәрҗемә итү һәм компонентларның берсен үзгәртеп тәрҗемә итү. Чөнки, тропларны образлылыкларын саклап тәрҗемә итү – оригиналның мәгънәви һәм сәнгатьлелек әһәмиятен тулы итеп бирүдә әһәмиятле чара. Рус һәм татар халкының сәнгатьле фикерләвендәге уртаклыкларның зур булуы да моңа ярдәм итә.

Беренче ысул нигезендә тәрҗемә ителгән тропларны карыйк: *ясные, как летнее небо, глаза – җәйге аяз күк йөзе төсле күзләр, это похоже было на плавание судна по бурному морю – бу давыллы диңгез өстендәге көймәгә охшый, как рыба на приводу – җимгә быелган балык кебек, глаза, холодные как лед – боз кекбек салкын күз, как грибы после дождя – яңгырдан соң үсеп чыккан гөмбәләр төсле;*

Эпитетлар: *холодное слово - салкын сүз, масляный голос – майлы тавыш, скромный одуванчик – тыйнак тузганак, молодой желтоусый меяц - сары мыеклы яшь ай, золотые руки - алтын куллар;*

Метафоралар: *золотая середина – алтын урталык, первые ласточки – беренче карлыгачлар, воздушные ворота – һава капкасы;*

Икенче ысул нигезендә тәрҗемә ителгән тропларга мисаллар: *похоже было на плавание судна по бурному морю (Пушкин) – давыллы диңгез өстендәге көймәгә охшый (Чаг.); плотный как чувал с зерном – арыш тутырган капчык шикелле (чаг.); неожиданнаая милость с неба - күктән төшкән бүләк (Мет)*

Аерым очракларда оригиналдагы троплар тәрҗемә теленең әзер троплары белән алмаштырып тәрҗемә ителә. Бу иң беренче чиратта, телләрнең үзенчәлекле образлы фикерләү рәвеше белән бәйле. Мәсәлән, карчыга руслар өчен уңай, татарлар өчен тискәре образ, сөлек руслар өчен тискәре, татарлар өчен уңай образ. Алмаштырып тәрҗемә иткәндә, сурәтләү чарасының образы үзгәрә, ләкин күчерелмә мәгънәсе, эмоциональ тәэсир итү көче буенча оригиналга тиң булырга тиеш. Мондый образларга корылган сурәтләү чаралары тәрҗемә иткәндә үзгәртелми кала алмый, әлбәттә. “Тропларны алмаштыру юлы белән тәрҗемә иткәндә, тәрҗемә теленең реалияләре катнашмаска тиеш. Югыйсә бу тарихи чынбарлыкны бозуга китерә”, дип саный Р. А. Юсупов.

Тропларны нейтральләштереп тәрҗемә итү әдәби тәрҗемәдә сирәк очрый. Бу ысул тәрҗемә телендә оригиналдагы сурәтдәү чарасына күчерелмә мәгънәсе һәм образлылыгы белән туры килерлек чара табылмаганда, кулланыла. Мәсәлән, *Стало быть: от этой песни везде слезьми плачут (М. Шолохов)* дигән җөмлә *Димәк, бөтен җирдә шул хәл* дип туры мәгънәдәге сүзләр белән тәрҗемә ителә.

Бераз үзгәртеп тәрҗемә итү нәтиҗәсендә туган яңа сурәтләү чаралары беренче карашка сәер тоелырга мөмкин. Моңа карап тропларны тәрҗемә итмичә калдырыга мөмкин түгел.

Матур әдәбиятта гомумпоэтик троплар белән беррәттән язучы теленә генә индивидуаль троплар да урын алалар. Һәм аныдый чаралар язучының индивидуаль үзенчәлеген, стилен булдыруда катнашалар. Мисалга Такташны искә төшерик: *еллар кәкрәгендә....*

Март аеның нечкә билле җиле сузылып ятып җиргә кар ашый.

Аларны тәрҗемә итү тагын да игътибарлы булу сорала.Автор тарафынна уйлар табылган яңа метафоралар, чагыштырулар, эпитетлар оригинал теле ияләре өчен дә гадәти булмыйлар. Шуңа күрә, иң беренче чиратта, индивидуаль тропларның контексттагы күчерелмә мәгънәләрен, эмоциональ дәрәҗәсен аңларга кирәк. Тәрҗемә принциплары язучының индивидуаль тропларын максималь дәрәҗәдә саклануны күздә тота. Индивидуаль тропларны тәрҗемә телендәге әзер троплар белән алмаштыру үзен акламаска мөмкин, шуңа күрә автор иҗат иткән сурәтләү чарасын, тел бизәген тәрҗемәдәдә автордагыча итеп саклау әһәмиятле. Тәрҗемәче аны, туган тел нормасын бозмыйча, төгәл тәрҗемә итәргә тиеш.

Шолоховның тәрҗемәләрендә кояш тол хатындай елмая, су елап калды, йомшак тавыштан бөтнек исе килә, майлы тавыш, һ.б.шундый троплар бирелгән. Шактый уңышлы, уйланган чаралар. Мондый тәрҗемәләр, әлбәттә, язучының индивидуаль стилен булдыруда катнашалар.

Кайвакыт матур әдәбиятта урынсыз тәрҗемәләр дә очрый. Мәсәлән, Шолоховның “Күтәрелгән чирәм” әсәрендә *Ясными, как летнее небушко, глазами* дигән чагыштыру үзгәртеп – *җәйге аяз көн төсле зәп-зәңгәр күзләрен* дип тәрҗемә ителгән. Бу логик яктан дөрес түгел: *зәңгәр күзләрне* көн белән чагыштырып булмый; *җәйге аяз күк йөзе төсле зәңгәр күзләр* дигән чагыштыруны сакларга кирәк иде.

Сөйләгәннәргә нәтиҗә ясап әйткәндә, тропларны тәрҗемә иткәндә, тәрҗемәче теге яки бу сурәтләү чарасының укучыга аңлашылуын, эмоциональлек дәрәҗәсен, тәрҗемә теленең мөмкинлекләрен дөрес билгеләргә тиеш.

Список литературы

1. Алексеева И. С. Введение в переводоведение. Учебное пособие /И.С. Алексеева. — Москва. — Санкт-Петербург: ACADEMA, 2004. — 352 с.
2. Байрамова Л.К. Татарстан: Языковая симметрия и ассиметрия/Л.К. Байрамова. — Казань: КГУ, 2001. — 267 с.
3. Виноградов В.В. Лексические вопросы перевода художественной прозы/В.В. Виноградов. — М.: Изд-во МГУ, 1978. — 174 с.
4. Комиссаров В. Н. Лингвистика перевода. – М.: ЛКИ, 2007. – 165 с.
5. Латышев Л.К. Эквивалентность перевода и способы её достижения. - М.: Междунар. отношения, 1981. - 248 с.
6. Миннибаев К.С. Перевод – это искусство. Золотой век. – Казань: КГУ, 2004.
7. Нәбиуллина Г.Ә., Мөгътәсимова Г.Р. Тәрҗемә практикасы: әдәби һәм фольклор тәрҗемәләре. Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы. - Казань: Ихлас, 2012. – 91 б.
8. Юсупов Р.А. Тәрҗемәнең теоретик һәм практик мәсьәләләре. – Казан: ТДГПУ, 2011. – 312 б.

Рекомендуемые информационные ресурсы

http://nsportal.ru/shkola/rodnoi-yazyk-i-literatura/library/tukaynyn-trzhem-eshen-monsbte
http://russian-tatar.ru/
http://tatpoisk.net/dict/rus2tat/

Лекция № 12

Фразеологик әйтелмәләрне тәрҗемә итү

Аннотация. Данная тема раскрывает способы перевода фразеологизмов.

Ключевые слова. Фразеологизмнар, сүзгә-сүз, ягъни калькалаштырып тәрҗемә итү, фразеологизм составындагы берәр компонентны үзгәртеп тәрҗемә итү, алмаштырып тәрҗемә итү, компенсация алымы, телара фразеосемантик тәңгәлллекләр**.**

Методические рекомендации по изучению темы.

- Тема содержит лекционную часть, где излагаются способы перевода фразелогизмов..
- Для проверки усвоения темы имеются вопросы для изучения, также необходимо выполнить задание и отправить на проверку.

Вопросы для изучения

Способы перевода фразеологизмов.
Полное соответствие.
Частичное соответствие.
Замена.
Компенсация.

Фразеологизмнар сөйләмне баетуда, үтемлерәк, көчлерәк һәм үткенрәк итүдә, художестволы әсәр стиленә сәнгатьлеле бирүдә, фикерне тулырак ачуда әһәмиятле роль уйный. Фразеологик материал язучы телендә алтын фонд санала. Аннан оста файдалана белү – язучы әсәренең уңышлы һәм отышлы ягы: автор образларны, вакйгаларны сиземлерәк итеп сурәтли, аларга үзенчәлекле төс кертә, әсәр теленең халыкчанлыгын, гадилеген, аһәңле яңгырашын тәэмин итә. Телнең фразеологик байлыгын, аның төзелешен, семантикасын яхшы белү тәрҗемә эшендә бик тә кирәк.

Фразеологизмнарны тәрҗемә итү мәсьәләсенә килгәндә, иң элек шуны әйтеп үтәргә кирәк: фразеологизмнар - гомуми-күчерелмә мәгънәлелеккә нигезләнгән универсаль берәмлекләр. Фразеологизмнар дөньядагы барлык телләргә хас тел җәүһәрләре. Аларны тәрҗемә итү закончалыклары турында сөйләгәндә, әлбәттә фразеологимнар, аларның төрләре турындагы теоретик мәгълүматлар, һәм бигрәк тә аларның тел универсалийлары булуы (типологиясендә дә универсальлек) мөһим роль уйный.

Рус теленнән татар теленә фразеологизмнарны тәрҗемә итүнең характеры, ысуллары төп ике факторга бәйле. Беренчесе – сүзтезмә, җөмлә составына кергән сүзләрнең фразеологик бйәләнешендә төрле телләр өчен уртак һәм үзенчәлекле яклар булу һәм әйтелмәләр составындагы элементларның бер-берсенә ни дәрәҗәдә береккән булуы. Икенче фактор – төрле халыкларның тормыш-көнкүрешендә, фикерләү рәвешендә, табигать, җәмгыять күренешләрен күзаллау, үзләштерү характерында уртак һәм үзенчәлекле сыйфатлар булу. Фразеологизмнарны бер телдән икенче телгә

күченргәндә туры тәңгәллекләр яки читләтелгән тәңгәллекләр белән эш итү мәсьләсе әнә шул ике фактордагы уртак һәм үзенчәлекле яклар белән турыдан-туры бәйләнештә тора.

Фразеологик әйтелмәләрне тәрҗемә итү ысуллары аерым компонентларның мөстәкыйль мәгънәләре саклану-сакланмау һәм тотрыклылык дәрәҗәсенә бәйле. Компонентлар мөстәкыйль мәгънәләрен никадәр күбрә сакласалар, бәйләнеш никадәр йомшаграк булса, фразеологизм шулкадәр төгәлрәк тәрҗемә ителә. Һәм киресенчә, компонетлар бер-берсенә никадәр ныграк берексә, фразеологик бөтенне сүзгә-сүз тәрҗемә итү мөмкинлеге шулкадәр азрак була. Фразеологик тезмәләр һәм фразеологик бердәмлекләр сүзгә-сүз, ягъни калькалаштыру юлы белән тәрҗемә ителәләр, фразеологик ныгымалар (сращения) исә , гадәттә турыдан-туры тәрҗемә ителмиләр.

Фразеологик әйтелмәләр, Р.А. Юсупов хезмәтләрендә 4 ысул нигезендә тәрҗемә ителәләр дип аңлатыла.

1) Сүзгә-сүз, ягъни калькалаштырып тәрҗемә итү.

Фразеологик тезмәләр (сочетания) һәм кайбер фразеологик бердәмлекләр (единства) әлеге ысул нигезендә тәрҗемә ителәләр. Төрле телләрдә, аерым алганда, татар һәм рус телләрендә, күп заманнардан бирле кулланылып килгән, аларның кайсы телдән алынуы да билгесез булган яки ике телдә дә параллель барлыкка килгән фразеологик әйтелмәләр урын ала. Мәсәлән, *смотрет через пальцы – бармак аша карау, ставит вопрос ребром – сорауны кабыргасы белән кую, ставить точку- нокта кую, заткнуть рот- авызын томалау, наступить на хвост – койрыгына басу, лить воду в мельницу – тегермәнгә су кою.* Бу төр фразеологизмнарның кайберләре рус теленнән калькалаштырып алынган һәм татар теле хәзинәсенә әверелгән. Аларның саны арта барып, әдәби тәрҗемәдә генә түгел башка төр тәрҗемәләрдә дә, сөйләм телендә дә актив кулланылалар.

2) Фразеологизм составындагы берәр компонентны үзгәртеп, ягъни ярымкалькалаштыру юлы белән тәрҗемә итү;

Икенче ысул белән фразеологик тезмәләр һәм бердәмлекләр тәрҗемә ителә. Оригинал фразеологизмның күчерелмә мәгънәсе, эмоциональлеге саклана. тик образы гына берникадәр үзгәрә. Мәсәлән, *шагать в ногу с жизнью – заман белән бергә атлау; достать птичье мололо – күгәрчен сөте табу; не входить в рамку – киртәгә сыймау, как без рук – ике кулсыз калу, тонкий аромат – хуш ис* һ.б. Күренгәнчә, бу тәрҗемәләрдә рус һәм татар телендәге аерым сүзләрнең фразологик әйтелмәләр төзүдәге милли үзенчәлекләре саклана.

Рус фразеологизмнарын калькалаштыру һәм ярымкалькалаштыру юлы белән тәрҗемә итү зур урын алып тора. Мондый тәрҗемә нәтиҗәсендә татар теле яңа фразеологизмнарга байый. Биредә шуны истә тоту зарур – калькалаштырылган фразеологик әйтелмәләр татар теленең үз синтаксик закончыгына нигезләнеп төзелергә тиеш, төгәлрәге, сүзләр бәйләнеше нормасы бозылмаска тиеш, дип саный Р. А. Юсупов.

3) **Алмаштырып тәрҗемә итү.** Фразеологизм күчерелмә мәгънәсе һәм эмоциональ-экспрессивлыгы буенча туры килгән тәрҗемә телендәге башка бер фразеологизм белән алмаштырыла. Мондый ысул белән, гадәттә, фразеологик

ныгымалар тәрҗемә ителә. Мәсәлән, *лясы точить – ләчтит сату, быть на седьмом небе – түбәсе күккә тию, бить баклуши – трай тибү, когда на горе рак свистнет – кызыл кар яугач, галду набивать – колак итен ашау.*

4) **Фразеологизмны компенсация алымы кулланып тәрҗемә итү.** Бу очракта оригинал телдәге фразеологизмның күчерелмә мәгънәсе нейтральләштереп – эмоциональ-экспрессивлыгы, образлылыгы югалтып бирелә. Бу алым әсәрнең эстетик тәэсир итү көченә зыян китермәскә тиеш. Бу очракта фразеологизм туры мәгънәсендәге гади бер сүз яки сүзтезмә белән тәрҗемә ителә яисә киресенчә, гади бер сүз яки сүзтезмә фразеологизм белән тәрҗемә ителә. Мәсәлән, *твердить свое – үз туксаны туксан, наломать дров - әллә ниләр эшләп ташлау һ.б.*

Шулай да һәр телдә дә бер үк фразеологизмнарны калькалаштыруга гына кайтарып калдырырга ярамый.

Мәгънәләре һәм образлыклары белән туры килгән фразеологизмнарның кулланылуы төрле халыкларның да тормыш тәҗрибәсе охшашлыгыннан килә торган уртак фәлсәфи караш, образлы фикерләү рәвеше белән аңлатыла, бу халыкларның үсеш-үзгәреш юлында гомуми якларны чагылдырган мәдәни реалийләр дә бу юнәлештә әһәмиятле роль уйный. Бу төрле халыклар фразеологиясендә телара фразеологик эквивалентлар тууга китерә. Мәсәлән, рус телендәге подливать масло в огонь фразеологизмының түбәндәге телара фразеологик эквивалентларын билгеләргә мөмкин:

инглиз телендә - *to pour oil on the flame(s) ягъни лить масло в пламя в огонь*

алман телендә - *öl auf das Feuer giesen ягъни лить масло в огонь*

француз телендә -*mettre de l' huile sur le feu* тәрҗемә шул ук

испан телендә - *echar aceite en el (al) fuego* тәрҗемә шул ук

татар телендә - *ялкынга ут өстәү, утка керосин өстәү*

Төрле телләрдә кулланылган әлеге фразеологик эквивалентлар семантик, фразеологик образлылыгы, стилистик кулланылышы һәм, лексик-грамматик яктан да тәңгәл. Һәр телдә дә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтне киеренкеләндерү, ситуацияне тагын да катлауландыру мәгънәсендә кулланыла, негатив бәяләү төсмеренә ия.

Эт белән мәче шикелле фразеологизмы рус, украин, поляк, румын, болгар, француз, испан, итальян, немец, норвег, малайзия телләрендә лексик-грамматик, стилистик тәңгәллектә кулланылалар. Беренче урында эт сүзе икенче урында *мәче* килә. Кайбер телләрдә, аерым алганда, инглиз һәм чех телләрендә беренче сүз булып *мәче* сүзе килә; венгр телендә исә оксюморон формасында кулланыла – *эт белән мәче шикелле дус яшәү.* Төрле телләрдәге фразеологик берәмлекләрнең охшашлыгы, нигездә, бер үк лексик-грамматик тәңгәллектә кулланылуы телара фразеологиянең структур-типологик бәйләнешен, универсальлеген күрсәтә.

Фразеологик тәңгәллекләренең кайберләре семантик тәңгәлеккә һәм фразеологик образларның якынлыгына нигезләнә. Аларны телара фразеосемантик тәңгәллекләр дип атыйлар. Бу очракта фразеологизмнар аерым компонентларга таркатып тәрҗемә ителә. Нигездә бу типологик яктан охшаш булган фразеологик берәмлек белән алмаштыруга кайтып кала. Мәсәлән, *урманга утын төяп бару* фразеологизмы

рус телендә - *ездить в Тулу со своим самоваром*

инглиз телендә - *to carry coals to Newcastle (доставлять уголь в Ньюкасл)*

немец телендә - *das Wasser in den Rhein tragen (носить воду в Рейн)*

венгр телендә - *vizet a Dunaba horbani (носить воду в Дунай)*

кебек семантик тәңгәллекләрдә кулланыла. Бирелгән фразеологизмнарны уртак логик-семантик үзенчәлек берләштерә: 1) тулып яткан бер урынга нәрсәдер алып бару; 2) кирәкмәгән, файдасыз бер эш белән шөгыльләнү.

Бирелгән фразеологизмнар – мәгънәләре һәм стилистик бизәкләре белән тәңгәл, ләкин фразеологик образлары белән аерылып, кабатланмас милли характерга ия булып торалар. Фразеологизмнар бер төрле фразеологик калып нигезендә төзелсәләр дә, составында бер этномәдәни компонент кулланыла.

Кызыл кар яугач фразеологизмы да фразеосемантик тәңгәллеккә ия.

Рус телендә - *когда на горе рак свистнет (рыба запоет)*

инглиз телендә - *when pigs fly (когда полетят свиньи)*

немец теленә - *wenn die Hunde mit dem Schwanz bellen* - *когда собаки залают хвостами*

испан телендә - *когда у лягушек появится шерсть*

Һәр фразеологизмның мәгънәсе бер үк – беркайчан да дигән мәгънәдә кулланыла

Телара фразеосемантик тәңгәлллекләрне ничек тәрҗемә итәргә?

Димәк, телара фразеосемантик тәңгәлллекләр мәгънәләре һәм стилистик бизәкләре белән тәңгәл, уртак фразеологик калапыка нигезләнеп төзелгән, ләкин фразеологик образлары белән аерылып торган фразеологизнар.

Мондый этномәдәни компонентлы фразеологизмнарны ничек тәрҗемә итәргә? Берничә вариант тәкъдим ителә. 1) фразеологизм буларак тәрҗемә итүдән баш тартырга мөмкин Әлге фразеологизмның мәгънәсен аңлату яисә синтаксик (ирекле) сүзтезмә белән бирергә мөмкин. Мәсәлән – *урманга утын төяп бару* – кирәкмәгән эш белән шөгыльләнү дип бирергә; 2) милли үзенчәлеккә ия булмаган синоним фразеологизм табу. Мәсәлән, *Дунайга су ташу дип түгел – диңгезгә су ташу* дип бирергә мөмкин; 3) теге яки бу фразеологизмның милли үзенчәлеген саклау өчен калькалаштыру юлы белән тәрҗемә итәргә мөмкин. Ләкин болай эшләгәндә, мәгънәсен аңлатып искәрмә ясау һәм тәрҗемә телендәге мәгънәдәш фразеологизмны күрсәтү зарури.

Фразеологик ныгымалар (сращения) гомуми күчерелмә мәгънәле һәм образлы булулары белән характерланмыйлар.Тәрҗемә иткәндә лексик-граматик яктан тәңгәл, бертөрле фразеологик калыпка нигезләнгән фразеологизмнар табарга мөмкин түгел. Бу очракта фразеологизмның мәгънәсенә, образына мөмкин кадәр тәңгәл, төгәл фразеологизм бирү сорала. Махсус фразеологик, эитмологик сүзлекләргә мөрәҗәгать итү тәрҗемәче өчен файдалы була.

Фразеологик ныгымалар, гадәттә, рәсми булмаган, көнкүреш җанлы сөйләм теленә хас булулары белән аерылып торалар.Алар сөйләмне эмоциональ-бәяләү төсмеренә баеталар. Компонентларның берсе үзенең этимологик семантикасын

югалткан, компонентлар арасында логик бәйләнеш юк. Мәсәлән, *бить баклуши, трай тибү*.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, 1) Иң адекват тәрҗемә булып структур-типологик мөнәсәбәттә якын булган телара фразеологик тәңгәллекләр санала.

2) Телара структур-типологик мөнәсәбәттә ераграк торган фразеологизмнарның тәрҗемәсе бик үк адекват түгел. Телара фразеосемантик тәңгәллекләр ярдәмендә тәрҗемә ителә. Этномәдәни компонент булу тәрҗемәне тагын да катлауландыра.

3) Төрле структур калыпка нигезләнеп төзелгән һәм бары тик семантик, образлылыгы ягыннан гына эквивалент фразеологизмнарны алмаштыру юлы белән тәрҗемә иткәндә адекватлык дәрәҗәсе кими.

4) Фразеологизмның лексик эквивалентны яисә семантик яктан якын булган ирекле сүзтезмә белән тәрҗемә иткәндә тәрҗемәнең адекватлылык дәрәҗәсе күпкә кими.

Список литературы

1. Алексеева И. С. Введение в переводоведение. Учебное пособие /И.С. Алексеева. — Москва. — Санкт-Петербург: ACADEMA, 2004. — 352 с.
2. Байрамова Л.К. Татарстан: Языковая симметрия и ассиметрия/Л.К. Байрамова. — Казань: КГУ, 2001. — 267 с.
3. Виноградов В.В. Лексические вопросы перевода художественной прозы/В.В. Виноградов. — М.: Изд-во МГУ, 1978. — 174 с.
4. Комиссаров В. Н. Лингвистика перевода. – М.: ЛКИ, 2007. – 165 с.
5. Латышев Л.К. Эквивалентность перевода и способы её достижения. - М.: Междунар. отношения, 1981. - 248 с.
6. Миннибаев К.С. Перевод – это искусство. Золотой век. – Казань: КГУ, 2004.
7. Нәбиуллина Г.Ә., Мөгътәсимова Г.Р. Тәрҗемә практикасы: әдәби һәм фольклор тәрҗемәләре. Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы. - Казань: Ихлас, 2012. – 91 б.
8. Юсупов Р.А. Тәрҗемәнең теоретик һәм практик мәсьәләләре. – Казан: ТДГПУ, 2011. – 312 б.

Рекомендуемые информационные ресурсы

9. http://nsportal.ru/shkola/rodnoi-yazyk-i-literatura/library/tukaynyn-trzhem-eshen-monsbte
10. http://russian-tatar.ru/
11. http://tatpoisk.net/dict/rus2tat/

Лекция № 13

Паремийларны тәрҗемә итү

Аннотация. Данная тема раскрывает способы перевода паремий.

Ключевые слова.

Методические рекомендации по изучению темы.

- Тема содержит лекционную часть, где излагаются способы перевода паремий.
- Для проверки усвоения темы имеются вопросы для изучения, также необходимо выполнить задание и отправить на проверку.

Вопросы для изучения

Способы перевода паремий.
Полное соответствие.
Частичное соответствие.
Замена.
Компенсация.

Паремийларга мәкаль һәм әйтемнәр керә. Аларны паремиология дигән махсус лингфистика фәне тармагында өйрәнәләр. Мәкальләр формасы белән - җөмлә калыбында, әйтемнәр сүзтезмә формасында булалар.

Мәкаль-әйтемнәр, тел-сурәтләү чарасы буларак, матур әдәбиятта бик еш кулланылалар. Билгеле бер ситуациядә әйтелгән фикернең дөреслеген раслау, фәлсәфи мәгънә бирү өчен, персонажның үзенчәлекле характерын, образын тудыру өчен халыкның тормыш, акыл тәҗрибәсе, мәдәнияте, дөньяга карашын чагылдырган әлеге халык авыз иҗаты җәүһәрләрен язучылар мул файдаланалар. Солодуб паремийларны, фразеологизмнар кебек әдәби тәрҗемәнең минималь берәмлеге итеп саный. Аның сүзләре белән килешергә нигез бар, чөнки мәкаль-әйтемнәр образлы, сөйләмгә әзер килеш килеп кергән, күчерелмә мәгънәдәге тотрыклы төзелмәләр, ләкин фразеологизмнардан аермалы буларак, алар ябык предикатив структурага ия.

Кешеләрнең яшәү шартларындагы, холык фигыльләрендәге, үзара мөнәсәбәтләрендәге уртаклыклар җирлегендә күп халыкларда, хәтта телләре, географик урыны белән бер-берсеннән бик ерак торган халыкларда да бер фикерне белдергән мәкальләрне табарга мөмкин. Шунысын да ассызыклап үтәргә кирәк: шундый семантик эквивалентлар әйтемнәргә караганда, мәкальләрдә күбрәк була. Бер төрле мәкальләр мәсәлән, рус, француз, немец, инглизләрдә дә күзәтелә. Мәсәлән, татар телендәге *Дус бәладә беленә* дигән мәкальне белорус, украин, болгар, поляк, инглиз, француз, испан, немец, мажар һәм башка телләрдә дә очратырга мөмкин. Алар паремиологик рәтләр барлыкка китереп, бер-берсенә карата телара фразеологик тәңгәллекләр булып йөриләр. Мондый мәкальләр формасы һәм мәгънәсе белән дә тәңгәл булалар.

Кайбер мәкальләрнең структур-семантик тәңгәллекләре белән бергә, аерым телләрдә бары тик семантик эквивалентлары гына (структур-типологик яктан төрле

булалар) бар. Мәсәлән, *Берьюлы ике куян артыннан куып булмый* дигән татар мәкаленең рус-европа телләрендә структур-типологик тәңгәллекләрен табарга мөмкин:

рус телендә – *Ике куян артыннан кусаң берсен дә тота алмассың*

инглиз телендә - *ике куян артыннан кусаң берсен дә тота алмассың (if you run after two hares, you will catch none)*

француз телендә - *кем ике куян артыннан куа берсен дә тота алмый*

немец телендә - *кем ике куян артыннан куа, берсен дә тота алмый*

испан телендә - *кем ике куян артыннан куа, берсен генә тотала, еш кына берсен дә тота алмый*

Украин (*ике йортның туенда берьюлы биеп булмый*), чуаш *(ике тәртә арасына ике ат җигеп булмый),* афган *(бер итеккә берьюлы ике аяк тыкмыйлар),* осетин *(ике җәнлек куып берсен дә тота алмаган),* кытай *(берьлы ике көймәдә басып торуы кыен)* телләрендә дә әлеге мәкальнең семантик эквивалентларын табарга мөмкин.

татар телендә - карга карганың күзен чукымый

рус телендә - ворон ворону глаз не выклюет

инглиз телендә - карчыга карчыганың күзен чукымый

француз телендә - каргалар каргаларның беркайчан да күзен чукымыйлар

испан телендә - бүре икенче бүрене тешләми

немец телендә - карга башка карганың күзен чукымый

вьетнам телендә - эт этнең итен ашамый

Күренгәнчә, мәкальләрне тәрҗемә иткәндә, кайвакыт структур-типологик тәңгәллекләрне һәм кайвакыт семантик эквивалентларны файдаланырга мөмкин. Мондый структур-типологик яктан охшаш, ягъни формасы да, мәгънәсе дә, образлары да туры килгән мәкальләрне тәрҗемә итү авырлык тудырмый. Бу очракта эзер эквивалентлар гына файдаланыла.

Мәсәлән, рус телендә *Разорванное не свяжешь* дигән мәкаль бар, бу мәкальгә татар телендә күчерелмә мәгънәсе белән туры килерлек бер кискән икмәк кире ябышмый мәкале бар. Әгәр тәрҗемәдә әзер вариантны куллансак, әлбәттә, оригиналның образы үзгәрер иде.

М. Заверин фикеренчә, “ Бер халык тарафыннан икенче телдән тәрҗемә ителгән яки ике телдә дә берьюлы барлыкка килгән мәкаль-әйтемнәрне яңадан тәрҗемә итеп торуның кирәге юк. Ә менә морале бер, образлар эчтәлеге төрле булганнарын тәрҗемә итәргә кирәк һәм мөмкин, чөнки ул мәкаль-әйтемнәрдә аларны иҗат иткән халыкның күп гасырлар буена тупланган тәҗрибәсе, чынбарлыкны танып-белү нәтиҗәсе чагыла”. Тәрҗемә ителгән мәкаль, оригиналдагы кебек, афористик, образлы, җыйнак, тапкыр булырга, шома әйтелгән, кыскасы, жанр табигатенә бәйле сыйфатларын югалтмаска тиеш. Семантик эквивалентлары блмаган очракта, мәкальләрне чын мәгънәсендә мәкаль итеп тәрҗемә итү өчен, туган тел таләпләрен, мәкальләрнең жанр табигате үзенчәлекләрен исәпкә алып эшләргә кирәк. Шулай булганда гына тәрҗемә үзен аклый.

Тәрҗемәченең бурычы – бер яктан, мөмкин кадәр тулырак, төгәлрәк, тиешле интонацияне саклап, тәрҗемә итү, икенче яктан, төп нөсхәдәге кебек образлы, тәэсирле итү.

Рус теленнән татар теленә әдәби тәрҗемәләрне карасак, шундый мәкальләрне очратырга мөмкин: *береги платье снову, а честь с молоду – киемеңне яңа чагыннан ук, намусыңны яшьтән үк сакла;*

семья не без урода – семья гарипсез булмый;

не место красит человека, а человек красит место – кешене урын бизәми, урынны кеше бизи;

горбатого могила исправит – бөкрене кабер генә төзәтә.

Шунысы үзенчәлекле: оригиналдагы мәкальләр тәрҗемәдә җөмлә калыбын үзгәртергә мөмкин. Татар һәм рус телләрендәге гомуми үтәүчеле бер составлы җөмләләр европа телләрендә еш кына ике составлы җөмлә калыбында биреләләр. Икенче яктан, мәкальне төзүче чаралар һәр телдә дә бертөрле булмый. Тәрҗемә иткәндә, әлеге чараларга да игътибарлы булу сорала.

Татар мәкальләренең күпчелеге бул ярдәмче фигыле белән төзелә. Мәсәлән, *первый блин с комом* мәкален тәрҗемә иткәндә, әлеге калыпны файдалану *дөрес була – беренче коймак төерле була.*

Рус мәкальләрендә, татар мәкальләренә карганда, каршы куючы теркәгечләр күбрәк күзәтелә, бу чара функциясен каршы кую интонациясе яисә, кире шарт фигыль формасы алмаштыра. Мәсәлән, *до бога высоко, а до царя далеко – алла биек, патша бик ерак; добрая слава лежит, а худая по свету бежит – яхшы хәбәр җирдә кала, яман хәбәр илгә тарала.* Соңгы мисалда теркәгеч төшереп калдырылган, хәбәр сүзе өстәлгән. Шолоховның “Күтәрелгән чирәм” әсәрендә *голос-то твой, песня – чужая* мәкале сүзгә сүз *тавышың үзеңнеке, ләкин җырың кешенеке* дип тәрҗемә ителгән, Бу тәрҗемәдә интонация табигый түгел – шуңа күрә *тавышың үзеңнеке булса да, җырың кешенеке яисә, тавышың үзеңнеке дә җырың гына кешенеке* дип бирергә мөмкин иде.

Аңлашылганча, мәкальләрдә сүзләрнең синтаксик бәйләнешләрендәге һәм грамматик формаларындагы үзенчәлек аркасында оригинал мәкален берникадәр үзгәртеп тәрҗемә итәргә туры килә. Түбәндәге мисалларда интонация тулылыгын, мәкаль стилен саклау өчен, сүз өстәлү күренеше күзгә ташлана: *отдашь руками, вернешь ногами – кулың белән биргәнне аягың белән йөреп алырсың; куда же палец от руки – бармакның кайчан кулдан аерылганны күргәнең бар; на ошибках учатся- ялгыша-ялгыша өйрәнәләр.*

Телдә милли колоритка ия, Солодуб сүзләре белән әйткәндә, “идиоэтник маркировкалы” мәкаль-әйтемнәр аерым урын алып торалар. Мәгънәсе бер, образлары төрле булган мәкальләрне тәрҗемә итү шактый катлаулы. Мондый очракта ике юл бар: 1) оригинал мәкален турыдан-туры тәрҗемә итү; 2) тәрҗемә телендәге әзер мәкальгә алмаштыру.

Мәсәлән, рус телендә *Москва не сразу строилась* әйтеме бар. Европа телләренә тәрҗемә текстларында бу мәкальне лексик яктан үзгәртеп тәрҗемә итәргә туры килә. Моның өчен шундый ук «маркировкалы» әйтемнәргә мөрәҗәгать итәргә туры килә:

француз телендә - *Париж бер көндә генә төзелмәгән*

инглиз һәм немец телләрендә - *Рим бер көндә генә төзелмәгән.*

Тагын бер мисал: *соловья баснями не кормят* мәкалендәге басня сүзе җыр белән алмаштырыла, чөнки *сандугачны мәсәл белән сыйлау* сүзтезмәсе табигый яңгырамый.

Мәкальләрне тәрҗемә иткәндә тагын бер әһәмиятле мәсьәлә бар: бу ритм-рифма таләбе. Бу үзенчәлек тәрҗемәдә дә чагылыш табарга тиеш.

Кайбер мәкальләрне турыдан-туры образлылыгын саклап тәрҗемә итеп булмый. Андый очракларда күчерелмә мәгънәләре, афористик яңгырашы, эмоциональ тәэсир итү көче ягыннан тиң булган әзер мәкальләр белән алмаштырырга туры килә. Мәсәлән, *входящее в уста не оскверняет* мәкален аерым компонентлары буенча тәрҗемә итсәк, фикер бөтенләй аңлашылмас иде. Шуңа күрә татар мәкале белән алмаштырабыз – *ризыкның языгы юк*.

Әдәби тәрҗемәдә кайвакыт мәкальләрне тәрҗемә итүдә компенсация ысулы кулланыла – мәкальләрнең мәгънәсе гади сүзләр белән бирелә, яисә төп нөсхәнең гади сүзләре мәкаль белән тәрҗемә ителә. Мәсәлән, *в тесноте да не в обиде – күңелең киң булса сыясың* дип, *кто не должен здороваться первым – кечелек итсәң, олылык табарсың* дигән мәкаль белән тәрҗемә ителгән.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, структур-типологик мөнәсәбәттә якын булган телара мәкаль-әйтемнәрнең тәрҗемә телендә адекватын табарга мөмкин.

Идиоэтник маркировкалы мәкальләрнең образларын, контексттагы функциясен саклаган хәлдә, тәрҗемәдә семантик эквивалентларын сайларга кирәк.

Паремийларны тәрҗемә иткәндә дә, аларның образларын, эстетик тәэсирен саклау, һәм тәрҗемә телендә - оригиналдагы образга якын тел берәмлеге табу әһәмиятле

Список литературы

Алексеева И. С. Введение в переводоведение. Учебное пособие /И.С. Алексеева. — Москва. — Санкт-Петербург: ACADEMA, 2004. — 352 с.

Байрамова Л.К. Татарстан: Языковая симметрия и ассиметрия/Л.К. Байрамова. — Казань: КГУ, 2001. — 267 с.

Виноградов В.В. Лексические вопросы перевода художественной прозы/В.В. Виноградов. — М.: Изд-во МГУ, 1978. — 174 с.

Комиссаров В. Н. Лингвистика перевода. – М.: ЛКИ, 2007. – 165 с.

Латышев Л.К. Эквивалентность перевода и способы её достижения. - М.: Междунар. отношения, 1981. - 248 с.

Миннибаев К.С. Перевод – это искусство. Золотой век. – Казань: КГУ, 2004.

Набиуллина Г.А. Некоторые вопросы перевода паремий // Актуальные проблемы и перспективы развития русскоязычной литературы в контексте национальных литератур:

материалы Всероссийской научно-практической конференции, приуроченной к 75-летию со дня рождения Рустема Кутуя (Казань, 9 ноября 2011 г.). – Казань, 2011. – С.155-159.

Нәбиуллина Г.Ә., Мөгътәсимова Г.Р. Тәрҗемә практикасы: әдәби һәм фольклор тәрҗемәләре. Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы. – Казань: Ихлас, 2012. – 91 б.

Саитбаева М.Н. Пословицы и поговорки как единицы текста и проблемы их перевода на узбекский язык / М.Н. Саитбаева // Текст как объект перевода. – Ташкент, 1988. – 80 с.

Юсупов Р.А. Тәрҗемәнең теоретик һәм практик мәсьәләләре. – Казан: ТДГПУ, 2011. – 312 б.

Рекомендуемые информационные ресурсы

http://nsportal.ru/shkola/rodnoi-yazyk-i-literatura/library/tukaynyn-trzhem-eshen-monsbte
http://russian-tatar.ru/
http://tatpoisk.net/dict/rus2tat/

Задания для практики по теме 6

6.1. Җөмләләрдә аерып бирелгән сүзләр нинди юллар белән тәрҗемә ителгән, оригиналдагы сүзләрнең мәгънәре сакланганмы?

1) Этого – не жди! Терпеть не могу лишних людей в доме, тебе помогают барышни. (М. Горький, “Васса Железнова”).

2) Стоит у стола. Раздумывая перебирает бумаги и переставляя вещи, хмурится глядя вперед. (М. Горький “Васса Железнова”).

3) Ну вот еще! Всю жизнь стеснялась, не зная для чего, — для хорошего человек можно! (М. Горький. “Мать”)

4) Прижав руки к груди, мать босая и в одной рубашке, стояла у его постели, губы ее беззвучно двигались, а из глаз медленно и ровно одна за другой текли большие и мутные слезы. (М. Горький, “Мать”).

5) И снова они стали жить молча,

1) Ансын көтмә дә инде! Йортта артык кеше булуны яратмыйм. Сиңа туташлар булыша бит. (Х.Үтәгән, Г. Камал).

2)Уйланып, кәгазьләрне актарып, әйберләрне күчергәләп, еракка караган килеш, йөзен чыта. (Х.Үтәгән, Г. Камал).

3) Менә инде сөйләде сүз! Бөтен гомерем буенча, ни өчен икәнен белмәстән, үземне үзем газапланганмын – яхшы кеше өчен мөмкин. (Ф. Бурнаш).

4) Ана ике кулын күкрәгенә кысып, ялан аяк һәм күлмәкчәен килеш, улының ятагы янында баскан, иреннәре тавышсыз гына селкенәләр, ә күзләреннән акрын һәм тигез генә бер-бер артлы ире, болганчык яшь тамчылары тәгәриләр иде. (Ф. Бурнаш).

5) Алар тагын эндәшми генә бер-берсенә ерак һәм якын кешеләр булып гомер итә башладылар (Ф. Бурнаш).

далекие и близкие друг-другу. (М. Горький “Мать”).

6) В холодном сумраке они шли по намощенной улице к высоким каменным клеткам фабрики, она равнодушной уверенностью ждала их, освещая грязную дорогу десятками жирных квадратных глаз (М. Горький “Мать”).

7) В этом крике — жажда бури! (М. Горький. “Песня о Буревестнике”)

8) Силу гнева, пламя страсти и уверенность в победе слышат тучи в этом крике.

9) Глупый пингвин робко прячет тело жирное в утесах.

10) Только гордый Буревестик реет смело и свободно над седым от пены морем.

6) Иртәнге салкында алар таш урам буйлап фабриканың биек таш читлекләренә ашыгалар, ә фабрик, пычрак юлны үзенең дистәләрчә дүрткел, симез күзләре белән яктыртып, бернәрсәгә исе китми торган ышанычлык белән аларны көтә. (Ф. Бурнаш)

7) Бу тавышта – давылга сусау яңгырый!

8) Ачу көче, дәрт ялкыны һәм җиңүгә ышаныч ишетәләр бу тавышта болытлар.

9) Аңгыра пингвин май баскан тәнен куркуыннан кыя ташлар арасына яшерә.

10) Тик мәгърур Давыл хәбәрчесе генә ак күбекле диңгез өстендә шулай кыю һәм иркен очып йөри.

6.2. Күчерелмә мәгънәдә кулланылган сүзләрне табыгыз. Туры килгән тәңгәллекләрне сайлап, җөмләләрне тәрҗемә итегез.

1. Противоположные чувства наполнили душу его. *(П.)* Выстрел раздалсы, дым наполнил комнату. *(Л.)* Он наполнил огромную кружку вином. *(Загоскин)* Радость наполнила его сердце *(Дост.)* 2. Если бы я поддержал его, он упал бы навзничь и больно расшиб голову. *(Гладк.)* Крышу поддерживает ряд простых четырехугольных деревянных столбов. *(Гонч.)* Коли может женщина получасовую беседу поддержать, это уж знак хороший *(Тург.)* Городские хозяйки изо всех сил поддерживали чистоту в домах. *(Пауст.) 3.* Отелло любит и ревнует гораздо сильнее дюжинных людей. *(Чернышевский).* А ты меня ревнуешь к этим мыслям. *(Писемский)* Вы… ревнивец! Вы адски ревнуете Ганю к известной гордой девице! (Дост) Еще и то заметь, чтобы любить ее, а ревновать не сметь. *(Кр.)*

6.3. Күчерелмә мәгънәдә килгән сүзтезмәләрне тәрҗемә итегез.

Золотые руки, груз горя, на лицо легла тень, неожиданная милость неба, горят глаза, ранит сердце, радость не умещалась в груди, медный лоб, мыльный пузырь, парит в облаках, вертишь мельницу, смотреть через розовые очки, стало тесно в собственной рубашке, на лицо легла тень, неожиданная милость неба, пускать красного петуха, потушить огонь жизни, проходить огонь и воду, подняться из-под земли, парить в облаках, кровь сбежала, луч солнца, черные тучи, огонь жизни, весна жизни, белый день,

дыхание весны, шепот моря, сердце горит, сердце кипит, сердце разрывается, сердце сжимается, сердце плачет, раздался свисток — свистеть в свисток, добывать серебро — столовое серебро, овечье шерсть — шерсть на платье.

6.4. Фразеологик берәмлекләрне табып, аларның нинди ысуллар ярдәмендә тәрҗемә ителүен аңлатыгыз.

I. 1) У меня у самой голова кружится, когда ты так делаешь. – Син шулай караганда, минем үземнең дә башым әйләнә. 2) Дедушка у нас на юге всякую совесть потерял, – засмеялась Анна. – Безнең бабакай көньякта бөтенләй оятын җуйган, – диде Анна көлеп. 3) Я очень рад, что нашел в вас порядочного человека, джентльмена, способного понимать с полуслова. – Сезнең шулай ярты сүздән безне аңлый ала торган күркәм кеше булуыгыз, джентельмен булуыгыз мине бик шатландыра. 4) И какой чудный воздух: дышишь – и сердце веселится. – Һавасы соң, һавасы нинди – бер тын алсаң, ничектер күңелләр ачылып китә. 5) Тяжело быть лишним ртом в семье. – Аннары гаиләдә артык кашык булып яшәү дә кыен. 6) Только один весь от страха раскисая, а другой держит себя в руках. – Тик берсе куркудан бөтенләй җебеп төшә, ә икенчесе эченә йота, белгертми. 7) На что уж мы легко глядели на эти романы, но даже и нас коробило. – Хәтта без дә гаилә романнарына бармак аша гына караган гаскәри офицерлар да, аның кайбер кыланышларын күреп исебез китә иде. 8) Князь Шеин, несмотря на свое видное положение в обществе, а может быть, и благодаря ему, едва сводил концы с концами. —Князь Шеин, җәмгыятьтә шактый күренекле урын тотып торуына карамастан, ә бәлки шул күренекле урын тотуы аркасындадыр, акча мәсьәләсендә бик кысан яши һәм тормышын көчкә-көчкә генә алып бара иде. 9) Каждый день вас ждали, а вы хоть бы глаза показали. Без сезне көн саен көтәбез, ә сезнең монда бер генә мәртәбә дә күренеп киткәнегез юк. *(А.И. Купринның "Гранат кашлы беләзек" әсәреннән).*

6.5. Фразеологизмнарны тәрҗемә итегез.

1) Бить баклуши, точить мясо, собаку съел, так себе, куда ни шло, была не была, то и дело, хоть куда, диву даться, ни в зуб ногой, кровь с молоком, висеть на волоске, выжить из ума, выплакать глаза, в рот воду набрать, входящее в уста не оскверняет, не было печали, так черты накачали, что было, то быльем поросло, похож ежа в ежу, жить душа в душу, злость берет , в единстве сила, находить общий язык, протянуть руку помощи, наступить на хвост, шкуру снимать, ставить точку.

6.6. Паремияләрне тәрҗемә итегез. Кайсы ысуллар ярдәмендә тәрҗемә ителүен аңлатыгыз.

Береги платье снову; Береги платье снову, а есть смолоду; На грех мастера нет; Незванный гость хуже татарина; Повинную голову меч не сечет; Керпене бияләй белән

тотарга; Из огня в пламя; Мирская молва – морская волна; А с лихой собаки хоть шерсти клон; Будет дождик, будут и грибки; а будут грибки, будет и кузов; Стали было к вечерни звонить, да попадья не велит: поп в гостьях, черти на погосте; Долг платежом красен; Худой мир лучше доброй ссоры, а и нечестен, так здоров. *(А.С.Пушкинның “Капитан кызы” әсәреннән).*

6.7. Әсәрдә кулланылган эпитетлар нинди ысуллар ярдәмендә тәрҗемә ителүен аңлатыгыз.

1. Грешные души – гөнаһлы җан; белый конь – ап-ак ат; грудный вечер – гүзәл бер кич; великое счастье – бөек бәхет; суровые, грозные годы – кырыс, усал һәм рәхимсез еллар; печальные вести – ачы вакыйгалар; плохие минуты – кыен минутлар; голубая дорожка – зәңгәрләнеп ята басу юлы; пьяный туман – рәхәт бер томан; гнилая хата – һәр ызбаның тишек түбәсе; ясная дорога – юлым төз; угрюмая улыбка – каш астыннан гына карадылар; стройный лик – назлы ак йөз; сиреневая погода – сирень сыман көн. *(С. Есенинның “Анна Снегина” поэмасыннан).*

6.8. Чагыштыруларны тәрҗемә итегез.

Женщина словно ангел, как грибы после дождя, подобно грому среди ясного дня, как гора из песка, как зоренька в погожий день, словно рыба в воде, будто муравьиное гнездо, что роса на восходе солнца, казалось началом чудной сказки, деньги — вода, золотом сверкала река, словно брызги парного молока, точно птица в клетке, как сломанное ветром дерево, словно одинокий подснежник, звучал как музыка, дрожать как лист, синее как солнце, как рыба в воде.

ТЕМА 7. ӘДӘБИ ТӘРҖЕМӘНЕҢ СИНТАКСИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Лекция № 14

Синтаксик фигураларны тәрҗемә итү үзенчәлекләре

Аннотация. Данная тема раскрывает способы перевода синтаксических фигур.

Ключевые слова. Синтаксик фигуралар, кереш сүзләр, эндәш сүзләр.

Методические рекомендации по изучению темы.

- Тема содержит лекционную часть, где излагаются способы перевода синтаксических фигур.
- Для проверки усвоения темы имеются вопросы для изучения, также необходимо выполнить задание и отправить на проверку.

Вопросы для изучения

Способы перевода синтаксических фигур.
Перевод обращений.
Перевод вводных слов.
Перевод повторов.

С.Фәйзуллин гоманлавынча, «Телне мөстәкыйль иткән, аны мәңге хәрәкәттә тоткан нәрсә - ул грамматик чара. Шуның аркасында гына сүзләрдән тел дип аталган гүзәл бер бина хасил булган. Шул бинага карап без һәр халыкның үзенә хас булган үзенчәлекле фикерләү ысулын күрәбез. Җыеп кына әйткәндә, һәр телнең үзенә җитәрлек грамматик ысуллары бар».

Әсәрнең нәфислеген, ритмын, яңгырау характерын, эмоциональ нәфислеген бирүдә синтаксис әһәмиятле роль уйный. Матур әдәбиятта синтаксик фигуралар әнә шундый әһәмиятле сурәтләү чараларыннан санала. Синтаксик фигураларга риторик сорау, өндәү, инверсия, кабатлау, параллелизм, симметрия, эндәш сүзләр һ.б. керә. Бу чаралар сөйләмнең эмоциональ-экспрессив булуына ярдәм итәләр.

Синтаксик фигураларны тәрҗемә итү мәсьәләсе турында В.Н. Комиссаров, Я.И.Рецкер, Х.Н. Садыков, А.В. Федоров, М. Каратаев, К. Чуковский хезмәтләрендә язылган. Галимнәр барысы да бердәм караш ята тора – синтаксик чаралар, һичшиксез, тәрҗемәдә чагылыш табарга тиеш. Алар фикеренчә, синтаксик фигуралар, сәнгатьлелек чаралары буларак, саклык белән бирелергә тиеш. К. Чуковский бу хакта түбәндәгечә яза: Төп нөсхә синтаксисында поэтик һәм прозаик сөйләмнең билгеле бер ритмнар системасын төзи торган төрле кабатлаулар, параллелизм, бер төрле башлану, симметрик төзелмәләр булганда, аларны рус синтаксисы чаралары ярдәмендә бирү авыр булмаганда, бу синтаксик фигураларны рус телендә гәүдәләндерү мәҗбүри.

Эндәш сүзләр матур әдәбиятта киң кулланыла. Эндәш сүзләр булып һәр ике телдә дә предметны, затны, төрле күренешләрне белдергән сүзләр килергә мөмкин. Эндәш сүзләр бер сүз белән генә белдерелергә дә мөмкин, җәенкеләндерүче кисәкләр белән дә килә ала. Эндәш сүзләр кабатланып та кабатланмыйча да килергә мөмкин. Алар җөмләнең төрле урынында килә ала һәм һәр очракта да аерымлана. Эндәш сүзләрнең урнашу тәртибе һәр ике телдә дә һәрвакытта туры килми: *Женись, Андрюша! – Андрюша, өйлән инде. (М. Шолохов); Это, брат, ерунда! – Юк нәрсә ул, туган! (М.Горький).*

Ике телдә охшаш яклар белән бергә, үзенчәлекле яклар да бар. Мәсәлән, татар телендә *әнкәсе, әтисе. сиңайтим, туганкай, сандугачым, былбылым, канатым, үскәнем, җанкаем, рус телендә матушка, мамаша, папаша, голубушка, родная* һ.б. шундый эндәш сүзләр кулланыла. Бу мәсьәләдә әдәби тәрҗемәләрдә телләрнең үзенчәлекле якларын исәпкә алу зарур. Теге яки бу халыкка хас эндәшү сүзләрен механик рәвештә генә күчереп кую дөрес түгел. Татар теленә тәрҗемәләрдә *матушка, мамаша – анакай, папаша – атакай, голубушка – күгәрченкәй* дип тәрҗемә итү очрый. Р. А. Юсупов фикеренчә, болай тәрҗемә итү дөрес түгел. Чөнки татарларда алай тәрҗемә итү юк, “Мондый күчерелмә мәгънәдәге эндәш сүзләрне оригиналга функция, стиль, ягыннан

туры килерлек чаралар белән тәрҗемә итәргә кирәк. Төп нөсхәдәге эндәш сүз укучыда нинди тәэсир тудырса, тәрҗемәдәге эндәш сүздән дә шундый тәэсир туарга тиеш. Бу таләп үтәлсен өчен, эндәш сүзнең тәрҗемә теле өчен табигый, аңлаешлы булуы – беренче шарт". Р.Юсупов, *голубушканы – сандугачым, былбылым, родимый мой – бәгырем, кадерлем, брат – агай, эне, папаша, мамаша* – яшьләренә карап, *абый, апа, бабай, әби* дип алмаштырырга тәкъдим итә.

Эндәш сүзләр зат исемнәреннән торганда, аларны тәрҗемә итү кыенлык тудырмый, чөнки үзгәртергә кирәкми.

Рус телендә дә, татар телендә дә эндәш сүзләр тыңлаучының игътибарын җәлеп итү чарасы булапак та, модаль максатларда да кулланыла. Әгәр эндәш сүзләргә билгеле бер модаль мәгънә, эмоциональ-экспрессив бизәк хас булса, аларны тәрҗемә итә тагын да катлаулырак. Мәсәлән, *Здравствуйте, мои миленьнкие. – Исәнмесез, сөеклеләрем! (И. Тургенев). Мать, а мать!* - *Әни, әни дим!*

Ә хәзер эндәш сүзләрнең урнашуын карыйк:

1) "Во всех ты, Душенька, нарядах хороша." - *"Нинди генә кием кисәң дә чибәр син, Җанашым." (А.С. Пушкин)*

2) "Постарайся, Настя, увидеть Алексея, да расскажи мне хорошенько, каков он собою и что он за человек." - *"Алексей Брестовны күрергә тырыш, Настя. Соңыннан миңа аның кыяфәтен һәм нинди кеше икәнлеген сөйләп бирересең." (А.С. Пушкин)*

3) "Батюшка, я о женитьбе еще не думаю." - *"Өйләнү турында уйламыйм әле мин, атакай."(А.С. Пушкин)*

Әлеге тәрҗемәләрдә эндәш сүзләр җөмлә ахырында килә. Эндәш сүзләрнең җөмлә ахырында килүе сөйләм агышын шомарак итә.

Эндәш сүзләрнең урыны оригиналдагыча булган җөмләләрдә бар. Алар да сөйләмгә зыян китермиләр. Бик уңышлы тәрҗемә ителгәннәр. Мәсәлән, *"Нет, папа, как вам угодно: я ни за что не покажусь."* - *"Юк, әти,теләсәгез нишләгез: мин аларга күренмәячәкмен.*"(А.С. Пушкин)

Кереш сүзләр. Кереш сүзләр синтаксис фәнендә модаль кисәкләр буларак өйрәнелә. Алар авторның билгеле бер вакыйга-күренешләргә модаль мөнәсәбәтен белдереп киләләр. Кереш сүзләр һәр ике телдә дә килеп чыгышы, мәгънәләре ягыннан өйрәнеләләр. Галимнәрнең тикшеренүләренә караганда, рус теленнән калькалаштыру исәбенә татар телендә кереш сүзләрнең саны арта бара (Ф.С. Сафиуллина).

Рус теленнән татар теленә, һәм киресенчә, татар теленнән рус теленә тәрҗемә иткәндә, кереш сүзләрне туры тәңгәллекләр белән бирергә мөмкин. Мисаллардан күренгәнчә, кереш сүзләр тәрҗемдә оригиналдагы урыннар буенча туры килергә яисә туры килмәскә дә мөмкин.

Рус һәм татар телләрендә кереш сүзләр мәгънә күләмнәре ягыннан өлешчә генә туры киләләр. Аларның рус телендә сан ягыннан да күбрәк булуы билгеле. Шуңа күрә русчадан татарчага тәрҗемәдә күп кенә кереш сүзләрне тәрҗемә итү кыенлык тудыра. Мәсәлән, *признаюсь, кстати, между прочим, представь, казалось бы, кажется, в*

самом деле кебек кереш сүзләргә адекват тәрҗемә табылмый. Аларны турыдан-туры калькалаштырып тәрҗемә итү дә һәрвакыт уңышлы булмый.

Мондый очракларда кереш сүзләрнең модаль мәгънәләрен бирү өчен, еш кына алмаштыру һәм компенсация ысулыннан файдаланырга туры килә. Моның өчен кисәкчәләр, сорау алмышлыклары, модаль төзелешле фигыльләр, ымлыклар, сүз тәртибе, интонация ярдәмгә килә. Мәсәлән, *Должно быть, на Каменск полетели переправу бомбить. - Кичүне бомбага тотарга Каменскига баралар булса кирәк. (А. Фадеев.).*

Кайбер очракларда рус теленең кереш сүзләре татар телендә үзләренең модаль мәгънәләрен югалталар.

Кабатлауларның бирелеше

Тәрҗемәдә оригиналның мәгънәсе, эчтәлеге бирелергә, авторның стиле сакланырга тиеш. Шулай ук, оригиналның бөтен эмоциональ нәфислеге, синтаксик бизәге, ритмы һ.б гәүдәләндерелгәндә генә тәрҗемә адекват була ала. Әсәрнең эмоциональ нәфислеген булдыруда синтаксис әһәмиятле роль уйный. Синтаксик үзенчәлекләрне гәүдәләндерү тәрҗемәдә оригиналның синтаксик төзелешен бирүне күздә тота. Синтаксик фигуралар дип риторик сорау, өндәү, инверсия, кабатлауларны, эндәш сүзләрне, дәшми калуны һ.б атыйлар.

Кабатлаулар билгеле бер сүзләрне логик яктан башкаларыннан аерып кую һәм сөйләмнең эмоциональ киреленкелеген көчәйтү өчен хезмәт итә. Ләкин бу кабатланып килгән сүзләр, сүзтезмәләр, җөмләләр тәҗемә телендә дә төп нөсхәдәгечә кабатланып килә дигән сүз түгел. Сөйләм җанлырак һәм табигыйрәк булсын өчен кабатлуларның санын үзгәртергә туры килгән очраклар да була.Т.Левицкая, А.Фитерман кабатлауларның тәрҗемә телендә уңайсызлык тудырмасалар, һәм артык булмасалар гына сакларга кирәк дигән каршата торалар. Табигый булмасалар, артык булсалар, аларның санын кыскартырга, яки башка сүзләр белән алмаштырырга, бүтән сүзләр өстәргә мөмкин булуын искәртәләр. Кыскасы, тәрҗемәдә кабатлауларны гәүдәләндергәндә, кабатлана торган сүзләрнең ике телдә дә характерларын, кыскалык һәм озынлыкларын, эмоциональ-экспрессив көчләрен исәпкә алырга һәм кабатлауларның санын бирү белән мавыкмыйча, оригиналда кабатланы килгән элементларга функциональ тәңгәллекләр табарга кирәк.

Мәсәлән, русчадан татарчага тәрҗемәләрдә кабатлауларның бирелешен карыйк: *Мокро, мокро, хозяева, - брюзжал Калмыков. – Калмыков: Юеш, хуҗалар, юеш, - дип мыгырдандылар. (М. Шолохов) Нет, нет, ты сегодня никуда не пойдешь!– Юк, юк, син бүген беркая да китмисең! (Н. Островский).* Бу мисаллардагы кабатлаулар уңышлы тәрҗемә ителгәннәр. Ләкин, русчадагы кабатлауларның тәрҗемәдә бирелеше, кабатлауларның санын саклау һәрвакытта да үзен акламый. Нәтиҗәдә, кабатлау сөйләмне авырайта, укучыны ялыктыра, табигый яңгырашны боза, тәрҗемә оригиналдагы кебек эмоциональ тәэсир көче тудыра алмый.

Русчадан татарчага тәрҗемәдә оригиналдагы кабатлаулар саны, нигездә, саклана, һәм алар күп очракта татар теле өчен артык та булмый. Мәсәлән, А.С. Пушкинның "Станция караучысы" һәм "Барышня крестьян кызы" повестьларындагы кабатлауларның бирелешен тикшерик.

"Барышня крестьян кызы".

1) "Ах, Настя, милая Настя!" - "Ах, Настя, җаным Настя!"

2) "Ну, хорошо, хорошо; согласен, делай, что хочешь, черноглазая моя шалунья". - "Я, яхшы, яхшы; мин риза, теләгәнеңне эшлә, минем кара күзле шаяным".

3)"Акулина, Акулина!"- "Акулина, Акулина!"

4) "Барин, сказывают, прекрасный: такой добрый, такой веселый." - "Бик яхшы барин, диләр: шундый яхшы күңелле, шундый көләч."

5) "И одет-то не так, и баишь иначе, и собаку-то кличишь не по-нашему." - "Өс-башың да үзгә, сөйләшүең дә бүтәнчә, эткә дә безнеңчә дәшмисең."

6) "Лиза... нет, Акулина, милая смуглая Акулина, не в сарафане, а в белом утреннем платьице, сидела перед окном и читала его письмо." -"Лиза... юк, Акулина, сөекле карасу чырайлы Акулина сарафаннан түгел, ә иртәнге ак күлмәктән тәрәзә алдында утыра һәм аның хатын укый иде."

Бу җөмләләрдә кабатлаулар уңышлы тәрҗемә ителгән, аларның саны оригиналдагыча. Бертигез сандагы кабатлаулар ике телдә дә бер төрле стилистик вазифа башкара һәм табигый интонация төзи. Мондый мисалларны "Станция караучысы" әсәреннән дә китерергә мөмкин:

1)"Ах, Дуня, Дуня!" - "Ах, Дуня, Дуня!"

2) "Бывало (Царство ему небесное!) идет из кабака, а мы-то за ним: "Дедушка, дедушка! Орешков! А он нас орешками и наделяет." - "Шулай (урыны җәннәттә булсын!) кабактан кайта торган иде, ә без аның артыннан:" Бабай, бабай! Чикләвек бир әле"- дип кычкыра идек, ә ул безгә чикләвек бирә торган иде."

3) "Кто не проклинал станционных смотрителей, кто с ними не бранился? Кто, в минуту гнева, не требовал от них роковой книги, дабы выписать в оную свою бесполезную жалобу на притеснение, грубость и неисправность? Кто не почитает их извергами человеческого рода, равными покойным подъячим или по крайней мере муромским разбойникам." - "Станция караучыларын кем генә каргамаган, алар белән кем генә тиргәшмәгән, кысу, тупаслык һәм тәртипсезлекләргә ачуы кабарган минутларда, үзенең файдасыз жалобасын язар өчен кем генә алардан шомлы дәфтәрне таләп итмәгән. Кем генә аларны мәрхүм подъячийларга яисә, кимендә Муром юлбасарларына тиң кансыз кешеләр итеп санамый."

4)"Боже! Какие ругательства, какие угрозы посыпаются на его голову!" - "Я ходай! Аның башына нинди тиргәүләр, нинди янаулар явачак!"

5) "Барыни дарили ее, та платочком, та сережками." - "Барынялар кайсы яулык, кайсы алка бүләк итәләр иде."

6) "Смотритель постоял, постоял и пошел." - "Карт тора, тора да китеп бара."

7) "Нельзя, нельзя! - закричала вслед ему служанка, - а у Авдотьи Самсоновны гости." - "Ярамый, ярамый! Авдотья Симеоновнада кунаклар бар", - дип кычкырып кала."

8) "Дочка-с, - отвечал он с видом довольного самолюбия, - да такая разумная, такая проворная, вся в покойницу мать". - "Ул бик кәефе килгән кыяфәт белән җавап бирде:

- Минем кызым, - өстәвенә шундый акыллы, шундый җитез, бөтенләй мәрхүм анасы инде."

Күренгәнчә, әлеге тәрҗемәләрдә дә кабатлаулар саны оригиналдагыча бирелгән. Тәрҗемә матур килеп чыккан. Алар татар теле өчен килешсез, кирәксез түгел, оригиналның укучыга тәэсир итү көче сакланган.

Кайбер очракларда кабатлаулар санын оригиналдагыча бирү сөйләмне авырайта. Түбәндәге мисалны карыйк:

1) "Ее дом держался: что прибрать, что приготовить, за всем успевала." - "Йортны тоткан кеше ул - җыештырырга, хәзерләргә дисенме, барысына да өлгерә."

Биредә "дисеңме" сүзе бер генә мәртәбә кабатлана, һәм болай эшләү үзен аклый да. Сүзне ике тапкыр кабатлау сөйләмне авырайтыр, укучыны ялыктырыр иде. Шуңа да игътибар итергә кирәк: оригиналдагы эмоциональлек югалмый, ул тәрҗемәдә тиңдәш кисәкләр һәм интонация ярдәмендә белдерелә.

2) *"Военный лакей, чистя сапог на колодке, объявил, что барин почевает и что прежде одиннадцати часов не принемает никого." - Калыпка киертелгән итекләр чистартып торучы гаскәри лакей: "Барин йоклый һәм сәгать унбердән элек беркемне дә кабул итми", - дип җавап бирә."*

Әлеге мисалда да оригиналда кабатланып килгән сүзләр урын алмый. Әгәр дә кабатлауларны саклап калсак, җөмлә түбәндәгечә килеп чыгар иде: *"Калыпка киертелгән итекләр чистартып торучы гаскәри лакей, барин йоклый дип һәм сәгать унбердән дә элек беркемне дә кабул итми дип, җавап бирә."*

Әлеге тәрҗемәләрдә кабатлаулар саны оригиналдагыча түгел. Сүз бер генә тапкыр кабатлана. Минемчә, бу бик уңышлы. Чөнки әлеге урында кабатлаулар санын саклаган булсак, алар табигый яңгырашны бозарлар иде, тәрҗемә дә оригиналның эмоциональ-экспрессив тәэсирен тудыра алмас иде. Кабатлауларны артык булмасалар, уңайсызлык китермәсәләр генә сакларга кирәк. Әлеге тәрҗемәләрдә кабатлауларны кыскартып, С.Әдһәмова бик дөрес эшләгән дип уйлыйм. Кабатлаулар саны кимесә дә, әсәрнең эмоциональ киеренкелеге тулы бирелгән.

Тагын бер мисалны карап китик:

"...заклинал ее не лишать его одной одрады: видаться с нею на едине, хотя бы через день, хотя бы дважды в неделю. - ...бары тик бер генә куанычтан: аның белән көн аша булса да, атнага ике тапкыр гына булса да, аулакта күрешү шатлыгыннан мәхрүм итмәвен ялварып үтенде."

Минемчә, биредә "булса да" сүзен оригиналдагыча ике тапкыр кабатлау сөйләмне авырайта, ялыктыргыч интонация китереп чыгара. Бу очракта кабатлауны бирү кирәк түгел, "...бары тик бер генә куанычтан: аның белән көн аша яки атнага ике генә тапкыр булса да, аулакта күрешү шатлыгыннан мәхрүм итмәвен ялварып үтенде" дисәк яхшырак. Эмоциональ тәэсир биредә шулай ук югалмый, ә интонация һәм тиңдәш кисәкләр белән белдерелә.

Пушкин повестьларында кабатлаулар бик уңышлы тәрҗемә ителгән. Тәрҗемәдә оригиналдагы кабатлаулар саны, нигездә, сакланган һәм алар татар теле өчен артык та түгел, оригиналның эмоциональ киеренкелеген саклыйлар. Кайбер урыннарда кабатлаулар төшереп калдырыла. Ләкин бу үзен аклый. Чөнки кабатлауларны кулланмау сөйләмне катлауландырмас өчен, укучыны ялыктырмас һәм эмоциональлекне бозмас өчен.

Список литературы

Алексеева И. С. Введение в переводоведение. Учебное пособие /И.С. Алексеева. — Москва. — Санкт-Петербург: ACADEMA, 2004. — 352 с.

Байрамова Л.К. Татарстан: Языковая симметрия и ассиметрия/Л.К. Байрамова. — Казань: КГУ, 2001. — 267 с.

Виноградов В.В. Лексические вопросы перевода художественной прозы/В.В. Виноградов. — М.: Изд-во МГУ, 1978. — 174 с.

Комиссаров В. Н. Лингвистика перевода. – М.: ЛКИ, 2007. – 165 с.

Латышев Л.К. Эквивалентность перевода и способы её достижения. - М.: Междунар. отношения, 1981. - 248 с.

Миннибаев К.С. Перевод – это искусство. Золотой век. – Казань: КГУ, 2004.

Набиуллина Г.А. Некоторые вопросы перевода паремий // Актуальные проблемы и перспективы развития русскоязычной литературы в контексте национальных литератур: материалы Всероссийской научно-практической конференции, приуроченной к 75-летию со дня рождения Рустема Кутуя (Казань, 9 ноября 2011 г.). – Казань, 2011. – С.155-159.

Нәбиуллина Г.Ә., Мөгътәсимова Г.Р. Тәрҗемә практикасы: әдәби һәм фольклор тәрҗемәләре. Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы. – Казань: Ихлас, 2012. – 91 б.

Саитбаева М.Н. Пословицы и поговорки как единицы текста и проблемы их перевода на узбекский язык / М.Н. Саитбаева // Текст как объект перевода. – Ташкент, 1988. – 80 с.

Юсупов Р.А. Тәрҗемәнең теоретик һәм практик мәсьәләләре. – Казан: ТДГПУ, 2011. – 312 б.

Рекомендуемые информационные ресурсы

http://nsportal.ru/shkola/rodnoi-yazyk-i-literatura/library/tukaynyn-trzhem-eshen-monsbte
http://russian-tatar.ru/
http://tatpoisk.net/dict/rus2tat/

Лекция № 15

Сүз тәртибе белән бәйле мәсьәләләр

Аннотация. Данная тема раскрывает особенности порядка слов в художественном переводе.

Ключевые слова. Сүз тәртибе, инверсия, җөмлә кисәкләре,

Методические рекомендации по изучению темы.

- Тема содержит лекционную часть, где излагаются особенности порядка слов в художественном переводе.
- Для проверки усвоения темы имеются вопросы для изучения, также необходимо выполнить задание и отправить на проверку.

Вопросы для изучения

Порядок слов в оригинале и в переводе.
Функций порядка слов в художественном тексте.
Варьирование порядка слов в переводе.
Различные виды инверсии и способы ее компенсации при переводе.
Инверсия в современной русскоязычной прозе и способы ее компенсации при переводе художественных текстов с русского языка на татарский.

Стилистик фигураларның тагын берсе - ул инверсия. Сүзләр урнашуның катгый тәртибе, нигездә әдәби телнең проза сөйләменә карый. Монда гомум кабул ителгән сүз тәртибен бозу телнең синтаксик нормаларыннан читкә тайпылу булып исәпләнә. Шулай да проза сөйләмендә билгеле бер максатларда берникадәр дәрәҗәдә кире сүз тәртибе, ягъни инверсия кулланыла.

Инверсия төп ике максатны: сөйләмне тәэсирлерәк итү һәм берничә җөмләнең рәттән бертөрле фигыль формаларына тәмамлануыннан килеп чыккан монотонлыкны кимету максатларын күздә тота. Ләкин инверсия мәсьәләсендә сак булырга кирәк. Гадәти сүз тәртибен үзгәртү белән мавыгырга ярамый. Инверсияне артык күп куллану ясалма интонация китереп чыгара. Тәрҗемәдә рус теленә ияреп, инверсияләрне күп кулланырга ярамый. Чөнки ике телнең сүз тәртибендә аермалар

бар. Рус телендә сүз тәртибе татар телендәгегә караганда иреклерәк, анда инверсиянең вазифалары безнең телдәгегә туры килми.

Хәзер инверсиянең тәрҗемәдә бирелешен тикшерик. "Станция караучысы" һәм "Барышня крестьян кызы" әсәрләрендә иң күп кулланылгын инверсия - ул ия белән хәбәрнең кире тәртибе. Әлеге әсәрләрдә, нигездә, рус телендәге кире сүз тәртибе тәрҗемәдә туры сүз тәртибе белән бирелгән. Тәрҗемәче дөрес эшләгән дип уйлыйм, чөнки инверсия сакланган булса, сөйләм ясалма килеп чыгар иде. Ә бу әсәрнең тәэсир итү көчен югалтачак. Мисаллар ("Барышня крестьян кызы" әсәреннән):

1) "Уехал он в последнюю свою деревню." - "Ул үзенең актык авылына кайтты."

